КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни Җомга

№ 19
24 ноябрь
1995 ел

1995 елның июленнән
башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы



БҮГЕНГЕ САНДА:

5 *Фарсил-Сәхәби ЗЫЯТДИН.* Җиргә мөнәсәбәт беркайчан да кешечә булмады, дөресрәге, Русиядә икмәк очен көрәшне күп очракта яңа җирләр яулап алу өчен көрәш алыштырган.

6 *Рәис БЕЛЯЕВ.* Чит төбәкләр белән артистлар алмашып, китаплар җибәреп кенә анда яшәүче милләттәшләребезнең мәдәнияткә һәм сәнгатькә булган ихтыяҗларын канәгатьләндереп бетереп булмый, ә күпләп белгечләр өзерләргә кирәк.

10 *Роберт МИҢНУЛЛИН.* Бу җәмгыятьтә башкаларга охшамаска тырышып яшәү бер дә җиңел түгел, көнләшү, аяк чалу, юл бирмәү кебек тискәре күренешләр безнең зыялылар арасында да җитәрлек.

12 *Равил ҺАДИ.* Төркиләр башка кавемнәр белән күп аралашкан, шуңа күрә телләре дә халыкара аралашу теле буларак камилләшкән.

Театр — могҗизәт, театр мәхәббәт,
Күңелдән мәрхәмәт китмәсен...

МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

Империя тәхетенә генераллар урнаша. Һәм аларның зур күпчелеге үз вакытында Әфганстанда бәйнәлмиләл бурыч үтәп яки Чечняда конституцион тәртип урнаштырып абруй казанган кешеләр. Әгәр дә совет-урыс дәүләте әледән-әле агрессив сугышлар алып бармаган булса, ихтимал, бу генералларның исем-шәрифләрен үз частендәге солдатлардан башка берәү дә белмәс иде. Ә бүген шулар депутат булырга, ил белән идарә итәргә әзерләнә. Әйдәгез, бергәләп уйлашыйк, кардәшләр: бу сайлаулар безне гөл итәрме, әллә көл итәрме?..

Газинур МОРАТ

КҮЗГӘ-КҮЗ КАРАП

Мин гомер буе үзем өчен яшәмәдем бугай

Рәис БЕЛЯЕВ,
Казан дәүләт сәнгать һәм мәдәният академиясе ректоры, академик:

— Рәис әфәнде, сезгә сорауларымны ректор, халык депутаты, галим, җәмәгать эшлеклесе буларак бирәсем, әңгәмәбезне шуңардан башлыйсы килгән иде. Әмма, ни хикмәт, гөлләр, чәчәкләр арасында эшләп утыруыгызны күреп, уйга калдым әле. Өстәлегездә тальян гармун булса, бу кадәр үк гаҗәпләнмәс тә идем, ә чәчәкләр?! Хатынызны да көнләштерерлек чәчәкләр бит...

— Чәчәкләрне, гөлләрне, гомумән, табигатьне мин бик яратам шул. Ләкин һәркайсын үзенчә яратам. Әлеге гөлләрнең, чәчәкләрнең күбесен сөекле хатыным Фәимә үстереп бирде. Моның өчен мин аңа бик рәхмәтлемен. Гөлләргә карасам, хатыным, балаларым күз алдыма килеп баса. Беләсезме, иң яраткан чәчәгем кайсы? Ромашкалар. Әнә, алар минем бүлмәдә дә бар. Ә иң яраткан агачларым каен белән миләш. Табигатьне яратам, дидем. Стенадагы картиналарда елның төрле фасыллары, табигатьнең төрле мизгелләре тасвирланган. Аларда безнең тормыш чагыла сыман. Кайда гына эшләсәм дә, бүлмәмдә гөлләр, чәчәкләр иде. Чәчәкләрдән культ ясадым кебек. Игътибар итсәгез, безнең коридорларда, аудиторияләрдә дә гөлләр, картиналар, фотообойлар бик күп.

— Сезнең сүздән гөлләрне, каен белән миләшне хатыныгыз, балаларыгыз белән чагыштырган-дай тойдым...

— Уйлап карасаң, бәлки, чыннан да шулайдыр ул. Гомер дигән юлның никадәресе узылган, инде балаларым да үз сукмакларын таптылар. Бабай булдым, оныгым үсеп килә. Хәзер уйлап куям, гаиләм өчен күпме яшәгәнмен икән, дим?

— Узган гомерен күпләр кызганадыр ул, Рәис әфәнде. Әмма гомер юлыгызга сокланырга гына кала. Ялан кыр уртасында калыккан шәһәр — Чаллы, Кама автогиганты үзе җуелмас тарих. Анда яшәүчеләр сезнең исемне олы хөрмәт белән телгә алалар бит.

— Чаллы шәһәре, Тукай районы халкына мин үзем дә рәхмәтлемен анысы. Унбиш ел буе бер уй-максат белән хезмәт иттек, шатлык-борчуларны булган ризыкны бүлешеп яшәдек. Бу төбәктән китүемә ун елдан артык вакыт узган булса да онытмаганнар икән. Әле менә халык депутаты итеп сайладылар. Хәзер сайлаучыларымның мәнфәгатен кайгырту, аларның ышанычын аклау уе белән яшим һәм эшлим. Бу ярдәм, әлбәттә, матди үлчәмнәр белән билгеләнми. Иң элек ул без кабул иткән законнарда чагыла. Җәмгыятебез, халкыбыз тормышында әлеге законнарның нинди мөһим роль уйнавын һәркайсыбыз аңлый булыр. Шуңа да мин законнар халкыбыз файдасына эшләргә тиеш дигән карашта торам. Парламенттагы бердән-бер ректор-депутат, галим һәм практик буларак, мин һәрбер законны кабул иткәндә актив катнашам. Аерым комиссия составында фән һәм югары уку йортлары мәсьәләләре белән бәйле эш белән шөгыльләнәм. Депутат булуның минем өчен отышлы ягы да бар, ул — республикабыз, халкыбыз тормышына тагын да якынрак килергә булган тәҗрибәмне мөмкинлекләремне эшкә җигәргә ярдәм итә. Республикабызда илдә, дөньяда нинди үзгәрешләр барганын белә торып, кабинетта гына утырып эш итү миңа кысан иде.

— Аңлавымча, сезгә эшчәнлек өчен киң мәйдан кирәк.

— Табигатем белән мин шундыйдыр инде. Урман-кырларны болыннарны яратуымның да, чыгышым буенча авылдан булуымның да йогынтысы бардыр дип уйлыйм. Казан дәүләт университетының юридик факультетында укыганда ук мин комсомол эшендә актив катнаша идем. Комсомолның өлкә комитетында җитәкче вазифаларын башкарганда республикабыз авыл-районнарында, илнең зур төзелешләрендә, чит илләрдә еш булырга туры килде. Амурдагы Комсомольски шәһәре, Братски, Түбән Кама ГЭСлары, Зәй ГРЭСы, Түбән Кама, Волжски заводлары төзелешләрендә булу миңа зур тәэсир иткән иде. Андагы романтика, кешеләрнең бердәй уй-омтылыш белән яшәүләрен һәм эшләүләрен сөйләп кенә бетерерлек түгел, әлбәттә. Комсомолда мин җиде ел эшләдем, финанс-экономика институтында укып, төзелеш белән бәйле белгечлеккә ия булдым. Фәнни эш белән мавыгып китеп, философия буенча кандидатлык диссертациясе якладым. Эшчәнлегебез шул чорга хас булганча, партия белән үрелеп барган чаклар иде ул. Партия кая кушса, без шунда барырга тиеш идек. Комсомолдан соң Бауман райкомында бер ел чамасы эшләп алгач, Кама автогиганты төзелешенә партиянең Чаллы шәһәр комитеты секретаре итеп җибәрделәр. Ул чакта миңа 34 яшь иде. Анда дүрт елга гына барасың диделәр — унбиш елга сузылды. Барып урнашканда егерме ике мең кешесе булган авыл иде ул. Хәзер ак калада ярты миллионнан артык халык, сиксәнләп милләт вәкиле яши.

— Хәзер мин «гаиләм өчен күпме яшәгәнмен икән» дигән фикерегезнең асылына төшенәм кебек. Сезгә җиңел булмагандыр шул, Рәис әфәнде.

— Югалтулар булды инде. Чаллыга иң элек үзем генә барып урнаштым. Аннары гаиләмне алып килдем. Балалар укырга да кермәгән иде әле. ЭВМ заводында инженер-химик булган хатыным эшен төзелеш канцеляриясендә кәгазь-документлар тутырып утыручы хезмәткәр буларак дәвам иттерде. Балалар тәрбияләп өйдә генә утырыр иде, алай яшәргә күнекмәгән. Шәһәрдә тормыш-көнкүреш өчен уңайлыклар мактанырлык түгел иде. Шуның өстенә ел саен диярлек илебезнең төрле төбәкләреннән йөз илле меңләп кеше эшкә килә. Аларның күбесен, әлбәттә, вакытлы вагоннарга урнаштырырга туры килде. Шуңа да бөтен көч автогигант төзелеше белән бергә социаль мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелде. Елга 550 мең квадрат метр торак мәйданы, бишәр мәктәп, уналтышар балалар бакчасы файдалануга тапшырылды. Унбиш елдан соң шәһәрдә бер генә вагон да калмаган иде инде. Әнә шул елларны торгынлык чорына кертеп безнең рәнҗетәләр. Чынлыкта, никадәр асыл ир-атларыбыз, сылу хатын-кызларыбыз, ә күбесе яшьләр гаиләләре тормыш уңайсызлыклары хакында да онытып, хезмәт куйды, югыйсә. Аякларда резин итекләр иде.

— Хәзер әнә үзенчәлекле архитектурасы булган, чиста-матур Чаллыга карап кемнәр генә сокланмый икән.

— Һәрхәлдә, бу шәһәр башкалардан күп ягы белән аерылып тора. Архитекторлар, проектлаучылар, төзү материаллары белән тәэмин итүчеләр, төзүчеләр бу максаттан зур тырышлык куйдылар. Килгән кунаклар алдында аерата горурланып сөйләрлек, күрсәтерлек йортларыбыз, биналарыбыз да бар иде әле.

Мин үзем матур итеп нәкышләп эшләнгән борынгы өйләргә сокланам. Казан үзәгендә алар аеруча күп. Андый йортлар яныннан узганда үземне музейда йөргән кебек хис итәм. Аларны төзекләндереп, буяп-агартып та җибәрсәң... Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев башкалабызның тарихи өлешен, Кремльне саклау, төзекләндерү буенча указ кабул итеп бик кирәкле һәм акыллы эш башкарды. Бүгенге һәм киләсе буыннар өчен бу бик мөһим дип саныйм. Кызганыч, соңгы елларда төзелгән байтак торак йортлар, административ биналар шулкадәр бертөрле, хәтта алар арасына кереп югалып каласың. Ә бит үзебезгә дигәндә, булдырабыз. Ул котеджларга, бакча йортларына сокланып туймаслык бит. Матур, кабатланмас йортлар салып куябыз.

— Сезнең бакчагыз да, Рәис әфәнде, күз явын алырлыктыр әле?

— Алай ук димәс идем. Гадәти генә бакча ул. Әлегә кадәр төзеп кенә бетерә алган юк. Малайларым белән шунда ун ел кайнашабыз инде. Мин күбрәк язу, уку, концерт-театрларга йөрү, оны зурләрне оештыру белән мәшгуль. Миңа шулар бу сын. Башкалар коттеджлар, зур-зур сарайлар салып чыкканда, кул кушырып утыруыма гаҗәпләнүчеләр дә бар, әлбәттә. Шәхси тормышта мин бу ганына шөкер итеп яшәргә күнеккәнмен. Яңа фатир бирегез, дип тә сораганым булмады хәтта. Шедән калганында яшәдек. Коттедж булсын дип тә кызыкмыйм. Ял итеп кайтырга, җимешеннән авыз итәргә бакчабыз булгач, шул җиткән, дим. Үземә, гаиләмә дигәндә, миннән дә буш кеше юктыр.

(Ахыры 6 нчы биттә).

Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар
5 6 7 1 2 3 4

Русия Дәүләт Думасына Белдерү

21 ноябрьдә Татарстан Дәүләт Советы Президиумының чираттагы утырышы булды. Анда Русия Федерациясе Дәүләт Думасы адресына Белдерү кабул ителде.

Бу документ Федерация эшләре һәм региональ сәясәт комитетының һәм Дума Советының федераль хакимият органнары белән Русия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары арасында уртак эшләрне һәм вәкаләтләрне бүлешүнең гомуми башлангычлары турындагы федераль закон проектын утырышта карарга җыенулары нәтиҗәсендә туды. Бу проектны депутат В.Михайлов тәкъдим итте. Белдерүдә түбәндәгеләр искәртелә: шушы елның 14 июнендә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе үзенең белдерүендә Дәүләт Думасы депутатларының игътибарын әлеге закон проектының республикаларның Русия Федерациясендәге дәүләтләр статусын исәпкә алмавына, Русия Федерациясе белән Татарстан Республикасы арасында ике яклы Шартнамәне — Үзәк белән төбәкләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең халыкара күләмдә танылган моделен санга сукмавына юнәлткән иде.

Федераль закон проектында Русия Федерациясе Конституциясенең идеяләрен башка шартнамәләрдә килешү һәм беркетмәләрдә үстерүне асылда тыю Русия Конституциясенең 5 һәм 11 нче статьяларына каршы килә. Федерациянең һәм аның субъектларының конституцион хокукларын чикли. Шулай итеп закон проектының күп статьялары Русия Федерациясенең гамәлдәге Конституциясенә һәм урнашып килүче Русия федерализмына каршы килә: алар Федерация белән республикалар, крайлар һәм өлкәләр арасындагы ике яклы Шартнамәләрне асылда юкка чыгаруга юнәлдерелгән.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы шуңа тирәнтен ышана: бу закон проектын Дәүләт Думасында тикшерү фактына үзе генә дә инде Үзәккә каршы тискәре фикер китереп чыгарырга мөмкин. Чөнки ул Федераль Үзәк белән Федерация субъектлары арасындагы мөнәсәбәтләрдә урнашып килгән ышаныч һәм хезмәттәшлек атмосферасын какшата, диелә Белдерүдә. Татарстан Дәүләт Советы Президиумы бу закон проектын тикшерүдән алдырыны тәкъдим итә.

Утырышны Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.Харисов алып барды.

Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры

Атналык программа:

24 җомга	ПРЕМЬЕРА Ш.Фәрхетдин **ЙОЛДЫЗЛЫ ЯҢГЫР!!!** **(Звездный дождь)** Концерт-тамаша-концерт 2 сәг. бара
25 шимбә (көндез)	Туфан Миңнуллин **ГАРМУН УЙНЫЙ БЕЛӘСЕҢМЕ?** **(Играй, гармонь!)** Музыкаль комедия 2 пәрдәдә 1 сәг. 40 мин. бара
25 шимбә (кич)	Нурихан Фәттах **ИТЕЛ СУЫ АКА ТОРУР** **(Пока течет Итель)** Ф.Ситдыйков инсценировкасы 2 пәрдәдә 1 сәг. 50 мин. бара
26 якшәмбе (көндез)	Разил Вәлиев **ӘЙДӘ БАРЫЙК, КЫЗЛАР КАРЫЙК!** **(Девушки-красавицы)** Музыкаль тамаша 2 пәрдәдә 1 сәг. 40 мин. бара
26 якшәмбе (кич)	И.Грекова **ТОЛ ХАТЫННАР КӨЙМӘСЕ...** **(Инсценировка по мотивам повести И.Грековой «Вдовий пароход»)** Ф.Ситдыйков инсценировкасы Драма 2 пәрдәдә 2 сәг. 45 мин. бара
28 сишәмбе	Наил Гаетбай **ӘСТӘГЪФИРУЛЛА...** **(Боже мой)** Комедия 2 пәрдәдә 1 сәг. 40 мин. бара
29 чәршәмбе	Эсфир Яңудин **МӘХӘББӘТКӘ МӘДХИЯ** **(Ода любви)** Моңсу комедия 2 пәрдәдә 1 сәг. 45 мин. бара
30 пәнҗешәмбе	КОНЦЕРТ-ТАМАША Узган һәм килачәк сезоннарга багышланган 2 сәг. 10 мин. бара

Спектакльләр көндез 12 сәгатьтә, кич 19 сәгатьтә, шимбә, якшәмбе һәм бәйрәм көннәрендә 18 сәгатьтә башлана.
Театр кассасы 10 сәгатьтән 19 сәгатькә кадәр эшли.

Тагын бер сәнгать үзәге

Узган атнада калабызда тагын бер сәнгать үзәге ачылды. Идел буе районында элеккеге «Чулпан» кинотеатрында «Казан» милли мәдәният үзәгенең филиалы эшли башлады. Ул шушы төбәктә яшәүчеләрнең мәдәнияткә, сәнгатькә булган ихтыяҗын истә тота. Үзәктә бию ансамбле эшли, яшьләр өчен дискотекалар уздырыла, күргәзмәләр оештырыла, танылган шәхесләр, артистлар белән очрашулар көтелә.

Президент баш мөфтине кабул итте

20 ноябрьдә Татарстан җөмһүриятенең Президенты М.Шәймиев Русия һәм БДБ илләренең Аурупа өлеше мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте баш мөфтие Тәлгать Таҗетдинны кабул итте. Әңгәмә барышында мөселман җәмгыятьләренең бердәмлеген ныгытуга, үзара килешеп эшләүләренә кагылышлы мәсьәләләр күтәрелде. Баш мөфти Татарстан территориясендә һәм Русиянең башка төбәкләрендә дини уку йортларын һәм алардан кадрлар әзерләүне арттыру зарурлыгын белдерде.

Татарстан җөмһүрияте Президенты аның тәкъдимнәрен игътибар белән тыңлады. Үзәк Диния нәзарәте Казан Кремле территориясендәге мәчетне торгызуда турыдан-туры катнашса иде, дигән теләк белдерде.

Китапка — дәүләт кайгыртуы

22 ноябрьдә Дәүләт Советында «Татарстан Республикасында китап нәшер итүнең торышы турында» парламент тыңлавы үткәрелде. Анда китап нәшрияты, матбугат хезмәткәрләре, кайбер министрлыклар вәкилләре һәм халык депутатлары катнашты.

Мәгълүм ки, кыргый базар шартларында бәяләрнең котырынып үсүе нәтиҗәсендә китап чыгару һәм аны укучыга ирештерү хәл итеп булмаслык мәсьәләгә әйләнеп бара. Мондый шартларда бигрәк тә татар китабына зур хәвеф яный.

Китапның язмышы дәүләт дәрәҗәсендә хәл ителергә тиеш — киңәшмәдә чыгыш ясаучыларның уртак фикере әнә шундый иде.

Өстәлдә ак кәгазь...

Чаллыда яшәп иҗат итүче язучыбыз, «Аргамак» журналының баш мөхәррире Айдар Хәлимгә:

— Соңгы вакытларда каләмегездәнниләр тама? — дигән сорау белән мөрәҗәгать иттек.

— Урыс-чечен сугышы турында «Все тот же он непобедимый...» дип аталган мәкаләләр шәлкеменең соңгы өлешен язам — диде Айдар әфәнде безгә биргән җавабында. — Ул «Кайся Русь!» дип атала. «Аргамак» журналында басылып килә. Мин монда урысның нинди милләт. Русьның һәм Русиянең нинди дәүләт булуы турында сүз алып барам. Безнең күп бәлаләрнең башы минем карашка һәм Аурупа дәүләтләре күзлегеннән караганда урысның — милләт Русьның дәүләт булмавында. Кимсетүдән түгел бу. Әлеге халык — славян-төрки кушылмасыннан килеп чыккан симбиоз түгел микән. Шул хакта уйланып йөргән һәм язган көннәрем...

«Әл-зәкат» Суомига җыена

Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев җитәкчелек иткән «Әл-зәкат» ансамбле гиздән Финляндиягә китәргә җыена. Ансамбль шунда гомер итүче милләттәшләребез алдында чыгыш ясаячак.

Җомгадан — җомгага

ҖӨМҺҮРИЯТ ЕЛЪЯЗМАСЫНА ҖӨМЛӘЛӘР

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Кремльдә Аурупа берлегенең Региөннар палатасы рәисе, Швейцария һәм Женева кантонының эчке эшләр, тирә-як мохит һәм региональ сәясәт министры Клод әфәнде Эгины кабул итте.

Чаллы тарих музеенда «Бөек Болгар җилләре» дип аталган күргәзмә ачылды.

Мәскәүдә яшүсмерләрнең туризм үзәге һәм «Мәгариф» татар иҗтимагый оешмасы оештырган яшь этнографлар слеты булып үтте.

Казан серкә заводында горчица җитештерелә башлады.

«Әтнә таңы» район газетасы компьютерда эшләнеп нәшер ителә башлады.

Татарстан Фәннәр Академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының кульязмалар һәм текстология бүлеге галимнәре танылган язучылар белән очрашып, мәрхүм каләм осталарының шәхси архивларын саклау юкалганнарын ничек тә булса халыкка кайтару турында сөйләштеләр.

29 ноябрьдә Татарстанда «Иман» ислам мәдәнияте үзәге тарафыннан оештырылган Ислам мәдәнияте көннәре үткәрелә.

«Заман»ныкы заманча

Шушы көннәрдә Татар дәүләт филармониясендә эшләүче «Заман» егетләре башкаруында яңгыраган җырлардан торган компакт-диск чыкты.

Компакт-дискка 12 җыр кертелгән. Алар арасында татар халык җырлары һәм композиторларның популяр җырлары бар.

Шунысын да әйтергә кирәк: «Заман» егетләре Татарстанда беренче булып компакт-диск чыгарырга өлгерде.

Ельцин да, Ленин кебек, Казанда торган

«Комсомольская правда» газетенең язуына караганда, Казанда уникаль тарихи объект табылган. Караганда урамындагы йортта (элек ул 6 нчы Союз урамы булган) заманында Борис Ельцин гаиләсе яшәгән икән. «Президент язмалары» дигән мәгълүм китапта ул чор турында бер-ике җөмлә белән генә әйтелгән. Ә бит биредә гаилә башлыгы Николай Игнатьевич Казан авиация заводын төзешкән (анда хәзер мәшһүр «ТУ»-лар эшләнә), аннары әлеге дә баягы 58 нче маддә нигезендә шушында ук өч ел төрмәдә утырып чыккан.

Шушы йортта, дип искә ала Казандагы кодагыйлары Нина Васильевна Сурова, совет власте яшәүгә мөмкинлек калдырмагач, аның әти-әниләре ябык кына гәүдәле яшүсмер Борис белән әнисе Клавдия Васильевнаны үз яннарына сыендырганнар. Боренька бик сүз тыңлаучан, тыныч бала булып исендә калган. Уенчыклар булмау сәбәпле, малай утын агачлары тезеп, шулардан идәндә «кварталлар» ясый торган булган (менә каян килә икән ул Ельциндагы төзүче күәсе!)

Йозьяшәр китапханә

Троицки шәһәрендә (Чиләбе өлкәсе) халыкка йөз елдан артык хезмәт итеп килүче татар-башкорт китапханәсе бар. Соңгы елларда ул татар һәм башкорт әдәбиятын пропагандалау очрашулар, әдәби-музыкаль кичәләр оештыру, гәзит-журналлар тарату, татар телен өйрәтү, дини дәресләр оештыру эшен шактый активлаштырды.

Хәтер конене багышлап китапханә «Татар халкы тарихы» дигән исем белән зур стенд әзерләдә һәм укучыларга анда тупланган мәгълүматлар буенча әңгәмәләр үткәрүне җайга салды.

Бу эшләрне башлап йөрүче китапханә мөдире, Татарстанда туып-үскән һәм белем алган Түбән Кама кызы Рәсимә Нашаровага чиләбеләләр чиксез рәхмәтле.

Бер тәңкәлек «эш»

«Маяк» радиосының хәбәр итүенә караганда, кеше хокукларын яклаучы Кронид Любарскийны (ул соңгы вакытта «Новое время» атналыгының баш мөхәррир урынбасары иде) Русия Дәүләт Думасы Җәүһәр Дудаевтан ришвәт алуда гаепләгән. К.Любарский үзенең кешелек дәрәҗәсен яклап Думаны судка биргән. Суд аның дәгъвасын канәгатьләндергән суратта, Дума Любарскийга 1 сум (бер сум) акча түләргә тиеш икән.

— Нишләп инде шундый гына бәя куйдың? — дип сорагач, Любарский:

— Миллионнар сорасам, аны барыбер халыктан талап җыячаклар бит, — дигән.

Имөкатдәс моң!

18 декабрьдә К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында өнә шундый исем белән концерт булачак. Аны Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе оештыра. Концертта Русиянең һәм Татарстанның халык артистлары Тукай бүләге иясе Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров, Айрат Арсланов, Татарстанның халык артисты Рәшит Сабиров, Татарстанның атказанган артистлары Габдулла Рәхимкулов, Флера Сөләйманова, Рабига Сибгатуллина, «Татар җыры-95» халыкара конкурсы лауреаты Закир Шаһбанов һәм Татарстан җөмһүриятенең Анатолий Шутиков җитәкчелегендәге халык уен кораллары оркестры катнаша.

Әй, Кукмара, туфрагыңнан ерагаймасын ара!

Узган атнаның җомгасында Кукмара мәдәният йортында зур бәйрәм-тантана-очрашу булып узды. Әлбәттә, мондый тамашалар җомһүриятебез районнарында күп тапкырлар үткәрелдә инде. Һәр төбәкнең горурланырлык, мөкиббән китәрлек тарихы — үткәне, бүгенгесе, киләчәге бар. Кукмараның да шатланып, сөенеп, горурланып билгеләп үтәрдәй шанлы үткәннәре, мәшһүр шәхесләре, мактанырлык гамәлләре бар. Без әйткән кичә Кукмарага нигез салынуга 400 ел, район оешуга һәм гәзите чыга башлауга 65 ел тулуга багышланган иде. Ике матур тау битен соеп, сызып, челтерәп аккан күз яшьләредәй саф, чиста һәм пакь сулы Нурминкә инеше Кукмара дигән нурлы төбәкнең үзе кебек үк гаҗәеп зур тарихи сынаулар, газаплар, михнәтләр аша узган. Инде менә Кукмара төбәге гасырларны кичеп, үз халкына янә хөрмәт күрсәтә. Ниһаять, ошбу туфрак та үз балаларын соеп, җыр, бию, моң, чәк-чәге белән каршы ала. Һәрхәлдә шунысы ап-ачык: Күктау дип юкка гына атамаган сине халык. Син чыннан да хыяллар иле, шигъри таулар төбәге! Ошбу бәйрәм-тантана-очрашудагы җылы сүзләр, әңгәмәләр, якты хатирәләр мәңге истә калсын иде. Бер-береңне сөй, ярат, татар баласы! Җиде миллионлы халык дип аталсаң да, син чәчелгән, син таралган, син сибелгән милләт әлегә. Бер оешырсың шулай, бер күтәрелерсең, әүвәлгечә зур милләт булып янә киләчәккә табан атларсың шулай. Кукмара район администрациясе башлыгы Мөхәммәт әфәндә Гатиятуллин кебек ипле, олпат җитәкчеләр идарә итә торган төбәк тә ул безнең Кукмара. Шуның өстенә Мөхәммәт әфәндә бер дигән оратор, нәфис сүз остасы да икән әле. Якташлар очрашкан кичәне өч телдә — татар, урыс һәм удмурт телләрендә ачып җибәргән бу җитәкченең садә холкы, җор күңеллелеге, туган телен мөкәммәл белүе мөкиббән итте күпләрне.

Үз чиратында без Мөхәммәт әфәндә үзе дә «Мәдәни җомга»ның мөштәрие булыр һәм безнең гәзитне танытуда көченнән килгәнчә ярдәм итәр дигән теләктә калабыз.

Заһид МӘХМҮДИ.

Төсләрдә — шигъри тәлгәшләр

Иҗат, сәнгать һәрчак вакыт галиҗәнаплары ихтыярында һәм андагы икенчел, ясалма нәрсәләр онытыла, төшеп кала.

Николай Индюхов рәсемнәре кичә дә, бүген дә тамашачы күңеленә хуш килә, чөнки алар югары профессиональ кимәлдә иҗат ителгән.

Рәссам тосләр аша уйлана һәм аңа «сүндерелгән» тосләр хас. Аеруча аның натюрмортлары игътибарны җәлеп итә. Бу рәсемнәрдә тынлык хөкем сөрә һәм ул тамашачыга уңай тәэсир итә. Н.Индюхов гади генә нәрсәләрдә дә җырлап торган шигъри тәлгәшләрне һәм гүзәллекне тотып ала белә.

Рауза СОЛТАНОВА.

● Н.Индюхов үзенең остаханәсендә.

Арсланга ярдәм кирәк

Күптән түгел Зеленодолда «Яшел үзән сандугачы» дигән конкурс булып узды. Анда 10 яшьтән 17 яшькәчә шәһәр һәм район балалары катнашты. Әлеге конкурста менә икенче ел инде Норлат балалар йорты укучылары актив катнаша. 9 нчы сыйныф укучысы Руслан Нагиев быел аеруча уңышлы чыгыш ясады, конкурста аңа тиңнәр табылмады. Ә Валя Осипова, тамашачы мәхәббәтен казанып, махсус призга лаек булды. Руслан (Арслан) милләте буенча әзәри. Ул татарча җырлап, Мәскәүгә «Таң йолдызы» телевизион тапшыруларына барырга лаеклы дип табылды. Тик ятим баланы Мәскәүгә җибәрердәй берәр игелекле зат табылырмы икән?

Шагыйрьнең иҗат бәйрәме

Җырларда җырланган гүзәл Минзәлә төбәгендә танылган шагыйрь Рәшит Гәрәйнең тууына 65 яшь тулуга багышланган әдәби атналык булды. Район хакимияте ярдәме белән үткәрелгән бу кичәләр шагыйрьнең туган авылы Малтабарда, Минзәләдә, Дәвек, Тауасты Байлар һәм Кадрәк авылы мәктәпләрендә һәм мәдәният сарайларында зур җанлылык белән узды. Район җәмәгатьчелеге, зыялылар һәм авыл хезмәтчәннәре шагыйрьгә зур хөрмәт һәм ихтирам күрсәттеләр.

Р.Гәрәйне котларга Казаннан да каләмдәшләре килде. Район үзәгендә һәм авылларда үзешчән сәнгать коллективлары җыр һәм биюләр белән шагыйрьнең иҗат бәйрәменә ямь өстәделәр. Шагыйрьнең сәмими һәм эчкерсез шигырьләрен һәр очрашуда яратып кабул иттеләр, аңа иҗат уңышлары, сәламәтлек теләделәр. Ул теләкләргә без дә кушылабыз.

Сара Садыйкованың пианиносын эзлибез

Хөрмәтле җәмәгать!

Сезгә зур үтенеч белән мөрәҗәгать итебез.

Татар халкының мәшһүр кызы Сара Садыйкованың мәдәни-хәйрия фонды композиторның булачак музеена экспонатлар җыя. 1986 елның июнь аенда Казан шәһәренең Киров урамындагы комиссион кибеттән сатып җибәрелгән «Казан» маркалы пианино Сара ханым Садыйкова истәлеге буларак сәнгатебез тарихы өчен бик кадерле. Әлеге пианиноны Сара Садыйкованың мәдәни-хәйрия фонды сатып алырга тели.

Хәбәрләшү өчен телефоннар 32-15-23 32-58-96, 43-31-46.

Киләсе елда мәдәният учагына күпме «утын» салыначак?

Үткән атнада Дәүләт Советында төгәлрәге бюджет-финанс мәсьәләләре буенча комиссиядә, Татарстан Президентының 1996 елга бюджет юлламасы тикшерелә башлады. Безне әлбәттә мәдәният-сәнгатькә күпме акча бирелачәге кызыксындыра.

Югарыда телгә алынган документта мәдәният-сәнгать өчен 84616 миллион сум акча бирү күздә тотыла диелгән. Шушы акча китапханәләр музей тыюлыклар республика фәнни-методик һәм фольклор үзәкләре өчен тотылачак. Театрлар концерт оешмалары һәм дәүләт циркына ярдәм итү өчен дә акча шушы «кесә»дән алыначак. «Казан Кремле» тарих-архитектура тыюлыгы корылмаларын саклау һәм торгызу өчен 12383 миллион сум бирү күздә тотыла шуның 749 миллионы — тыюлык дирекциясе ихтыяҗлары өчен. Язучылар һәм Композиторлар берлекләренә 800 миллион сум акча бирү күздә тотыла дип акка кара белән язылган. Массакүләм мәгълүмат чаралары өчен 45896 миллион сум акча каралачак, шуның 15424 миллион сумы оештыручылары дәүләт органнары булган республика гәзит-журналларын нәшер итүдән килгән зыянны каплау өчен тотылачак.

«Татарстан» телерадиокомпаниясенә шул исәптән (45896 миллион сумнан) 21300 миллион сум каралган.

Без бирердә мәдәният-сәнгатькә бирелә торган акчаның төп юнәлешләрен генә санап үттек. шуңа күрә күрсәтелгән суммаларны кушкач, иң алдан әйтелгән санның килеп чыкмавына шаккатмагыз.

Шунысын да искә төшерәбез, бу мәгълүмат бюджет юлламасыннан алынды, ә әлегә ул Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителмәгән. тикшерү барышында кайбер саннар үзгәрергә дә мөмкин.

Сәхифәдә редакциябез журналистлары, авторларыбыз, «Татар-Информ» һәм башка чыганаклар хәбәрләре файдаланылды.

ҖИРЕ БАЙНЫҢ ИЛЕ БАЙ

Фарсил-Сәхәби ЗЫЯТДИН,
язучы, икътисад фәннәре кандидаты

ТУФРАККА КҮҢЕЛ ҖЫЛЫСЫН БИРӘБЕЗМЕ?

Кешелек тарихын берәүләр тынычлык тарихы дип, икенче берәүләр сугыш һәм походлар тарихы, дип атый. Ләкин мин аны өзлексез бер көрәш — икмәк өчен, яшәү өчен көрәш тарихы дияр идем. Моннан меңнәрчә еллар элек киркәмән белән коралланган көрәшченең кулында бүген машиналар, катлаулы җитештерү җиһазлары. Ул, көрәшеп, бүгенге көнгә килеп җитте. Әйе, көрәшне туктатмаганга килеп җитә алды ул. Икмәк өчен көрәш — яшәү өчен көрәш бервакытта да туктала алмый...

Дөрес, башкачарак фикер йөртүче галимнәр дә бар. Имеш, тиздән бу көрәш нәтиҗә бирми башлаячак, басылачак. Ниһаять, 40-60 елдан кешелек яшәү чыганаклары җитмәүдән һәм әйләнә-тирә мохитнең зарарлануыннан, пычрануыннан акрынлап һәлак булачак, диләр



Дж.Форрестер, Д.Мидоуз, М.Месарович, Э.Пестель һ.б. күп кенә галимнәр. Ашыгыч нәтиҗә ясыйлармы? Шулайрак кебек. Ни өчен дисәң, кешелек әле көрәш юлының яртысын да үтмәде, ресурслар өчен, бигрәк тә икмәк өчен көрәштә әле мөмкинлекләрнең биштән бер өлеше дә файдаланмый. Моны Русия һәм Татарстан мисалында да ачык күрергә мөмкин.

Гомумән, соңгы ике йөз елда статистика Русиядә муллык булуы турында сөйләми. Моның төп сәбәпләреннән берсе — җирнең ныклы хуҗасы булмауда. Җиргә мөнәсәбәт Октябрь революциясенә кадәр дә кешечә булмады, аннан соң да. Хәтта бүген дә шундый ук хәл. Мондый хуҗасызлык Русия халкының тарихы, гореф-гадәтләре белән бәйләнгән булса кирәк. Дөресрәге, Русиядә икмәк өчен көрәшне күп очракта яңа җирләр яулап алу өчен көрәш алыштырган. Ә инде яңадан-яңа чит җирләр үзләштереп яисә яулап алып гомер кичергән халык искеләрен яңарту, аны тәрбияләү, карау турында артык уйламаган. Шулай итеп, җирнең кадере киткән. Чөнки басып алган җирләр бихисап булгач, ул, гомумән, иске җирләрнең уңдырышлылыгын күтәрүгә игътибар бирмәгән. Монысы бер булса, икенчедән, көн аралаш булып торган һәм эчү белән тәмамланган бихисап бәйрәмнәр дә җир эшләрен тиешенчә һәм кыска срокларда үткәрүгә комачаулый. Җир нәтиҗәле файдаланылмый, уңыш артмый. Өченчедән, гомумән, җирдә эшләүчеләрнең хезмәт активлыгы түбән булды. Ә соңгы алтмыш елда формалашкан хуҗасызлык, «уртак милек» хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да киметте. Димәк, менә шул сәбәпләр аркасында гасырлар буе формалашкан крестьян психологиясен, гадәтен үзгәртү өчен гаять зур тырышлык таләп ителә.

Күп кенә урыс икътисадчылары Русиядәге Совет чорын хурлап, патша Русиясе вакытын мактап, үрнәк итеп күрсәтергә тырышалар. Имеш, ул чакта Русия чит илләргә күпләп икмәк чыгарган, уңыш мул булган. Шулаймы соң? Инкарь итмим, Русия алпавытлары чит илләргә икмәк сатканнар. Ләкин бу илдән арткан икмәк түгел, халыктан арткан икмәк түгел... Мәгълүм булганча, елы-елы белән ун меңнәрчә крестьян ачлыктан кырылган. XIX гасырның кырык елында икмәк уңмаган һәм бу күпчелек очракта ачлык белән тәгәлләнгән. «Новое время» журналы 1891 елның 13 октябрь санында менә нинди мисаллар китерә:

«1880 — уңыш булмады; 1885 — уңыш булмады, саранча; 1886 — уңыш булмады, ачлык диярлек; 1887 — арыш юкка чыкты, сабан ашлыгы уртачадан түбән; 1888 — шундый ук хәл; 1889 — үләннәр начар; арыш юкка чыкты; сабан ашлыгы уртачадан түбән; 1890 — иген уңышы һәм үлән начар; 1891 — уңыш тулысынча булмады.

Шулай итеп, унике елның нибары дүрт елында гына уңыш азмы-күпме җыеп алынган. Крестьянның хәле елдан-ел начарлана бара. Әгәр дә XYIII гасырда 34 ачлык ел кабатланса, XIX гасырда ул 40 ка җитә, ә XX гасырда герман сугышына кадәрге унике елның җидесендә ачлык килә: 1901, 1905, 1906, 1907,1908, 1911, 1912 еллар. Ачлык булган регионнар саны арта һәм ишәя генә бара. Бары тик 1913 елда гына иң югары уңыш алына: һәр гектардан 12 центнер. Бу — Русия тарихында иң югары уңыш. Шуннан соң уңыш та, тормыш та тагын түбән тәгәри: 1916, 1920, 1921 елгы коточкыч ачлык еллар килә. 1921 елда Казан губернасы территориясендә һәр гектардан нибары 40 кг уңыш җыеп алына. Чәчкән орлыкның нибары биштән бер өлешен генә тәшкил итә бу Шуңа күрә, Русиядә халык мул тормышта яшәгән, икмәк муллыгы булган, дип сөйләшүнең уйдырма икәнен чамалап була. Югары катлам кешеләреннән тыш, Русиядә халык беркайчан да муллык күрмәгән, рәхәт яшәмәгән, дисәк, һич тә хата булмас. Яңа җирләр басып алып, буйсынырга теләмәгән халыкларны буйсындырып, талап кына рәхәтлеккә чыгып булмый. Бары тик аек акыл, тыныч тормыш, тырыш хезмәт кенә бәхет китерә. Өстен катлам гына түгел, ә бар халык күпмедер дәрәҗәдә рәхәт яшәсен өчен Русиядә Япония эшчеләре кебек эшләргә, Германия фермерлары кебек җирне, хезмәтне яратырга, Италия яисә Торкия эшмәкәрләре кебек сәүдә итә белергә, җитештерү мөнәсәбәтләрен Америка демократлары кебек көйләргә өйрәнергә кирәк. Җир байлыкның анасы булса, хезмәт аның атасы. Бу сүзләрне коммунизм байрагын күтәргән классиклар кабатлап әйтсә дә, дөрес әйтелгән. Хәер, алар сүздә һәрчак дөрес сөйләде. Тик кылган эшләренең генә сүздән аерылуы аяныч...

Русиядәге хуҗасызлык шаукымы безгә дә йогынты ясамый калмады, әлбәттә. Дөрес, безнең авыл кешесе тырышрак, җиргә ныграк тартыла. Авылдан китүчеләр дә азрак. Әмма байтак кына Конбатыш илләре белән чагыштырганда әле бик күп эшлисе бар. Терлек азыгы культураларыннан уңыш алу артса да, иген уңышы, реформа башланганчы, түбән кала бирде. Гомумән, игенчелек 1990 елга кадәр торгынлык кичерде. 1966-1990 елларда, ягъни чирек гасыр эчендә уңыш алу бөтенләй артмады диярлек. Әйтик, 1966-1970 елларда һәр гектардан уртача 14,3 центнер уңыш җыеп алынса, тугызынчы бишьеллыкта ул 12,8, унынчы бишьеллыкта 14,0, унберенче бишьеллыкта 15,5, уникенче бишьеллыкта (1986-1990) 15,8 центнер булды, нибары 11 процентка артты. Бу чирек гасырда бары ике тапкыр — 1986 һәм 1990 елларда гына кырларыбызда уңыш 20 центнерга җитте.

Бәлки, бездә революциягә кадәр, яисә колхозлашу елларында әйбәт уңыш үстергәннәрдер? Революциягә кадәр иң югары уңыш 1913 елда һәр гектардан 9,1 центнер алынса, 1917 елда — 4,7, 1920 елда — 2,7, 1921 елда — 0,4, 1922-1923 елларда — 4,8, 1924-1925 елларда — 5,2 шәр центнер булды. Ниһаять, 1933 елда уңыш 1913 елдагы дәрәҗәгә җитә, ягъни һәр гектардан 8,9 центнер үстерелә. Бу — күмәк хуҗалыклар ирешкән беренче җиңү. Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы авыл хуҗалыгы эшләрен (чәчү, урып-җыю, орлык салу) башкаруда, колхоз һәм совхозларны ныгытуда, дәүләт алдындагы йөкләмәләрен үтәүдә ирешкән күркәм уңышлары өчен 1934 елның 3 гыйнварында Ленин ордены белән бүләкләнә. Билгеле, иген уңышының 1932 елдагы 6,9 центнердан 1933 елда 8,9 центнерга кадәр җитүе, беренчедән, машиналарны күбрәк куллану (бу елны кырларда 2012 трактор һәм тарихта беренче тапкыр 220 комбайн эшли) нәтиҗәсендә барлык төр агрочараларның вакытында һәм сыйфатлырак итеп башкарылуы белән аңлатылса, икенчедән, бу җирнең «хуҗасы» — игенченең, колхозчыларның инициативасы, патриотик омтылышларының күтәрелеп киткән чагы. Әйе, колхозлашканнан соң крестьяннарның психологиясендә мондый үзгәреш булды һәм ул үзенең әйбәт нәтиҗәләрен күрсәтте Әмма колхозлашу елларында чамадан тыш кылану һәм арттырып җибәрүләр булмаса, авылның иң тырыш, иң эшчән, иң белемле кешеләре — урта хәлле крестьяннар кулак ярлыгы тагылып Себергә озатылмаган булса, уңышлар тагын да куанычлырак булыр иде. Әгәр җентекләбрәк анализлап карасаң, кулак ярлыгы тагып куылган кешеләрнең абсолют күпчелеге хезмәт сөючән, эшнең рәтен, җирнең кадерен белүчеләр бит Шуңа күрә дә алар, җирдән нәтиҗәле файдаланып, Яңа икътисади сәясәт (НЭП) елларында үзләренең шәхси хуҗалыкларын ныгытып өлгергәннәр. Дуамал большевиклар сүзе белән әйтсәк, баеп өлгергәннәр..

Бу елларда патриотизм хисенең үсеше «Правда» газетасында басылган «Татарстан большевиклары, алга, яңа җиңүләргә!» дигән баш мәкаләдә дә ачык чагыла (23 октябрь. 1932 ел) Анда «Бүген Татарстан республикасы икмәк хәзерләүнең еллык планын вакытыннан алда үтәве турында рапорт бирә... Һәр хезмәт көненә 10-12 шәр фунт икмәк бүленде. Пролетар революциясе дошманнары, штрейкбрехерлар һәм ренегатларының каркылдаулары Татарстан республикасының социалистик игенчелектәге гүзәл җиңүе алдында нәрсә ул?» дигән юллар бар.

Патриотик хисләр белән беррәттән, шушы ук мәкаләдә татар халкының авырткан җирен яклап та сүз әйтелә. Кемнән яклап? Инде җимерелгән патша Русиясеннән яклап, билгеле. «...Гасырлар буе Татарстан (Татарстан түгел, ә татар халкы — **Ф.З.**) урыс помещиклары һәм капиталистлары тарафыннан изелде һәм буылды, патша штыклары сагы астында татар хезмәт ияләре әйбәт җирләрдән кысып чыгарылды, промышленностьта квалификацияле эштән читләштерелде, югары һәм урта махсус уку йортларына якын җибәрелмәде...»

Бу мәкаләне укыйсың да гаҗәпләнәсең. Максатка ирешү өчен, пропаганда үтемле булсын өчен менә нәрсәгә кадәр барган ул елларның большевиклары. Чынлап та, мәкалә күтәренке рух, чакыру белән тәгәлләнә. «Татарстан большевиклары авыл хезмәт иясе массаларын алга, яңа җиңүләргә уңышлы алып барачаклар.Артта калучылар хәзер, әйдә, аларга тигезләнсеннәр».

Сүз дә юк, Татарстанда коллективлаштыру гаять кызу темплар белән алып барыла. 1930 елның 20 февралендә, ягъни язгы кыр эшләре башланыр алдыннан барлык хосусый хуҗалыкларның 72,1, ә җирләрнең 68,9 проценты (2 млн. 750 мең гектар) күмәкләштерелә. Ә менә Кайбыч, Минзәлә, Әгерҗе, Норлат районнарында, аерата «тырышлык» күрсәтеп, барлык хуҗалыкларның 98 — 87 процентын күмәкләштерүгә ирешәләр. Барысы 13668 хуҗалык кулак хуҗалыгы дип игълан ителә, аларның барлык мөлкәтләре тартып алына һәм колхозларга тапшырыла. Билгеле, күпчелек районнарда кирәгеннән артык «бөгү» гаять зур зыян китерә. ВКП(б)ның Мамадыш канткомы бюросы, мәсәлән, 1929 елның көзендә күмәкләштерүне 2-3 ай эчендә тәгәлләргә карар кыла. Монда бигрәк тә диктатка төп урын бирелә, үзиреклелек мәсьәләсе онытыла, крестьяннарны колхозларга көчләп кертәләр. Урта хәлле крестьяннарның да шактый өлеше кулак дип игълан ителә. И.В.Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» мәкаләсе дөнья күргәннән соң, билгеле, законсыз кулак дип игълан ителгән урта хәллеләр күмәкләштерүгә каршы көрәш ачып өлгерәләр. Моннан соң инде күмәкләштерүне аерата кыен шартларда алып барырга туры килә. Таралган колхозларны яңадан җыю башланып китә. Нәтиҗәдә, инде 1930 елда ук яуланган күрсәткечләргә бары тик 1932 елның 1 гыйнварына гына ирешелә. Мәсәлән, бу вакытка 3884 колхоз (шул исәптән 34 коммуна, 82 иптәшлек җәмгыяте, 2112 артель) төзелеп, күмәкләштерү 64,4 процент тәшкил итә... һәм 1934 елның 30 ноябренә ул 77,9 процентка җитә, ягъни бу елларда күмәкләштерү инде акрынлап, көч кулланмыйча гына алып барыла башлый. Шулай да Азнакай, Зеленый Дол районнары күмәкләштерүне тулысынча тәгәллиләр. Күп кенә районнарда хосусый хуҗалыклар әле 1936-1939 елларда да шактый исәпләнә. Ләкин төрле санкцияләр куллану, зур налоглар салу нәтиҗәсендә алар үз җирләреннән баш тарталар һәм акрынлап эреп юкка чыгалар.

(Дәвамы бар).

КҮЗГӘ-КҮЗ КАРАП

Мин гомер буе үзем өчен яшәмәдем бугай

Рәис БЕЛЯЕВ,
Казан дәүләт сәнгать һәм мәдәният академиясе ректоры, академик:

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

— Тормышта үзе өчен генә көн итүчеләр дә, җәмгыять мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәүчеләр дә бар. Сезнең шундыйларның икенчесенә керүегезгә торган саен ныграк инанасың. Әгәр дә сез башкарган эшләрне, башыгыздан узганнарны кәгазьгә төшерергә мөмкин булса, үзе бер дәвамлы әсәр булыр иде, могаен.

— Кама автогиганты, Чаллы төзелеше хакында, әйтик, үз вакытында байтак әсәрләр иҗат ителде анысы Шул исәптән, минем дә өч китабым дөнья күрде Хәзер аның чираттагысын язам Хәтердә сакланган матур мизгелләрне киләсе буын укучысына җиткерү тарих күзлегеннән караганда да бик урынлы булыр иде. дип уйлыйм Удар төзелеш елларында бу төбәктә кемнәр генә булып китмәде бит танылган язучылар, актерлар, җырчылар, спортчылар, хәтта космонавтлар, чит ил кунаклары да Бу төбәккә эшләргә килүчеләрнең рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә дә зур әһәмият биреп килдек Концерт-тамашаларга йөрү төп эшебезнең аерылгысыз бер өлеше итеп карала иде Төзүчеләр алдында Мәскәү Казан театрлары актерлары күп мәртәбәләр чыгыш ясады Нур өстенә нур өстәп. халык талантларына — төрле милләт вәкилләреннән тупланган үзешчән коллективларга ул чакта ук киң мәйдан ачтык Халык мөмкин кадәр тулы канлы тормыш белән яшәсен. үзләрен кыр уртасында онытылганнар итеп тоймасын өчен мөмкин булганның барын да эшләргә тырыштык, әлбәттә һәм ул эзсез югалмады кыска гына вакыт эчендә камазлылар республикабызны дөньяга таныттылар, ә андагы иҗат коллективлары әле дә булса иң яхшылардан санала.

— Монда, Рәис әфәнде, сезнең өлешнең дә зур булуын билгеләп үтәргә кирәктер. Сез анда үзегезне оста оештыручы, төзелеш эшләрен, кешеләрнең холык-фигыльләрен яхшы белүче буларак кына түгел, җиңел куллы гармунчы итеп тә таныттыгыз шикелле.

— Ул гармун белән мин мәктәпкә укырга кергәнче үк мавыга башлаган идем инде Чаллыда эшләгән чакларымда тальян гармунын һәрчак машина багажнигында йөрттем. Байтак кешене җырлатты, биетте. күңелен күтәрергә булышты ул Мәскәүдән килгән хөкүмәт җитәкчеләренең, иң кырыс саналганнары арасында да тальянны сузганым булды. Яраттылар Халкыбызның моңлы көйләре аларның күңелен дә җилкендерә иде. Гармуннан әле дә булса аерылганым юк, алар барысы бишәү, өйдә тора Эштә вакытта мин күбрәк студентларның уйнаганын тыңларга яратам Гаиләбездәге алты ир-егетнең барысы да гармунчылар булгач, бу уен корапының сихри моңнары миңа аеруча якын Яшьләр дә тальян гармунны, халкыбыз моңнарын онытмасыннар иде дим.

— Гармунчы элек-электән мәҗлес күрке. Кем әйтмешли аларга кызлар күзе дә ешрак төшә, сый-хөрмәте дә мулрак эләгә...

- Безнең татар халкы кирәгеннән артык кунакчыл (шул исәптән гармунчыга карата да), дияр идем Табынга төрле ризыклар, эчемлекләр чыгарып куялар Шуның өстенә хуҗа кеше «Әйдә, аша инде авыз итмәдең бит, эчеп куй әле», — дип, колагыңа сыерчык булып керә инде Рюмкасына тикле кулына тоттыралар Андый вакытта икенең берсен сайлыйсың инде...

Чаллыда эшләгәндә миңа бик күп кунаклар кабул итәргә туры килде Чоры шундый иде, табынга шешәсен дә чыгарып куймый булмый Инде кунак хөрмәтенә тост әйтмәсәң, шулай ук дөрес аңламаулары бар Кыскасы, мәҗлесендә дә утырырга, тостын да әйтергә йотып та җибәрергә туры килде Ләкин унбиш ел Чаллыда эшләп, авызга бер грамм спиртлы эчемлек алмадым Табындашларга баштарак бу бик сәер тоела иде, ахрысы Соңрак артык игътибар бирми башладылар Рюмка белән су эчеп утырганны беләләр иде инде Шул вакытта эчүгә тартылган булсам, мин әллә кайчан кешелектән чыккан идем бит Менә шулай сөйләшеп утырырга да насыйп булмас иде әле Хәтта Чаллы кибетләрендә ресторанында спиртлы эчемлекләр сатуны туктатып. «коры закон» керттек Бик күп гаиләләр яшьләр өчен андый чараның да ярдәме тими калмагандыр, дип уйлыйм Һәрхәлдә спиртлы эчемлекләргә хирыс кешеләргә егылып эчәрлек шартлар юк иде

80 нче елларда кабул ителгән «Эчкечелеккә каршы көрәш» турында указ да аптыраганнан эшләнгән чара иде Шундый зур илдә дистә еллар буе тамыр җәйгән яман гадәтне бер указ белән генә йолып ташлап булмавын Президент үзе дә аңлаган булгандыр Монда кеше иң элек үзе уйланырга, нәтиҗә ясарга тиештер, минемчә Кеше — чәчәк, гөл кебек бит ул Һәм шулай булып калсын да иде

— Ата-анаңның спиртлы эчемлек белән мавыкмавы балаларына да үрнәк бит әле ул. Җырга-моңга осталыгыгыз да улларыгызга күчми калмагандыр, могаен.

— Шулай берчакны малайларымның музыка мәктәбенә йөрүләре турында сөйләшкәндә «берничди сәләтләре юк. горком секретаре балалары булгангa гына йөрмәсеннәр» дигән сүз ычкындырган идем Соңыннан малайларым «Әти, нигә шулай дип әйттең?», диләр Ә мин аларга «Табигать биргән таланты булган кеше әллә каян күренә». — дим Алар мине аңладылар бугай Дөрес, әлегә мәктәптә берсе скрипка. икенчесе баян буенча йөрүләрен дәвам иттеләр Әмма да сәнгать юлыннан китмәделәр Айрат улым хирург-уролог белгечлеген сайлады Айдарым авиация институтын тәмамлады, хәзер инженер-конструктор КамАЗның Париж-Пекин авторалли командасында техник мәсьәләләр буенча җаваплы белгеч Болай әйбәт кенә тәрбия алдылар сыман. Алар өчен күңелем тыныч.

— Рәис әфәнде, сезнең күңел тыныч булса да, үзегез бик тә тынгысыз кешегә охшагансыз. Шулай булмаганда, тагын бер авыр эшкә — мәдәният институты ректоры вазифасын башкарырга алыныр идегезмени? Ни өчен бирегә килергә уйлавыгыз да кайберәүләр өчен сер булып калды.

— Үз гомеремдә миңа эш эзләп йөрергә туры килмәде Партия өлкә комитетыннан эштән киткәндә, миңа берничә урын тәкъдим иттеләр Мин, әлбәттә, икеләнеп тормадым, монысын сайладым. Яшьтән үк сәнгатькә гашыйк булгач, Чаллыда чакта мәдәният-сәнгать әһелләре белән еш аралашып яшәгәч фундаменталь белемем дә бар, миңа иң кулай урын шушы иде Дөрес, эшне башлаганда үземә бернәрсә җитенкерәми иде ул да булса, уку-укыту процессы белән бәйле тәҗрибә Тора-бара анысына да ирештем кебек Ректор булып эшли башлавыма да ун ел булып килә Укытучы-педагоглар белән уртак фикердә торып эшлибез, үзем дә студентлар алдында лекцияләр укыйм.

— Институт кыска гына вакыт эчендә зур сикереш ясады, хәтта академия статусы алды. Бу студентларга сәнгать дөньясында яңа офык ачылды дигән сүз түгелме соң?

— Бу очракта, мин иң элек үзебезнең коллективка олы рәхмәтемне әйтер идем Һәр әйбәт башлангычны алар хупладылар, аны тормышка ашыруда үзләреннән өлеш керттеләр һәм хәзер дә шул юнәлештә бөтен көчләрен куеп хезмәт итәләр Эшли башлаган вакытларда профессиональ татар театры актерлары әзерләп чыгару буенча бер бүлек ачарга дигән теләк бар иде Аңа да ирештелдә Соңыннан ул факультет дәрәҗәсенә үсте Хәзер ул уңышлы эшләп килә Аңа күренекле режиссерыбыз, профессор Марсель Сәлимҗанов җитәкчелек итә Факультетта Казан театрларының тәҗрибәле актерлары белем бирә Әгәр дә яшь актерларны элеккеге кебек Мәскәүдә генә укытсак, бу иң элек студентлар кесәсенә бик нык сугар иде Укыткан өчен генә дә миллионнарча сум акча түләргә кирәк бит Ә без талантлы яшьләребезне бушлай укыту ягында, аеруча БДБ илләреннән килгән студентларга ярдәм итәргә тырышабыз.

Институтның берничә ел эчендә сәнгать һәм мәдәният институты һәм быелдан башлап академия итеп үзгәртелүе, дөрестән дә, безгә киң юл ача. Киләчәктә без бирегә сәнгать кафедрасы, аспирантура булдыру турында да хыялланабыз, инде татар музыкасы кафедрасы да уңышлы эшләп килә Бүгенгә көндә бездә Русия һәм БДБ илләренең 32 өлкәсеннән килгән вәкилләр — студентлар белем ала Чит төбәкләр белән артистлар алмашып, китаплар җибәреп кенә анда яшәүче милләттәшләребезнең мәдәнияткә һәм сәнгатькә булган ихтыяҗларын канәгатьләндереп бетереп булмый Бу җәһәттән, иң элек белгечләрне күпләп әзерләп чыгару зарур.

— Талант акчага да сатылмый бит әле.

— Академиягә укырга алганда, булачак студентларның сәләтенә беренче чиратта әһәмият бирелә Чөнки андыйлар берниндн тамашачы алдында да югалып калмый. Әйтик, Балтач районыннан Эльвира Вәлиева элек сыер савучы булган, бүгенге көндә бездә укый Менә дигән җырчы Йә булмаса, Аксубай төбәгеннән чыккан Ландыш Шәфигуллинаны алыйк Ул инде республика смотрында катнашып, югары бәя алган башкаручы Безнең яшьләребез, чыннан да, талантлы, аларны эзләп табарга һәм тәрбияләргә генә кирәк.

— Республикабыз мәдәни тормышы белән кызыксынып торуыгызны, шуның эчендә кайнавыгызны беләбез. Бүгенге көн күзлегеннән карап, аңа нинди бәя бирер идегез?

— Театрларыбызга килсәк, алар яңа күтәрелештә дияр идем Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры яңа бинага күчкәч, тамашачыларны әйбәт спектакльләр белән куандыра башлады Опера һәм балет театры коллективы да уңышлы эшләп килә Татар филармониясендәге үзгәрешләр генә сагайта төшә сыман Мин бу иҗат оешмасын бер йодрыкка тупланып, халкыбызны җыр-моңнары белән куандыручы коллектив итеп күз алдына китерергә теләр идем Базар шартларында ялгызың гына йә булмаса. кечкенә бригадалар составында җырлап йөрүе җиңел түгел бит Язучыларга, гомумән, иҗат интеллигенциясенә бүгенге шартларда яшәп. иҗат итүе авыр бирелә

— Рәис әфәнде, сүзне яңә дә сезнең шәхси тормыш белән бәйлисе килә. Күреп-сизеп торабыз, язмыш сезне дә күп сынаган, тормыш дәрьясының бер ярыннан икенчесенә бәргәләгән. Әгәр бер генә юнәлештә эшләгән булсагыз, дим.

— Гаиләдә мин бик бәхетлемен, хатыным Фәимә гел минем өчен генә яшәде дисәм, ялгыш булмас. Аңа рәхмәт КамАЗ автогиганты төзелешендә катнашуым белән дә үземне бәхетле саныйм Дөрес, үземнең көчне, энергияне төрле тарафка ташладым, сарыф иттем. Хәзер уйлыйм, әгәр университетта укыта башлаган килеш эшемне шунда дәвам иттергән булсам, мин, бәлки, күптән галим булган булыр идем. Йә булмаса экономика белән бәйле юнәлештән китсәм, республикабыздагы хуҗалык җитәкчеләре рәтендә йөрер идем. Миңа, чыннан да, һәр урында эшне өр-яңадан башларга туры килде. Бәлки, әле бер генә юнәлештә хезмәт куйган булсам, мин республика тормышына күбрәк файда китерә алган булыр идем Нишлисең бит, үткәнне кире кайтарып алып булмый, без шул чор кешеләре булып калачакбыз.

— Ата-бабаларыгыз хакында да шулай әйтергә мөмкин булыр иде, минемчә.

— Элекке тормыш, нәсел шәҗәрәбез турында да әтием белән озак сөйләшеп утырганым булды. Аның кайбер детальләре хәтергә кереп калган булса да, кызганыч, сөйләгәннәрне магнитофон тасмасына яздырып кала алмавыма үкенәм Әтием 40 ел буе мәктәптә укытты, директорлык итте. Җырлар, шигырьләр язарга ярата иде. Картаймыш көннәрендә намазлыгын да онытмады. Ул чагында мәчетә генә булмады шул. Ата-бабам нигезе урнашкан Шәрбән авылында (Аксубай районы) хәзер яңа мәчет төзелеп килә, мин моңа бик шат Миңа калса, ул бөтен авылның тарихын яңартыр сыман Дөрес, мин үзем элекке Биләр районының Яңа Адәм авылында дөньяга килгәнмен Әмма үткәнем һәм бүгенге көнем Шәрбән белән бәйләнгән. Үзвакытында мин анда мәктәп төзетүдә, күпер салдыруда, юлларны төзекләндерүдә булышкан идем Якташларым, шул хөрмәткәдер инде, күперне Рәис исеме белән атап йөртәләр Туган якка кайтып йөрибез, анда безнең әти белән әни, бабалар күмелгән Аларны онытырга ярамый .. Әти белән сөйләшеп утырган чакта, шулай берчакны, мин аңардан фамилиябезнең ни өчен Беляев булуы хакында сораган идем Татарда мондый фамилия юк бит инде Хәтта үземне керәшен дип белүчеләр дә бар иде Моның сере гади булып чыкты Бабам Билал, ә аның әтисе Морат булган икән Димәк, мин дә чын татар баласы Бабам элеккә заманда читкә күмер кисәргә. төрле эшләргә йөри торган булган Ә документсыз ерак китеп булмый Шул чактагы документларга Биләй дип язып та куйганнар Әни ягыннан нәсел агачыбыз зур Октябрь районының хәзер Хафизов исемен йөрткән колхоз әниемнең энесе Шәрип абый хөрмәтенә аталган Колхозлашу чорында ул утызмеңчеләр сафында булып, Бөек Ватан сугышында катнашканнан соң да 30 ел буе хуҗалыкны җитәкләде Ул союз күләмендә депутат һәм Социалистик Хезмәт Герое исеме алган кеше Әниемнең икенче энесе Шакир абый да колхозга 30 ел буе председательлек иткән Ә сеңелләре, алар өчәү, җырга-моңга оста булулары белән аерылып торалар Аларның әтиләре Сәгыйрь бабай теге чорларда танылган сәүдәгәр булган

Шәҗәрәдәге һәр буынны күздән үткәрәм дә, уйлап куям алар да көн, заман сулышы белән гомер кичергәннәр бит Минем дә тормышка ашырасы никадәр уй хыялларым бар. җанда көч-дәрман барында шуңа өлгереп каласы иде дим

Әңгәмәне **Альберт САБИРОВ** үткәрде

Кирәк булыр...

Чыңлап үтә гомер,
Артта кала еллар,
Күкне каплап болыт агыла.
Күңел тошми кара болытларга,
Җан тартыла кояшка гына...

Әйтерсең лә Идел бозы китә,
Ак болытлар карлы боз кебек.
Йөрәк дертләп куя,
Болыт арасында
Балкып торган зәңгәр «күз» күреп...

Зәп-зәңгәр күк, гүя, кызлар күзе,
Нурлар сирпи сары коземә.
Рухым күтәрелде —
Яшьлек, кабатланып,
Гүя, кайтып килде үземә.

Күзләремә тулып, яшьлек нуры
Бит очымда уйный-куана...
Кумыйм әле сары коземне дә,
Кирәк булыр — нигә куарга...
Бит очымда нурлар куана...
23 октябрь, 1995 ел.

Сагыну

Бик күрәсем килә әтиемне,
Яшьли үлгән, сабыр итмәгән...
Әйт әле, әйт, әни,
Телем ачылганны,
Үскәнемне нигә көтмәгән?

Әни елый,
Үксеп-үксеп елый,
Күкрәгенә кысып башымны.
Үкси-үкси йоклап киткәч кенә
Ярсуларым бераз басылды...

... Күрше малайлары үксез түгел,
Аталылар ике канатлы.
Авылымда шушы бәхетләләр
Йөрәгемне азмы канатты.

Яшьтәшләрем кыен ашатканда
Каршы торсам, чыга атасы.
Әйтерсең мин иң әшәке малай,
Үксезләрнең юк шул аркасы...

... Инеш буйларына әти торткән,
Сылу булып үскән талларны
Берәм-берәм кочып, йокламыйча
Аттырдым мин күпме таңнарны!..

Ал таңнардан аккан моң-сагышның
Ак томаны инеш буйларын
Басып китте, ә мин,
Шул томанга чумып,
Чоңгылында йөздем уйларның...

Таллыкларда сайрый сандугачлар,
Яфрак белән яфрак ымлаша.
Ярларыннан ташар иде диңгез,
Йөрәгемне килеп тыңласа...
Апрель, 1995 ел.

* * *

... Тәннәр арык,
Карыннар ач,
Арып-талып эшлим кон-тон...
«Алда матур тормыш кот син!..»
Котә-котә мин бил боктем —
Җибәргәннәр күзгә тотен...
10 май, 1995 ел.

Коткы

Бер-береннән «үчен» ала халык,
Үзенекен итә явыз коткы —
Качып-посып, итәк асларыннан
Шовинистлар озаталар укны...

Янган мәсҗетләрнең соремнәре
Боркеләләр сулган күңелләрдән.
Җаһилләрнең мәкер җәтмәсендә
Күпме бәгырькәйләр күмерләнгән!..

Кардәшләрен кыра Кавказ халкы,
Чакма чагып тора явыз коткы.
Күрсәтмичә, итәк асларыннан
Шовинистлар кон-тон йортә утны...
30 сентябрь, 1995 ел.

Упкын читендә

Күреп шаян күзләреңне,
Нурландылар күкләрем;
«Мәхәббәтем син икән», дип,
Кулларыма күтәрдем...

Күтәрдем башым остенә.
«Ярым!», диеп куандым.
Артык ышанган булганмын —
Яр читендә уяндым...

«Йоклатып...», ярга илткәнсең,
Упкын яры читенә...
Ах, бу доньяда кешенә
Зәпүләре читен лә!..
Башым упкын читендә...
8 май, 1995 ел.

Юксынып йөрәк әрни

Тегәр җепкә тезде әни
Туксан тугыз тоймәсен.
Асылташ кебек тоймәләр —
Тик күз генә тимәсен...

Зобәрҗәт кебек тоймәләр
Балкыйлар ялт-йолт килеп.
Әйтерсең, күз ачып-йомып,
Сабыйлар уйный колеп...

... Ничә еллар тәсбих әйтеп,
Дисбесен тарткан әни.
Үзе юк шул инде хәзер —
Юксынып йөрәк әрни...

Тошләремә керә әни,
Таныш дисбесен тартып;
Догалары хәтеремне
Торалар гел яңартып...

Кулымда әни дисбесе,
Күңелемдә — бер Аллам.
Тәсбих әйтеп, иман укып,
Рухыма саулык алам...
4 октябрь, 1995 ел.

Саклый алмадык шул...

... Ишеткәч тә, дустым,
Рәшит Әхмәтҗанов,
Гүя, донья кысты үземне.
Тирә-ягым томан,
Калтыранам, туңам —
Каян гына алыйм түземне?
Гүя, донья кысты үземне...

Табаннарым җиргә тию белән
Иблис калкып чыкты дүрт чатта.
Уңга карасам да,
Сулга карасам да
Кара елан сыман юл ята.

Итәк асларыннан үткән юллар
Буйлап алган туган җирләрне —
Посып торган юллар,
Юлларга иш еллар
Суырдылар безнең җегәрне...

... Кайдан башланганын
Хәбәр итә идең
Ябырылып килгән хәвефнең.
Үзең кебек, синең, шагыйрь дустым,
Шигырьдәге һәрбер хәрефең
Каршысына басты хәвефнең...

... Мәңгелеккә озаттык без сине,
Татар халкы сыкрап озатты...
Ышан, дустым,
Шәһит киткән шагыйрь,
Илне богаулаган йозакны
Ачар халык,
Ачар йозакларны —
Татар тыны тимер эретә;
Соңгы канны түкми-чәчми генә
Чыксак иде тулы ирекка!
Татар тыны тимер эретә...

... Ах!
Үлемеңне ишеткәч тә синең,
Гүр суыгы алды үземне.
Кайгы-хәсрәтемнән һуштан яздым —
Кайдан гына алыйм түземне?
Гүр суыгы алды үземне...

Саклый алмадык без,
Сине, шагыйрь дустым,
Җир ярылып, гүрең ачылды.
Газиз халкым белән мин дә йоттым,
Йоттым синең үлем ачыңны —
Йөрәк ярам әрнеп ачылды...
21 октябрь, 1995 ел.

Тигәнәк

Яз җиттеме, голчәчәкләр әзлим,
Тик каршыма чыга тигәнәк:
«Голчәчәктән ваз кич», — дигән кебек
Кулларымны ала тәлгәләп...

Киемемне сырып ала, каһәр,
«Миннән котылмассың», дигән күк.
Донья тулы матур-матур кызлар.
Арасында әдәпсезләр күп —
«Миннән котылмассың», дигән күк...



Сафуан Мулла ГАЛИ

Язмышмы бу?
Тигәнәккә охшаш
Кызлар белән йорим табышып —
Йорәгемне телем-телем телеп,
Капкагача кайта ябышып...
2 октябрь, 1995 ел.

Сәрхуш хатын

... Күчә сыман баскан җирем,
Селкенә күк ботен кала —
Каршымдагы ой эчендә
Елый да елый бер бала...

Илереп елый бер бала,
Әнисеме ташлап киткән?!
Бәргәләнә-әрни җаным,
Нигә бала елый икән?

Чык тамчысы яфракларда,
Таң яктысы юлга яткан...
Карап тора тәрәзәләр:
«Коткар!..», диеп торле яктан.

Авырта йорәк, авырта,
Иренемне тешләп түзәм.
Юк калмады башка чарам,
Инде ишек бавын озәм...

Керсәм, баласы янында
Сәрхуш хатын йоклап ята...
Юк, әтидә генә түгел,
Әнидә дә бик күп хата —
Сәрхуш хатын йоклап ята.
30 сентябрь, 1995 ел.

Кыланмадым артыгын

Моң ага, янып, әчемнән,
Әрнеп моңлы җыр ага.
Гомер буе йозеп килә
Хәсрәт тулы елгада...

Сикермәдем чоңгылларга,
Ни файда югалуда?
Ир булып каласым килде,
Юл ярып югарыга.

Кермәдем сазлык-баткакка,
Булса да ут чакларым,
Акча-байлыкка кызыгып,
Намусымны сатмадым...
Булса да ут чакларым.

Фиркагә дә димләделәр —
Кирәклеген күрмәдем.
Тик хәрәм кызлар янында
Мин дә бераз керләндем...

Аз-маз керләнсәм дә, синең
Белдем мин киләсеңне;
Кояш сыман нурлар боркеп
Үбәсем килә сине.

Утыр әле яннарыма,
Бәхет биргән картлыгым.
Син килмәссең әле,диеп,
Кыланмадым артыгын.

И, картлыгым, яшьлегемдә
Кыланмадым артыгын...
24 октябрь, 1995 ел.

КИТАП ТУРЫНДА ХИТАП

Бүген без гәзитебездә өр-яңа рубрика ачып җибәрергә уйлыйбыз. Ул китап дөньясына багышлана. Китапсыз өй — тәрәзәсез бүлмә, ди безнең халык. Чөнки белемнең гаебе юк. Ә гыйлем — китапның эчендә дә, тышында да була.

Безгә китап дөньясына сәяхәттә күренекле язучыларның һәм галимнәрнең китаплары ярдәм итәчәк. Шулар арасында аеруча татар галиме Әбрар Кәримуллин һәм венгр галиме Иштван Рат-Вег кебек дөнья күләмендә танылган зыялыларның китаплары беренче урында тора.

Кыскасы, хәерле сәгатьтә, мөхтәрәм укучылар.

Ризван ХӘМИД

Беренче китап кайчан язылган?

Хәзерге галим-голәма бу сорауны бирсәң, җилкәсен генә җыерып куя. тавык алдан яралганмы, йомыркамы, янәсе. Чөнки бүгенге көндә фәнгә билгеле булган иң борынгы язма турында гына сүз йөртергә мөмкин. Андый сорауга җавап бар: Парижда милли китапханәдә безнең эрага кадәр 3350 елда язылган бер папирус төргәк саклана. Борынгы Фиваның зиннәтле каберләренең берсендә табылган ул. Аннан да «картрак» китаплар да бардыр, бәлки: Мисыр табутларында ни генә булмас?!

Ә инде югарыда куелган сорауга чынлап җавап эзләргә ниятлисең икән, ясалма чәчләр-париклар хуҗаларына — урта гасырлар галимнәренә мөрәҗәгать ит. Бу проблема астында бер генә буын париклы «чүлмәк» ватылмаган! Ниһаять, XYII гасырда университет галимнәре уртак нәтиҗәгә килә: иң беренче китапны Адәм галәйһис-сәлам иҗат иткән булырга тиеш. Бүтән беркем дә моңа дәгъва итә алмый. Шуннан соң гына гыйлемле париклар җиңел сулап куялар: хәзер китап фәне, тиз йөрешле итекләр кигәндәй, кызулык белән үсәргә форсат алды. Һәм, чыннан да, бөтен Аурупаны китап туфаны баса: кем беренче булып Адәм язган китапларның (хәзерге язучылар кебек әфтияк калынлыгы бер китап бастыруга Язучылар берлегенә йөгермәгәндер уртак бабабыз, иҗат ләззәтен татыган кеше моны яхшы белә!) исемнәрен ача, шуңа һәйкәл куячаклар бит! Шушы изге эштә күпме каләм шартлап сына, күпме нерв җепләре ашалып өзелә — бер Ходай гына беләдер. Һәм менә — төзүгә якты нур. «Адәм дөньяда бөтен фәннәрне уйлап табучы гыйлем иясе булган» Китап чаклы китап язсын да — чи надан булсынмы?! Бөек галим ул! Хәзергечә әйтсәк, күпкырлы энциклопедист. Париклы башлар сабантуй оештырган заманга караганда, Адәм тудырган фәннәр шундыйлар: грамматика, фәлсәфә, астрология, математика, теология һәм юриспруденция, ягъни, хокук гыйлеме. Тирән нигезләнгән бу ачышка берәү дә каршы төшми. Бер тар маңгай гына иң беренче бабабызның сәясәт фәнен белүен шик астына алгач (ә бит хаклы бугай ул галим: Адәм үзенең булачак хатыны Хава белән ике арада сәясәт корып ятмагандыр ич инде?), теге мескеннән дурчмак пешереп ташлыйлар. Шул кирәк аңа: белер-белмәс эшкә алынма! Китап сабантуйларында кискен көрәш дәвам итә. Кем әйтмешли, белмим нәрсәне белмим нәрсәгә тапкырласаң, нәрсәдер барлыкка килүе мөмкин: җиң сызганып, тирләп-пешеп эзләнә торгач, Адәмнең 12 китап авторы булуы ачыклана. Ә иң беренче китабы нинди булган? Әлифба, әлбәттә! Монда Адәмнең китап киштәсендәге бөтен китапларны да санап торуның хаҗәте юк. Хавага өйләнгәч, анысы да, иреннән күрептер, 2 китап иҗат иткән, җитмәсә. Шунысы кызык, ир белән хатын икесе дә берәр китапларына бер үк исем кушканнар: «Күрәзәлекләр китабы». Кайбер үтә җитди галимнәрнең язуына ышанганда, өстәвенә, эчтәлекләре дә сүзе сүзгә диярлек тәңгәл туры килә икән. Шулай итеп, көтмәгәндә яңадан кызу диспут куба: нәрсә бу — дөньяда иң беренче плагиатмы, әллә — ул галимнәрнең Хава намусына тап төшерергә маташтыруымы? Мин үзем тегеләй дә, болай да түгелдер, дип фараз кылам: китап исемнәре туры килү —безнең татар язучылары арасында да еш очрый торган хәл бит. Купкан гыйльми бәхәс күпме барган булыр иде, билгесез, ярый әле озаклый Адәм белән Хаваның китапларын беркемнең дә укымаганы ачыклана. Аннан соң, ир белән хатын арасына тыкшыну — күрәләтә нахаллашу бит ул. Ачыклыйсы сораулар болай да баштан ашкан: әйтик, Адәм белән Хава нинди телдә язганнар? Нинди хәрефләр кулланганнар? Китаплары таштан ясалганмы, агачтанмы, яки — кәҗә тиресеннәнме? Җиңел генә хәл ителә торган проблемалар түгел болар. Без, татарлар, башта рун хәрефләре, аннан — уйгур, гарәп, яңалиф, ә иң соңыннан — кириллица кулланганыбызны әйбәт белгәч тә. Галимнәрнең бәхетенә, шул чорда Ватикан китапханәләренең бер тузанлы почмагында ниндидер сәер тимер кисәкләре табыла: сырлап эшләнгән нәмәрсәләрнең бер ягында аерымачык булып бер ир кеше сурәте төсмерләнә, ә астында — ниндидер язуга охшаган сырламалар да бар. Башваткычны ваталмаган галим кеше буламы? Бер немец галиме каты чикләвекне шундук кабыгын кабыкка төшен төшкә аерып ташлый. бу сурәт — Адәм сурәте ә аска «Барлык фәннәрне уйлап табучы — Адәм» — дип язылган! Немец акыл иясе артыннан инглизләр белән итальяннар да шуны ук хуплыйлар. Тик искәрмәгәндә кечтеки генә аңлашылмаучылык туа: галимнәрнең теге рәсем астындагы язу күчермәләре берсе дә бер-берсенә туры килми! Ә бит бер дә гаҗәпләнәсе юк. «Крит дисбесе» белән әнә безнең күз алдында гына да күпме галәмәт хәлләр булып тора! Татар галиме бер төрле укып бирде, урыс галиме — үзенчә сукалый, немец галиме — үзенчә.. Чын булса, дөньяда хәзер йөз илледән артык вариант бар, имеш. Ярый, Адәм белән Хавага борылып кайтыйк. Озын сүзнең кыскасы, галимнәрнең аяклары астында шундый аңлашылмаучылык кебек түмгәкләр калкып куйгаласа да, төп максатларына ирешәләр: «Адәм бервакыт кәҗә тиресеннән пергамент эшкәрткән дә, язу карасы уйлап тапкан һәм, каләм ясап, иҗатка тотынган». Ләкин менә бәла, хәрефләр юк бит әле, хәрефләр! Язуда иң мөһиме — әлифба. Безнең татар әлегә чаклы нинди хәрефкә тукталырга белми бер читтән икенче читкә бәргәләнә! Уен эшмени?! Нәкъ әнә шул мизгелдә Адәм ялгыз гына берни майтарып булмаганын аңлаган булырга тиеш бәхетенә, дип әйтикме — моның күзенә ниндидер чибәр зат чалынган һәм ул үзе дә көтмәгәндә «О-о!» дип кычкырып җибәргән һәм катып калган бәрәч, иреннәре түгәрәкләнеп «о» хәрефе ясады түгелме?! Гаҗәпләнер дә бер хәреф тә табылды. хатынлы да булды! Адәм шатлыгыннан башын күтәреп, тирә-ягына каранган, андагы хозурлык, мин сиңайтим! Бу юлы Адәм, иреннәрен алгарак сузып, «У-у!» диген. Димәк, икенче хәреф тә булды. Бер башлаган эш — беткән эш инде ул калган хәрефләрне табу алай ук артык авыр булмаган.

Әлифба булды. Ләкин бит әле галимнәр алдында тагын бер чишелмәгән зур мәсьәлә тора: Адәм белән Хава оҗмахта (һәм Хак Тәгалә үзе дә) нинди телдә сөйләшкәннәр һәм язганнар? А Кэмпе диген бер галим бик җитди гипотеза тәкъдим итә: бер дә баш ватмагыз. оҗмахта Ходай швед телендә, Адәм — даниялеләрчә, ә Хаваны хәйләкәр Елан французча яман белән яхшыны аерырга ярдәм итә торган алманы ашап карарга котырткан — Хава шул телне белгән булып чыга. Әмма галим бу үтә дә үзенчәлекле фикерен берничек тә нигезләп маташмаган. Бер немец галиме, шуннан файдаланып, Кэмпенең гипотезасыннан тузан очыра. күңелләрегезне вәсвәсәләндермәгез. оҗмахта немецча сөйләшкәннәр. бәхәсне туктаттык һәм — бетте-китте, ди Кирәк бит, моның акыллы киңәшенә һәркем колак салмый:

— Бик булуы мөмкин, Адәм белән Хаваны шунлыктан оҗмахтан куганнардыр да! — дип җавап бирә бер җор телле француз язучысы. Немец теленең французчага караганда катырак һәм тупасрак яңгыравына ишарәләве булгандыр инде. Җөпләп әйткәндә, минем белүемчә, оҗмах теле әлегә кадәр ачыкланмый кала бирә.

Киләсе очрашуда, Аллаһы боерса, «Китап исемнәре эпидемиясе» хакында сөйләшербез.

АКМУЛЛАНЫҢ һӘЛАК БУЛУЫНА 100 ЕЛ

Шагыйрьнең соңгы төне

«Дөньясы тар булса булсын —
күкрәге тар булмасын.
Йорты Болгар булса булсын —
йортны болгар булмасын»,

дигән шигъри юлларның авторы Мифтахетдин Акмулла 1831 елны Ырынбур губернасындагы Дүсән авылында дөньяга килә. Сабый чактан ук шактый кыен күреп үсә.

Акмулла — суфи шагыйрь Шәмсетдин Зәкинең шәкерте, ул Эстәрлебаш мәдрәсәсендә сабак ала. Ә инде Троицкида уку дәверендә үзе дә казакъ балаларына белем бирә. Хәлфәлек итү белән мавыгып китеп, укуларын тәмамлагач, Карасу аймагында төпләнеп кала. Кыскасы, иҗатын һәрчак балалар укыту белән бергә бәйләп алып бара.

Намусы пакь хәлфә, әлбәттә, миһербансызлык-шәфкатьсезлек галәмәтләренә күз йомып яши дә, алдашу-гаделсезлекләргә битараф кала да алмый — гади халыкны яклап, хакыйкатьне даулап, үзләрен дала хуҗасы санаучы казакъ байлары белән дәгъвалаша-тартыша, гаделлек эзләп Петербурга чаклы барып җитә.

Хәлфә буларак та, шагыйрь буларак та Акмулла үзенең укучыларын юлдан-диннән язмаска, читкә тайпылмаска өнди; акыллы-тәүфыйклы булырга чакыра; әдәпле-инсафлы, сабыр холыклы булырга өйрәтә.

Аның байлар белән тыныша алмавы иҗатында да чагыла: нинди генә яла якмасыннар, нахак бәла такмасыннар — пычрата алмаслар саф алтынны һичбер вакыт, ди ул; утны-суны кичми торып, дөнья казанында кайнамый-пешми торып, чыныкмый торып — камил булмый адәм баласы, ди; дошманнарын вак-төяк кошка санап: «Тургайның тозагына лачын төшми», — ди.

Әмма дошманнары алай ук вак-төяк кошлар да, сабыр холыклы затлар да инсафлы-шәфкатьле кешеләр дә түгел икән ләбаса! Менә алар, Акмулланы ничек тә авызлыклый алмагач, тозакның яманын-зәһәрен коралар: калага сәфәр чыкканын сагалап торалар да, 1895 елның көзге бер төнендә казакъ даласында шагыйрьнең башына җитәләр.

Җан кыюга, кан коюга барып тоташкан фаҗигале бу вакыйга әле йөз елдан соң да һәммәбезне тетрәндерә. Моңа һәркем үзенең фикерен әйтә, бәясен бирә. Ә инде рәссам шушы олуг фаҗигагә багышлап картина иҗат итә.

Инеш-фәлән булгандырмы казакъ даласында, юктырмы — анысын әйтүе кыен. Әмма сәнгатькәр шагыйрьнең изге гомере өзелгән урынны шулайрак күзаллый. Караңгы төнне тасвирлаган карасу фонда аксыл-зәңгәр тасма булып еракларга мул сулы инеш сузылган. Җир өсте дә, күк йөзе дә күзгә төннең караңгылыгына таман килә. Казакъ даласында елкы урлаучылар да, куй караклары да мондый төндә үзләренең кара эшләрен бик тә рәхәтләнеп башкара торганнардыр. Әнә бит әле, аннан да карарак, аннан да хәтәррәк эшкә ялланган бәндәләр дә төн карасын күтәреп алганнар. Күзгә төртсәң күренмәстәй караңгыда бер гөнаһсыз шагыйрьнең канын кою, сабыйлар зиһенен яктыртучы мөгаллимнең җанын кыю ансатрактыр, мөгаен, бәдбәхетләргә...

Киндердә караңгы, шомлы төн тасвирлана. Әйләнә-тирәне үз эченә йоткан шушы караңгылыкта фәкать үзе белән мәңгелек яшәү көче алып килүче су, әүлия дәрәҗәсендәге шагыйрь һәм аның турылыклы дусты — аты гына якты нурлар булып балкып күренә, сәнгать әсәрен җанландырып җибәрә. Атның үз-үзен тотышында бертөрле сагаю-шөбһәләнү сизелә: утлап йөрүче ат, шомланып, башын күтәргән, хуҗасы-дусты ягына, болай таба борылган. Әмма шагыйрь үзе берни абайламый булса кирәк. Әнә ул, арбасы-кибиткасы янына җайлап кына утырган да язуын белә. Аның тәкъва сакал-мыегына чал иңгән, үткен күз карашы алга төбәлгән. Шагыйрь бу фани дөньядан гүя бөтенләй ваз кичкән — онытылган, хиссият дөньясына чумган... Иҗат иясе андый чакта җанын саклау ише вак нәрсәгә илтифат итә димени!..

Картинада Акмулланың йөз-кыяфәте дә, уйлануы да, ике кулы да, хәтта каурый каләм тоткан бармаклары да гаять зур осталык белән язылган.

Кыям МИҢЛЕБАЕВ.

● Кәнәфи НӘФИКОВ. «АКМУЛЛА».

ИСТӘ, ҺАМАН ДА ИСТӘ

Шагыйрь һәм композитор Ләбиб Айтугановның тууына 60 ел

Кемнең кемлеген күзенә карап белеп була, диләр. Аның күзләре ачык, тобалүчән һәм кыска гына мизгел эчендә дә кешеләрне танып алырдай караш белән хәтердә калган. Без аның белән «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газите каршындагы әдәби-иҗат берләшмәсендә бер вакыттарак йөри башлаган идек. Гали Хуҗи һәм Шәрәф Мөдәррис кебек танылган шагыйрьләр җитәкчелек иткән бу берләшмә хәзер инде әдәбиятта күренекле урын тоткан зыялыларны тәрбияләп чыгарды, дисәм, ялгышмам шикелле.

Ләбиб Айтуганов безнең арага ничектер бик күзгә ташланмыйча, тыйнак кына килеп кәрде. Һәр нәрсәне бер селтәнүдә хәл итәргә хыялланган без, — яшь максималистлар, — ялкынланып, йодрыклар төйнәп шигырь укыр идек тә, фикер алышу дигән хәтәр вакыт җитәр иде. Ул вакытта хәтер саклау дигән нәрсә юк: нәрсә уйлыйсың — ярасың да саласың. Кемдер кемнедер күкләргә чөеп мактый, кемдер кемнедер пыр туздырып ташлый. Аргументларга ул кадәр игътибар иткән юк. Сүзең расмы, түгелме — ул кадәресен кайгыртмыйсың. Менә бер заман тыныч кына утырган Ләбиб күтәрелә. Тикшерелгән әсәрнең бүгенге көн өчен кирәклеме-түгелме икәнлеге турында әйтә, шигырь өчен фарыз булган рифма-ритм мәсьәләләрен кузгата. Ә берләшмәнең җитәкчесе, фикер алышуга йомгак ясаганда, еш кына нәкъ менә Ләбиб әйткән сүзләргә таяна.

Ул чорда Л.Айтугановның үз шигырьләре дә көндәлек матбугатта байтак дөнья күрде. Алар шигъри эшләнешләре ягыннан шактый камил, халыкча әйтсәк, җырлап торалар иде. Бәлки, бүгенге көн өчен алар беркадәр искергәннәрдер дә, дөнья вәзгыятен хәзерге биеклектән аңлата да алмыйлардыр. Заман баласы үз заманыннан аерыла алмый шул. Ул елларда яшәеш фәлсәфәсен азмы-күпме аңлаган, утлар-сулар кичкән өлкәннәребез дә бик артык зур фикерләргә дәгъва итә алмыйлар иде.

Һәм бер нәрсә хак: без һәммәбез дә ихлас булырга тырыштык.

Ходай Ләбибкә сәләтне өеп биргән булып чыкты. Шигырь язу өстенә ул бик матур итеп мандолинада уйный һәм... койләр чыгара иде. Ул бу һөнәргә шигри табигатьле Әгерҗе төбәгендә һәвәсләндеме, зур мәдәни традицияләре булган Минзәлә педагогия училищесында өйрәнгән идеме, әллә үзлегеннән шулай килеп чыктымы... һәрхәлдә, аның моңнары да, көйләре дә күңелгә якын һәм үз иде. Алар ничектер халык йөрәгеннән саркып чыккан чишмә сулары кебек табигый яңгырый иде. Аның шигыренә язылган «һаман да истә» дигән җыры искә төшерү дә җитә торгандыр.

Йомшак кына җемелдиләр
Йолдызлар җәйге кичтә...
Туган якның зәңгәр күге
Истә, һаман да истә.

Хәзерге кайбер шагыйрьләр кебек борганып-сырганып маташмаган, бөтенесен гади һәм гадәти итеп әйткән дә салган. Күрәсең, шуңа күрә дә халык күңеленә бик тиз юл тапкандыр ул.

Мин университетның соңгы курсларында укыганда (Ләбиб үзе педагогия институтында укыды), ул Татарстан радиосының музыкаль тапшырулар редакциясендә эшли иде инде. Табигый, без, иҗатташ, мәсләктәшләр, аның янына еш килә идек. Радиода ул ару-талуны белми эшләде — эшкә бөтен иҗат мөмкинлекләрен җикте: йә гадәти концерт программасы тезе ул, йә шигырьләрне-җырларны аралаштырып композиция ясый, музыкаль спектакльләр яза, режиссер булырак, артистлар белән эш итә. Аның тирәсендә һәрчак композиторлар, шагыйрьләр, артистлар... Эш төн уртасына кадәр дәвам итә. Мин аның юньләп ял иткәнен гомумән хәтерләмим. Ул кадәр көч һәм чыдамлык каян килгәндер аңа. Башы тулы идеяләр — каян шул кадәр табып бетерә ала торгандыр. 1959 елда ул язучы Рахмай Хисмәтулла белән мине дә эшкә җикте.

— Менә кайбер акыллы башлар рояльләрне, фортепианоларны Кабан күленә ташларга тәкъдим итәләр. Тальян гармун һәм җыр-такмак белән генә булмый бит инде, — диде ул. Без музыка мәсьәләсендә шактый дилетант булсак та, «Гадидән — катлаулыга, тальян моңнарыннан — симфониягә» дигән тапшыру ясарга алындык. Нәтиҗә без көткәннән дә уңышлырак килеп чыкты. Радиотыңлаучылардан күп кенә хатлар килде, тапшыру үзе Мәскәүдә узачак радиофестивальгә тәкъдим ителде.

И чордашлар, замандашлар! Кемнәр генә юк иде бит безнең арада?! Кайсыберләре шул чорга һәм хакимият җитәкчеләре күңеленә хуш килердәй көлтә-көлтә шигырьләр иҗат иттеләр дә, заманнар яңача фикерли башлагач, гаугасыз, шау-шуларсыз гына шигърият мәйданын ташлап киттеләр, икенчеләре, үзләре җигелеп иҗат итәсе урында, каләмдәшләренең шигырьләренә һөҗүм итүне, һичьюгы «тәнкыйтьче» дәрәҗәсе алуны артыграк күрделәр. Ул елларда шигърият күгендә ялтыраган каләмдәшләр әле дә бик са сагынырга. Ә Ләбиб бигрәк тә. Тиз арада һәммәбезнең якын дустына, фикердәшенә әйләнә алган кешеләр сирәк очрый бит бу тормышта.

Соңгы тапкыр мин аның белән ул вакытта радио дикторы булып эшләгән шагыйрь һәм журналист Эльс Гаделнең өй котлау мәҗлесендә очраштык. Соңгы тапкыр, диюләре, ай-һай, авыр. Ул вакытта аңа утыз яшь тә тулмаган иде бит әле. Үзенең фаҗигасе якынлашуын сизә идеме ул, әллә гадәти җор күңеллелеге, оптимизмы ташып чыккан кодрәтле мизгел туры килдеме, хәтта аны бик якыннан белгән дуслары да Ләбибнең ул көндәге шатлануына гаҗәпләнмәгәннәрдер. Ул ботенебезне көлдерә-көлдерә тостлар әйтте, күмәк җырларыбызны күтәреп җибәрүче булды, аерылгысыз дусты — мандолинасы кылларын чиртте, ашкына-ашкына биеде. Ул бу кичәдә игътибар үзәгендә иде. Тормыш соючән, тәшенкелекнең ни икәнен дә белмәгән тиктормас кешенең көннәре инде санаулы гына калгандыр дип ул чагында кем уйлаган!

Татар зиратына, йөрәк бәгырьләре өзгәләнә-өзгәләнә чираттагы зыялыбыз белән хушлашырга барган саен, аның кабере чителтеп үтеп булмый. Кабер ташында — сискәндергеч, фәлсәфәләрчә гыйбрәтле, Ләбиб үз көе, үз моңы белән үлемсез иткән шигъри юллар:

Юллар, юллар, озын булса булсын,
Тик соңгысы гына булмасын.

Әхмәт РӘШИТ.

Мидхәт МИНШИН

Мизгелләр һәм мәңгелек

(Ләбиб Айтугановның үлгән көнендә язылган шигырь)

Иртән генә әле радиодан
Синең яңа җырны бирделәр.
Тереләдер, савыгадыр, диеп
Өметләнгән иде күңелләр.
Ә үзең бит шушы мизгелләрдә
Соңгы сулышыңны алгансың —
Җыр көчәеп кенә килгән чакта
Арабыздан китеп баргансың.
Юллар авыр булса, булсын, —диден,-
Тик соңгысы гына булмасын.
Үзеңә дип берни дауламыйча,
Үлемсезлек яулап алгансың.

24.04.1964 ел
Буа шәһәре.

Татарстан дәүләт телерадио компаниясе, «Казан» милли мәдәният үзәге иртәгә — 25 ноябрь көнне — шагыйрь һәм композитор Ләбиб Айтугановның тууына 60 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичәгә чакыра. Ул кондезге сәгать 12 дә башлана (Солтангалиев мәйданы, 1 нче йорт).

ТИНЧУРИН ТЕАТРЫНДА ПРЕМЬЕРА

Йолдызлы яңгыр шавы

Кыш булды дигәндә генә, урамда яңгыр коепмы коя. Җитмәсә, ул җылы, күңелне сафландыра торган яңгыр. Ә Тинчурин театрында өнә шундый язны хәтерләткән кичтә (17 ноябрь) «Йолдызлы яңгыр» дигән спектакль премьерасы булды.

Яңгыр. Урамда да, сәхнәдә дә яңгыр. Алар бу кичтә бер-беренә шифа өстәгәндәй булдылар. Театр дусларын, К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры коллективының һәр яңа хезмәте белән ихластан танышып баручыларны коеп яуган яңгыр гына туктата алмады. Зал тамашачы белән шыгрым тулы иде. Ә сәхнә йолдызлары аларның ышанычларын аклады, чын мәгънәсендә сәнгать бәйрәме ясады.

Шамил Фәрхетдиновның «Йолдызлы яңгыр» әсәре, ике пәрдәле концерт-тамаша дип атаган әсәр, җемелдәп торган матур төсле ут яктысында, күктән йолдызлар тамып торганда сәхнәнең иң түрендә милли киемнәр киеп баскан дүрт чибәр кыз җыры белән башланып китә. Ә әсәрнең эчтәлеге бүгенге тормышыбыз турында. Сәхнәне җыештыручы Хәтимә апа, урлап китмәсеннәр өчен кадаклап куйган идән югычын тартып азапланганда, салмыш ире килеп керә. Уф, тагын кара халатлы җыештыручы апа һәм салмыш башлар икән монда дигән уй, Хәсән аганың җырлавын ишеткәч һәм Майкл Джексонга әверелүен күргәч үзгәрә дә куя. Татарстанның халык артистлары Наил Шәйхетдинов һәм Роза Хәбибрахманова Хәсән белән Хәтимә рольләре өчен койган да куйган инде. Шәп уйныйлар, шайтан алгыры. Орион Кутон ролен башкаручы артист Илдус Фәиз исә Чарли Чаплин, Радж Капурлар уенын искә төшерде. Егеттә осталык җитәрлек икән. Ул үзенең уены белән тамашачыны ихластан шатландырды. Хәер, башка артистлар уенына карата да шуны ук әйтеп була. Сәхнәдә чыгыш ясаучылар-катнашучылар утыз кеше булса да, һәр артист тамашачыны кызык-көлке, тапкыр сүзе белән җәлеп итте.

Сәхнәдә яшьләрнең күпләп катнашуы аларга чын мәгънәсендә йолдызлар кебек балку, җемелдәү, яну мөмкинлегенә бирдә.

Әлеге әсәр драма һәм комедия театры артистларының рольләрне башкару осталыгы белән бергә, аларның җырга, биюгә сәләтләрен дә күрсәтте. «Дулкын» бию коллективындагы Зөлфия Зарипова, Илсөяр Сафиуллина, Җәмилә Әсфәндиярова, Ләйсән Мәхмүтова, Гөлчәчәк Исмәгыйлева, Миләүшә Нәҗмиева биегәндә, үзеңдә биисе килү теләге туу да гаҗәп түгел.

Җырчылар да драма һәм комедия театры артистлары Мамай Мөфлихетдин — Марсель Сабиров, Зифанур Бармакова — Гүзәл Гарәпшина, Ренас Заманов — Ирек Әхмәтханов, Готфан Җилкуаров — Ринат Шәмсетдинов, Нур Күпъяшәргалиев — Фаил Бикмуллин тамашачы күңеленә үтеп керердәй җырлар башкардылар.

Индә тамашаның авторы хакында берничә сүз. Ш.Фәрхетдинов тамашачы күңеленә хуш килердәй әсәр иҗат иткән һәм ул үзе дә тамаша үзәгендә кайный — режиссер-конферансье ролендә уйный. Шәп башкара Шамил үз вазифасын: аның авызыннан «Тропиканка», «Санта-Барбара» телесериалларына карата да, тормышыбыздагы башка уңай һәм тискәре күренешләргә дә мөнәсәбәт караш, уй-фикер әйбәт үткәрелә. Димәк, теләге булган авторга әйтер сүзен концерт-тамаша аша да халыкка-тамашачыга ирештерү мөмкин икән.

«Йолдызлы яңгыр»ны музыкаль әсәр диярга дә мөмкин. Әсәргә музыканы композитор Чыңгыз Абызов язган.

«Дулкын» коллективы башкарган биюләрне Марат Гыймадетдинов куйган.

«Йолдызлы яңгыр» әсәрен театрның баш режиссеры Рәшит Заһидуллин сәхнәләштергән.

Театр коллективының бу хезмәте сезонны бизәп, баетып торыр дигән теләктә калабыз.

Сәрмәдия СӨЛӘЙМАН.

1 нче биттә «Йолдызлы яңгыр» тамашасыннан бер күренеш. Уртада — Татарстанның халык артисткасы Роза Хәбибрахманова.

Әкрәм **ШӘФИГУЛЛИН** фотосы.

Роберт МИҢНУЛЛИН

Атнабай

Атнабай Әнгам абый Әнгам Касыйм улы Атнабаев Шагыйрь һәм драматург Исем-дәрәҗәле, абруйлы әдибебез Башкорт әдәбиятында тоткан олы урыны бар Халык арасында популярлыгы, дан-шөһрәте җитәрлек Ул — фигура, легендар шәхес Ә минем өчен ул — кумир Яшьлегем кумиры

Әдәби тәнкыйтьтә, каләмдәшләре дә Атнабайны үзләренең җылы сүзләре белән артык иркәләмәде бугай Әндәшми калу күрмәскә тырышу, битарафлык — үзе тәнкыйтьнең бер төре бит Аның ачысын шагыйрь үзе сизде микән? Бәлки әдәбият сөючеләр арасында популярлыгы аркасында ул аңа мохтаҗ та булмагандыр Шул популярлыгы барысын да каплап баргандыр. Нәкъ менә үзенең популярлыгы белән ул башкалардан гомере буе аерылып торды да Халык арасында аның шикелле шөһрәт казанган шагыйрь башкорт белән татарда тагын бар микән? Билгеле, популярлыкның да төрлесе булырга мөмкин Берәүләр шигъри мохитта бик популяр икенчеләр — югары даирәләрдә, өченчеләр — милли җирлектә дүртенчеләр — исем-дәрәҗәләре, орден-медальләре, тоткан эше, ягъни кәнәфие белән Атнабай исә фәкать үзенең иҗаты белән халык мәхәббәтен казанды Шигырьләре һәм сәхнә әсәрләре белән меңләгән күңелләрне яулап алды Моңа кадәр шигырьне бар дип тә белмәгән, шигырьгә исе дә китмәгән туң йөрәкләрнең дә хисләрендә уйный алды Шигъриятнең киң катлам укучыларга җиткерүдә, шигырьнең тәэсир итү мөмкинлекләрен киңәйтүдә Атнабайның шигырь һәм поэмалары әйтеп тә бетерә алмаслык зур хезмәт күрсәтте Аны егылып укыдылар, авызларын ачып тыңладылар Гади авыл кешеләре дә, гади район секретарьлары да, фән эшлеклеләре дә, сәүдә хезмәткәрләре дә бердей мөкиббән аңа Шунысын да әйтергә кирәктер, халык аны ниндидер бер илаһи буй җитмәс итеп түгел, ә үз кеше итеп, үз шагыйре итеп кабул итте. Аның популярлыгы да шуңа нигезләнгәндер әле.

Бүгенгедәй хәтеремдә әле урта мәктәптә укып йөргән чагымда Әнгам Атнабаевның шактый калын шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы дөнья күрде. Мин аны район үзәгендәге ягъни Югары Яркәйдәге китап кибетеннән, кош тоткан шикелле алып кайткан идем. Берне генә дә түгел, берьюлы биш-алты данә Ни өчен шулай күпләп алганмындыр, әйтә дә алмыйм инде хәзер Берсен әнкәйгә калганнарын энекәшләргә сеңелкәшкә дус-ишләргә биреп бетердем бугай Үземнеке әле дә үзем белән Атнабай белән ныклап «җенләнүем» шул китаптан башланды да инде Аңа кадәр мин аны «Кызыл таң»да чыгып килгән зур-зур шигъри шәлкемнәре аша гына белә идем Ул китап минем шигъри язмышымда хәлиткеч роль уйнагандыр дисәм дә ялгышмамдыр Ул шигырьләрне яттан өйрәнүләр Атнабайга ияреп шигырь язулар Аларның «Ә Атнабаевка ияреп» дип куйганнары да бар куймыйча гына язылганнары да хәтсез. Өйрәнчек шигырьләр Нишлисең сукырларча иярелгән Атнабай иҗатының шундый сихри бер тарту көче бар. Ниндидер йогышлы шигырьләр алар

Ә инде мин яраткан шигырьләре, әлбәттә. «Кара икмәк», «Бер генә», «Тош», «Чаптарым», «Без малайлар идек», «Туфрак», «Кызык бит», «Үлем килгәч», «Әй усал да икән бу дөнья». Ә төн йокыларын качырган мәхәббәт лирикасы? «Син китәргә тиеш бөтенләйгә» «Сагынам» «Сине уйлап кояш бата», «Китәсеңме?» «Син янмыйсың хәзер», «Капка төбендә» Шушылай Атнабайның бөтен шигырьләрен санап чыгарга мөмкин Ә ул шигырьләрне укып яшьрәк чакта теләсә кайсы чибәр кызның һушын алырга була иде Эчендә җаны булган нинди генә яшь йөрәк битараф калыр икән шагыйрьнең әлеге шигъри юлларына. Безнең яшьлектә гашыйкларның куен кесәләрендә йөри торган иде алар Хәзер яшьләр башкарак бугай инде. Аларны шигырь белән генә алдыру авырдыр Әмма Атнабайның ул шигырьләре минем өчен гади шигырьләр генә түгел Алар — минем яшьлегем шигырьләре. язмышым шигырьләре, мәхәббәтем шигырьләре Мине олы шигъриятькә алып килгән шигырьләр. Шул ук вакытта һәрчак чабуымнан тартып торган, шактый еллар үземчә язарга ирек бирмәгән үземне табарга комачаулаган шигырьләр Алар минем каныма сеңгән Мин аларның күбесен яттан беләм Яшьлегемдә сәхнәләрдән сөйләгәнмен, дус-ишләремә укыганмын. Хәтта телевидениедә .. Моннан 25 еллар элек Илеш үзешчәннәре концерт куярга, ниндидер смотргамы, конкурскамы барды Мин анда Атнабайның «Замандашым» поэмасыннан бер өзек укып катнашкан идем Шәп сөйләгәнгәме икән, әллә Атнабай поэмасы булгангамы мине телевидениегә сайлап алдылар Ул чакта әле алдан яздырып алулар юк, туп-туры экранга чыгасың Камера алдында мин беренче тапкыр Шулай да каушарга исәп юк Горур гына башны күтәреп «Төзелештән син авылга кайттың», — дип башладым да тынып калдым ..

Оныттым гына бит поэма юлларын. Әй искә төшерергә тырышам Төшми генә Тез буыннары дерелди башлады. Тирләп чыктым Күпме вакыт узгандыр. искә төште тагы үзе «Кечерәеп калган авылың», — дип алып киттем Барыбер ерып чыктым, тик кәеф нык киткән иде Ә иптәшләр кулны кыса, котлый, «молодец» дип тә җибәрәләр. Баштa шаярталар дип уйладым «Ничек инде, мин әйтәм, оныттым бит сүземне» Көләләр генә. «Курыкканга гына куш күренгәндер», — диләр Баксаң, тегеләр минем туктап калганымны бөтенләй сизмәгәннәр икән Каушаудан үземә генә шулай озак булып тоелган, күрәсең Менә шуннан соң онытып кара инде Атнабай шигырьләрен

Атнабай шигъриятенең серләрен эзлим Беренче карашка, бер сере дә юк шикелле Барысы да гап-гади, үтәли күренеп тора, бөтен сүзләре дә таныш Шигъри бизәкләргә, метафораларга, чагыштыру-мазарларга исе дә китми фикерне образларга төреп булышмый, табигать күренешләрен нечкәләп тасвирлауны да күрмәссең. Ахылдауга-ухылдауга корылган пафос та хас түгел аңа, мәхәббәт лирикасына хас төчеләнү дә, сентиментальлек тә күзгә ташланып тормый Аның шигырьләре боек көчкә — сүз көченә корылган Дөресрәге, хис-эмоция көче, тапкырлык, җорлык көче ул Халыкчанлык, тормышчанлык та шуннан киләдер, күрәсең.



Әнгам Атнабаев һәм Роберт Миңнуллин.

Аннары аның шигырьләре һәрвакыт актуаль яңгырый Көн таләбе, чор таләбе аның өчен — күңел таләбе Шуңа күрәдер дә аның шигырьләре кеше күңеленә якын, табигый яңгырашлы Ул күп очракта шагыйрь булырга тырышмый шагыйрь булып уйнамый. Шигырьләрендә ул гап-гади бер гашыйк, гап-гади бер авыл егете, гап-гади бер авыл агае Гап-гади хисләрне, төшенчәләрне, күренешләрне, кичерешләрне, хәтта артык примитив күренгән әйберләрне дә шигъри биеклеккә күтәрә белүче шигырь остасы. Баксаң җир-туфрактан, реаль тормыштан аерылмыйча да, шул ук мәхәббәтне яшьлек хисләрен биекләргә күтәрергә югары чөяргә мөмкин икән. Ә бит шагыйрь язарына ризыкны әллә кайлардан эзләп изаланмый шул ук кара икмәк шул ук атлар, этләр, шул ук туган туфрак Ул хисләр абстракт булмаганга кадерле, якындыр да безгә

Шагыйрь әйтергә теләгәнен афоризм дәрәҗәсенә җиткереп әйтә белә. Гади сөйләм үрнәкләрен урыстан кергән халыкта еш кулланылган гыйбарәләрне кертеп җибәрүе белән дә шигырьнең эчке аһәңен, тәэсир итү көчен арттыра Шигырьләренең беренче юллары ук укучының күңелен иләсләндерә, җәлеп итә торган. «Бу кешегә һәрчак нидер җитми», «Гомер буе мине өйрәттеләр», «Аның белән култыклашып уздың», «Мин бер көнне кинәт үлеп киттем» .. Ләкин башлау белән генә түгел бит әле Шулай ук оста итеп төгәлли белергә дә кирәк Атнабайның осталыгы нәкъ менә шигырьне очлый белүендә вакытында һәм урынында нокта куя белүендә ачык чагыла «Ун бер малай үстек авылда... Сагындыра икән бары да!», «Кеше диеп мине йөретмәгез, шушы җирне әгәр онытсам», «Казанны сагынып барам да, Уфамны сагынып кайтам», «Кеше үзенең боек күңеллеген каян белер иде үлмәсә», «Туган якка кеше барамыни, туган якка кеше кайта ул» Һәрберсе канатлы сүз булырлык юллар

Атнабай үзенең шигъри мәктәбен тудырган шагыйрь. Билгеле, бу хакта берәүнең дә әйтергә батырчылыгы җитми әлегә Аннары ул үзе дә Такташка мәхәббәтле Баштагы чор иҗатында Такташ тәэсире бераз чагылып киткәли дә Хәзер инде Атнабайның үзенең тәэсире турында сөйләргә вакыт. Аның үзеннән соң килгән шагыйрьләргә, гомумән, шигъриятькә тәэсире турында Әгәр дә соңгы егерме-егерме биш елда поэзиягә килгән күп кенә башкорт һәм татар шагыйрьләренең иҗатына күз салсаң, һичшиксез, Атнабай чалымнарын күрербез. Аларның аерым шигырьләрендә атнабайлык ярылып ята Әлбәттә, турыдан-туры иярүләр дә, кабатлаулар да, тема уртаклыклары да, Атнабайдан күчкән шигъри сурәтләр дә очраштыра. Арада уңышлы дәвам итүчеләр дә бар Әзер штампларга, калыпларга салып шигырь язучылар да җитәрлек. Монысы да Атнабайның популярлыгына бер мисал.

Атнабай — сәхнә шагыйре дә Аны укырга да, тыңларга да кирәк Андагы актерлык сәләте профессионалларны да көнләштерерлек. Ә инде аның сәхнәдә үз-үзен тотышы, шигырь укуы үзе бер сәнгать. Ул бит Евтушенколар, Вознесенскийлар кебек үк 60 нчы еллар башында популярлык казана башлады Шигырьнең, китап кысаларына гына сыймыйча, зур залларга бәреп чыккан чагы Шигырьнең мәдәният сарайларында, театрларда, мәйданнарда, стадионнарда яңгыраган чагы. Атнабайның да чәчәк аткан чагы Дөрес, ул чорда Атнабай үзе генә түгел иде. Н.Нәҗми, Р Сафин, М Кәримов, соңрак Р Бикбаев, С Әлибай Безнең Казанда — Р.Гаташ, Зөлфәт, М Әгъләмов... Аларның һәрберсенең үз сөйләме, үз стиле Әмма Атнабай кебек шигырь укучыны күргәнем юк әле Дөрес, сәхнәдән бөтен көчкә кычкыручы, ертылырга җитеп көчәнүче яисә артистланучылар бар ул шагыйрьләр арасында да Ясалмалылык кемгә кирәк тә, аның белән хәзер кемне алдый аласың.

Атнабай белән әдәби очрашулар әдәбият сөючеләр өчен үзе бер бәйрәм. Без аның белән кайларда гына очрашмадык Уфа белән Казанда да, Илеш белән Сарманда да Бөре белән Минзәләдә дә Агыйдел белән Базы буйларында. Дим белән Ыкта Укучы балалар белән дә очрашкан булды, студент яшьләр белән дә, колхозчы агайлар арасында да Иң беренче күрешүебез, мөгаен, Илештә булгандыр. 1968 елның ап-ак кышы Илештә башкорт әдәбияты һәм сәнгате көннәре бара Район кунаклар белән мәш килә Кунаклар арасында, әлбәттә инде, Әнгам Атнабаев та бар Илештә һәрчак көтеп алынган кунак. Район үзәгендә уздырылган әдәби-музыкаль кичә аеруча истә калган «Җиз кыңгырау моңнары» исемле искиткеч җырның премьерасы нәкъ шунда булды Илештә туган җыр. Вәсил Хәбисламов көен уйнап күрсәтте Атнабай шигырен укыды

Җиз кыңгырау тагып кына,
Атларда чабып кына,
Килер идем яшьлегемнән
Тик сине алып кына –
Атларда чабып кына,
Чанага салып кына.

Атнабайга хас җорлык белән мыек астыннан гына сизелер-сизелмәс кенә елмаеп соңгы юлын укыгач, халыкның шаулатып кул чабуын күрсәң, искиткеч мәле иде Әмма шагыйрь соңгы юлын тамашачы өчен генә өстәгән булып чыкты Соңыннан ул аны бер тапкыр да бастырып чыгармады Гомумән, халык белән очрашканда Атнабай шундый нечкәлекләрне бик оста файдалана белә Аның һәр сүзе уйланган булыр. Тыңлаучыга ниндирәк сүз кирәген әллә каян белеп торыр Саллы, салмак кына сөйләр, «ни», «э-э-э» дигән булып паузалар ясар Халык көтә Атнабай ашыкмый Өстәлдәге кырлы стаканнан, эчәсе килмәсә дә, су алып эчкән була. «Атнабай эчәргә ярата икән», — дип уйлыйсыз инде», — дигән була. Тамашачыга шул гына кирәк Шаулатып кул чаба, егылып көтә Бераз җитди сүз сөйләгәннән соң мәхәббәт, көнкүреш темаларына кереп китә дә президиумда утырган абзыйларга карап: «Политик яктан хата җибәрмәдемме?» — дип сорап куя Халыкка кызык, ә җитәкче иптәшләр шагыйрь сүзен чынга алып: «Юк, юк!» — дип тынычландырырга ашыгалар Кичә дәвам итә Илештә булса, һичшиксез, Илеш җирен, аның игенчеләрен мактый, мәхәббәтен аңлата башлый «Әгәр дә үземнең Түтешлем булмаса, мин, әлбәттә, Илештә туган булыр идем», — дип тә җибәрә Бу сүзләре халыкның күңеленә май булып ята. Шагыйрь алкышларга күмелә Тамашачыга да күңелле, Атнабай да канәгать. Ә инде бер матбугатта да басылмаган «Аракыга мактау» шигырен дә укып җибәрсә... Хәер, ул аны күбрәк мәҗлесләрдә генә укый иде бугай. Мин ул шигырь хакында беренче тапкыр район газетендә эшләгәндә редактордан ишеткән идем. Җитәкчеләр җыелган бер мәҗлескә ул да чакырылган булган. Икенче көнне, Атнабайның шул шигыре турында шаккатып сөйләгәннәре хәтердә калган

Атнабай белән бер кичәдә чыгыш ясау, бигрәк тә аннан соң шигырь уку шагыйрь өчен бик авыр хәл Үземнең шундый хәлдә калганым бар. Чөнки җорлыкта, сүз уйнатуда, шигырь укуда, халык белән уртак тел табуда аны уздыру мөмкин түгел бер эш ул. Тырышып караучылар яшьрәкләр арасында булды шикелле. Аңа охшарга тырышып мыек та җибәреп карадык, аныңча шигырьләр дә укыдык Булмагач, булмый икән, чукындырасыңмыни аны.

Атнабай тумышы, тормышы белән дә, бөтен булмышы белән дә Башкортстан шагыйре Башкортныкы да, татарныкы да. И.Юзеев булса, «Башкортстанда Атнабайны эте дә белә, бете дә белә», — дип шаяртыр иде. Чыннан да, үзенең туган җирендә үтә дә популяр шагыйрь булуына карамастан, читтә аны бөтенләй диярлек белмиләр. Татарстанны исәпләмәгәндә, әлбәттә Бездә дә аны күбрәк драматург буларак, аннары «Җиз кыңгырау моңнары», «Бәхет», «Ярамыйга карамый», «Әнкәй, синең куллар» кебек җырлары аша билгеле. Аның Мәскәүдә китап чыгарганы булмады шикелле Казанда да чыгара алмады Бәлки, үзенең дә теләге булмагандыр. анысын әйтә алмыйм Шунысы кызык, Мәскәүдә ел саен китаплар чыгарган шагыйрьләребезнең дә күбесенә урысның исе китмәдә. Атнабайның да абруе төшмәдә Һаман шул Атнабай булып калды Бу яктан караганда, ул отты гына булса кирәк. Чит телдә китап чыгарам дип, тәрҗемәләр белән вакланмады, вакытын сарыф итмәде. Үз укучысы өчен язды, аңа хезмәт итте.

Гомумән, бу җәмгыятьтә үзең булып калулар, башкаларга охшамаска тырышып яшәүләре бер дә җиңел эш түгел Башкалардан талантлырак, популяррак булсаң, бигрәк тә Көнләшү, аяк чалу, юл бирмәү кебек тискәре күренешләр безнең зыялылар арасында да җитәрлек. Уфада яшәмәгәч, андагы әдәби дөньяның нечкәлекләрен белеп тә бетермим Дөресен генә әйткәндә, кызыксынганым да юк Әмма мин Атнабайны баш бирмәс шәхес дип беләм Нинди генә хәлләрдә дә үзе булып калган, як-якка салуламаган, заман җилләренә бирешмәгән принципиаль бер Уфа зыялысы ул Төрле чаклар булды, заман җилләре тегә яктан да, бу яктан да истә Сыгылмыйча, сынмыйча калулары җиңел булмагандыр Егетлеге саклап калгандыр.

Атнабай! Мин аны яшьлегем кумиры дип язган идем Юк икән, бүген дә ул минем иң яраткан шагыйрьләремнең берсе, һәрвакыт уртак тел табучы, һәрчак сагындырып торучы өлкән дустым Ул һаман да егетләрчә, шагыйрьләрчә Ул һаман да җор телле, тапкыр сүзле Ул һаман да юлда Аны авылларда, калаларда үзенең яраткан укучылары көтә

РЕДАКЦИЯДӘН: Әнгам Атнабаевның шигырьләрен газетебезнең киләсе саныннан укый аласыз.

И ТУГАН ТЕЛ...

«МӘДӘНИ ҖОМГА» ГАЗЕТАСЫНЫҢ МАХСУС КУШЫМТАСЫ № 4 (27)

Хисап булды булуын, ә эш?..

...һәркемнең
Үз теле, үз йөзе. үз төсе
Бер җыр — аз, бер моң — аз.
бер тел — аз.
Йөз телдә сөйләшеп үс, кеше!

Хәсән ТУФАН

Татарстан Дәүләт Советының октябрь аендагы чираттагы пленар сессиясендә «Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау өйрәнү һәм үстерү буенча Дәүләт программасының үтәлүе» мәсьәләсе дә каралды Сессиядә Татарстан Министрлар кабинеты рәисе урынбасары И Хәйруллин нотык сөйләде гадәттәгечә сорау җаваплар булды берничә депутат шушы темага чыгып та сөйләде

Бу көн тәртибе алдан куелмаган әзерләнмәгән иде ул депутатлар таләбе белән сессия барышында гына кертелде Мәсьәлә дөресен әйткәндә элекке Югары Советның Татар милли университетын ачарга дигән карарының һаман үтәлмәве сәбәбеннән барлыкка килде һәм сөйләшү дә нигездә шул тирәдә барды Карар да шул хакта гына чыгарылды

Аңлашу барышында республикада телләр мәсьәләсенең бер югары уку йорты ачу белән генә һич тә чикләнмәве телләр турындагы Законны үтәр өчен мөһим урын тотачак Дәүләт программасын чынлап торып гамәлгә ашыру юлында хәл ителмәгән эшләрнең әле бихисап икәнлеге тагын бер тапкыр ассызыклап әйтелде

Дөрес Премьер-министр урынбасары сөйләвеннән күренгәнчә хәрәкәт бөтенләй үк юк түгел Мәсәлән «Программаны кабул иткәннән соң милли мәгарифне үстерү милли мәктәпне торгызу өлкәсендә зур эшләр башкарылды Яңа уку елында республикабызда гомуми белем бирүче 2454 урта мәктәп булса. шуның 1113е татар мәктәбе урыс мәктәпләрендә 1700дән артык татар сыйныфы ачылды Үз телендә белем алучы татар балаларының саны арта бара. быел бу күрсәткеч 58 процент Балалар бакчасында ана телендә тәрбияләнүчеләрнең саны арта бара Милли мәгариф системасының хәлиткеч баскычы — югары мәктәпне торгызу буенча да эш алып барыла Казан финанс-экономика институты һәм медицина университетыннан кала барлык вузларда татар төркемнәре ачылган яки татар телен укыту кертелгән Бүгенге көндә мондый төркемнәрдә 3 мең. ә инде педколледж лицейларны да исәпләгәндә 7 меңгә якын студент белем ала »

Әлбәттә берничә фәннән татарча лекция тыңлап яисә татар теленнән бераз дәресләр алып кына студенттан чын мәгънәсендә милләт таянычы булырлык милли рухлы белгеч чыгачагына шик зур бу — өлегә хыял гына. моның өчен югары уку йортларының эшен тамырдан үзгәртергә кирәк Шулай да киләчәк хыял гамәлгә ашсын өчен дә бүген ышанычлы башлангычлар этәргечләр кирәк ләбаса Алар бөртекләп тамчылап җыелырга тиеш Дәүләт Советының гуманитар институт оештырырга дигән карары әнә шундый өметле бөртекнең берсе дип кабул ителде Казан дәүләт университеты нигезендә оештырылачак бу институт киләчәктә гуманитар университет дәрәҗәсенә үсәр дигән сүз дә әйтелде Монысы да берүк кәгазьдә калмаса ярар иде

Көн тәртибен караганда шулай ук милли матбугат китап басу мәдәният өлкәсендәге кайбер уңай чаралар өметле ният-планнар турында да телгә алып кителде Тик аларына да. депутатлар биргән сорауларга. алар чыгышларындагы тәкъдимнәргә дә көн үзәгендә күпләрне борчып торган башка проблемаларга да чыннан да өстән генә йөгертеп кенә күз салынды «өйрәнергә кирәк. кабаланырга ярамый» дигән сылтау белән алардан тизрәк котылырга теләү сизелде Гомумән дә югары җитәкче даирәләрдә бүген «тел — нечкә мәсьәлә ашыгырга ярамый» дигән тактика өстенлек ала башлады

МӨХӘРРИР ФИКЕРЕ

Әйе сессиядә бәян ителгән уңай фактлар кайбер чаралар һич тә тынычланырга ирек бирми алар дөресен әйткәндә башкарырга тиешле эшләр диңгезенең берничә тамчысы гына

Республикада чын мәгънәсендә гадел тиң икетеллелеккә психологик мохит тудыру ике телне дә тигез куллануга көндәлек ихтыяҗ булдыру өчен әле эшлисе дә эшлисе бар Бу эшнең уңышлы нәтиҗәле башкарылуы өчен иң башта Дәүләт Советы хөкүмәт үзләре җаваплы Бу уңайдан Дәүләт Советы Рәисе В.Лихачевның сессия барышында юл уңаеннан гына әйтеп киткән сүзләре игътибарга лаек «Телләр турындагы Дәүләт программасын үтәү юнәлешендә кертелгән чараларны көндәлек кулланышка кертү моның өчен чын ихтыяҗ тудыру буенча да хәзер нык лап эшлисе бар »

Әлбәттә моңа инде искә төшкәндә бер каралган чаралар белән. өзек-өтек үтәлгән эшләргә хисап биреп канәгатьләнеп кенә ирешеп булмый бу барыбыздан да үзебезне туган телебез алдында җаваплылык тоеп армый-талмый эшләвебезне сорый

Татар теленә ихтыяҗ тудыру мәсьәләсен «И туган тел » киләчәктә дә яктыртырга җыена Бу хакта «Сез ни өчен татарча укырга карар кылдыгыз?» анкетасына килгән җавапларда да фикер йөртелә Бүген аларның тагын берничәсен тәкъдим итәбез.

Аз сүздән
мәгънә чыгар,
күп сүздән
бәла чыгар

Әйтү бер,
эшләү башка

БЕЗНЕҢ АНКЕТА

Татарча уйлаганга күрә

Туган телем! Ни өчен мин югары уку йортында укыр өчен гомумән дә киләчәктә яшәр өчен сине сайладым әй мөкатдәс Тукай теле!? Әллә башка телләрне белмәгәнгәме? Юк аларны да беләм сине яхшы белгәнгә күрә тагын да күпмесен өйрәнә алам Ә мин сине сайладым чөнки мин татарча уйлыйм Башка телләрне белсәм дә ул телләрдә уйлый алмыйм башка милләтчә яши алмыйм Мин — татар җаным татар моңнарым татарныкы уйлавым татарча! Синең белән мин үземне ышанычлы тоям белемне дә тормыш тәҗрибәсен дә күбрәк алырмын дип ышанам!

Рәфис ҖӘМДИҺАНОВ.
Чувашия

Җавап безнеңчә булмас...

Һәркемгә дә белемне үз телендә алу җиңелрәктер Туган тел безгә ана кебек якын кадерле Ләкин үз телен түбәнсетүчеләр дә бар Мәсәлән мәктәптә татар һәм урыс класслары еш кына кайбер фәннәрне кушылып укый идек Бервакыт биология дәресендә укытучы кушылып укыйсы булгач татар классы укучыларына. аңламассыз дип башка дәрескә барырга кушты Шунда мин «Безне аңгыра дип беләсез мәллә?» — дидем Җавапны урыс классында укучы бер кыз бирде «Һәрхәлдә. без сездән акыллырак»

Димәк. ул урыс классында укып акылга утырган булып чыга Шулай итеп ул үз телен рәнҗетте — ул бит татар кызы

Минем үз телемне тагын да яхшырак беләсем килә Тик шәһәр туган телне өйрәнүгә аяк чала Чөнки бар җирдә урысча аралашу Мисал өчен транспортны алыйк Бервакытта да бер-беребезгә «Сез төшәсезме?» — дип мөрәҗәгать итмибез Татарча эндәшсәк, безгә җавап бирүче булыр дип өметләнә алмыйм

Раилә ГОМӘРОВА.

РӘХМӘТ, КАЛӘМДӘШЛӘР!

«Молодежь Татарстана» гәзите «И туган тел ..»не кунакка чакырган иде Без аңа «күчтәнәч» итеп башка милләт кешеләренә татар телен өйрәтүгә багышланган язмаларыбызны алып килдек

Яшьләр гәзите безгә урынны түрдән, мулдан бирде — аның 10 ноябрь санының урта куш бите тулысы белән өлеге материаллардан тупланган иде Авторыбыз инженер Равил Хөсәенов Казан компрессор акционерлык җәмгыятендә оештырган «түгәрәк өстәл» хәбәрләре Татарстан китап нәшриятыннан тәкъдим ителгән язмалар галим И Ганиевнең «Фәлсәфәне татарча укытып буламы?» дигән чыгышы һәм башка язмалар укучыларда һичшиксез кызыксыну уяткандыр

Рәхмәт каләмдәшләргә! Кунак ашы — кара-каршы — без дә аларга «Түрдән рәхим итегез!» дибез.

БИШЕК ҖЫРЫ

Ләбиб АЙТУГАНОВ

Йокла, улым

Кичке шәфәкъ сүнде күптән
Кояшны каплый таулар
Тиздән инде сине эзләп
Тәрәзәдән ай карар

Кушымта:
Йокла, йокла, улым,
Без бергә икәү.
Каршыларбыз таңны
Әлли-бәлли-бәү!
Әлли-бәлли-бәү!

Тагын балкып кояш чыгар.
Кырларга сибәр нурын
Алсу таңдай матур булсын
Күз нурым тормыш юлың
Кушымта.

Кичке шәфәкъ сүнде күптән
Кояшны таулар каплый
Нуры белән сине назлап
Тәрәзәгә ай карый
Кушымта.

Бу шигырьгә Ш.Монасыйпов көй язган.

Сәхифәбездә:

- Туган телне — гамәлгә! Дәүләт Советы сессиясендә
- Шушы телдә уйлаганга күрә ул миңа кирәк Анкетага җаваплар
- Докторлык диссертациясе якланды Котлыйбыз!
- Яңа рубрика Аңлашыйк әле
  Сүз янә алфавит турында
- Д.Карнегиның сөйләмият дәресләре
- Татар теле турында яңа китаплар
- Мирасыбызны барлыйбыз
- Бишек җыры Конкурс дәвам итә

АЛФАВИТ ҺӘМ ФӘЛСӘФӘ

Алфавит (әлифба) мәсьәләсе халык тормышының төрле тармакларына килеп керә.

Мәсәлән, ул сәясәткә дә туры-дан-туры карый алфавитыбыз белән без кайсы дөньяга (көнбатышка йә көнчыгышка, исламга йә христианга) юнәлеш тотабыз? Кайсы дөнья безнең холык- табигатькә якынрак? Кайсы юнәлешне алып, милләтебез чәчәк атар яисә йомылып калыр?

Бу сорауларны ачыклауда милләтнең фәлсәфәсен аңлап эш итү сорала. Ә милләт фәлсәфәсе тел фәлсәфәсендә чагылыш таба.

Телчеләр арасында татар теле «ялкау тел» дип әйтүчеләр очрый. Сәбәбен телнең сингармонизм кагыйдәләренә буйсынуы белән аңлаталар. Имеш, сүзләрне ирен белән телне бер урында тотып кына, һава сулышы белән генә әйтәләр: Физикада инерция дигән закон бар: тиз барган машинаның рулен тиз борып булмый, машинаның капланып китүе ихтимал. Тракторны бер урында 90 градуска борып җибәреп була. Телдә дә шул ук хәл. Әйтик, урыс теленең әйтелеш тизлеге белән татар телендә сөйләшсәк, татар сүзләре әкрен, сузылып әйтелә. Ә бит авыл кешесен тыңласак, аның сөйләме тизрәк бара, һәм татар теле ялкау сөйләм дип әйтеп булмый. Тарихтан да дәлил бар. төркиләр күчмә халык буларак күп аралашкан, шуңа күрә телләре дә халыкара аралашу теле буларак камилләшкән, мәсәлән, татар телендә Алтын Урда дәүләтендә сәүдә бик яхшы барган.

Безнең күзәтүләргә караганда, татар телендә саннар системасы инглиз, алман һәм урыс теле системаларына караганда сүзләрнең кыскалыгы һәм кагыйдәләренең азлыгы белән камилрәк Гомумән дә, язма татар теленең хәбәрне тизрәк бирүен 20 нче елларда Галимҗан Шәрәф тә исбатлаган Аның күзәтүе буенча, гарәп хәрефләренә нигезләнгән язма татар теле әлифбасында язу һәм уку латин-кириллныкына караганда 10-15 процентка тизрәк булган. Бу мисаллар татар теленең өңгәмә өчен уңай булуын дәлилләп тора

Татар теленең фонетик системасын алфавит аша үзгәртү телнең сөйләм тизлеген киметә. Бу исә телнең куллану даирәсенә дә йогынты ясый. Моны мисаллар белән ачыклыйк. «Әбиме», «дәү өниме»? «Сезме», «синме»...? Кечкенә чакта төрле авылларга кунакка йөрергә туры килде: Казан артында, Чаллы ягында, Пермь өлкәсенең Барда районында. Ул чакта анда өлкән апаларга, аннары үз аталарының һәм аналарының әнисенә «әби» дип дәшәләр иде. Соңгы 20 елда татар теленә әби мәгънәсендә «дәү әни» сүзе кереп бара. Гасыр башында әбигә «дәү әни» дип дәшкән булсалар, мыскыл итү булган булыр иде. Чөнки ул исем белән ислам дөньясында бер гаилә балалары әтисенең беренче хатынына дәшкәннәр. Интернациональ сәясәт татарның рухын тел аша да сындырган — бездә алман, француз һәм инглиз теленнән күчергән сүз активлашкан: (Grand mot&er, gross muter — дәү әни). Ә бит дини тарихыбыз кире кайта — бу сүзнең мәгънәсен хәзер ничек аңларга?

Гасыр башында Аллаһыга «син» дип дәшкәннәр... Нигә хәзер «син» дигән сүзнең куллану даирәсе кимеде? Бүгенге көндә хөрмәт йөзеннән татарлар бер-берсенә «Сез» дип дәшә. Элекке язмада баш хәреф белән «Сез» дигән сүзне биреп булмый иде, чөнки гарәп алфавитында баш хәреф төшенчәсе юк. Элекке заманда «Сез» дип түрәгә генә мөрәҗәгать иткәннәр. Түрәлектә татар дөньясында берничә кеше утыруы мөмкин булган, урыс дөньясында — бер генә кеше. 17-18 гасырларда да урыс дәүләтендә татар теле дәүләт теле дәрәҗәсендә яшәгәнгә, татарның берничә түрәгә мөрәҗәгать иткән «Сез»е урысның бер генә түрәсенә тәрҗемә итеп «Вы» дип дәшүгә китергән. Урыс теле фәлсәфәсендә шәхесне җәмгыятьтән аеру гадәткә кергән. Хәтта гаиләдә дә бер-берсенә Иван Иванович формасында дәшә торган булалар. Татар дөньясында шәхесне читләтү — Сез дип дәшү — ят булган булса кирәк.

Кирилл алфавитындагы баш хәрефләр татарга да кеше исеменең мәгънәсен үзгәртергә юл ачкан. Кеше исеме элекке заманда шәхесне аеру йә аның сыйфатын билгеләү вазифасын үтәгән. Бүген исә ул аның таныгы мәгънәсен ала.

Хәтта җанварлар да элек «сарыбай», йә «мыраужан» дип «җанландырылган» булса, баш хәреф килеп керү белән шул хайваннарга язма аша исем биреп кеше рәтенә кертү гадәткә керде.

Китерелгән мисаллар нигезендә без гарәп алфавитыннан китеп, тел аша, гореф-гадәтләребезне күрәбез. Янә берничә мисал-фикер. «Төймә» дигән сүз, Каюм Насыйри 1885 елда күрсәткәнчә, «тимә» белән тәңгәл булган. Икесе дә «ти» тамырына кайтып кала. «Вак», «Ват» һәм «ванна» сүзләре гарәп алфавитында һәм яңа әлифтә «уак», «уат» һәм «уына» дип язылган. Монда нигез «у» дигән сүз. Күрәсез, телнең морфема системасы латинга һәм кириллга күчкәч зәгыйфьләнә: морфемалар саны үсә башлый — телнең фәлсәфәсе үзгәрә.

Тел ике ысул белән үзләштерелә: мантыйк һәм хәтер аша. Морфема системасы үсүе белән тел хәтере үсә, ә мантыйгы кими башлый. Мәсәлән, кытай телендә 2000-2500 морфема-иероглиф кулланыла, татар телендә 5000 чамасы. Ә урыс телендә 17000 чамасы кулланыла. Татар телендә кулланылган морфемаларның яртысыннан күбрәге төрле юллар белән тел зәгыйфьләнүе нәтиҗәсендә килеп кергән Әйтик:

1) әле әйтелгән «вак» һәм «ват», янә «виноград», (йөзем) сүзләренең килеп керүенә алфавитка яңа хәрефләр өстәлү сәбәп булды;

2) баш хәрефләр килеп керү белән кеше исемнәре аерым морфемалар төркемен билгели башлады. Телгә ятышлы булмаган исемнәр кушылып, сөйләмдә сингармонизм кагыйдәләре имгәтелде;

3) яңа терминнар булдырабыз дигән сәбәп белән телчеләр алынма сүзләрне үзгәртмичә кертә башлады. Мәсәлән, «елка», «компьютер» һ.б.;

4) кайбер сүз-терминнар «бозылган телефон» уенындагы сыман бозылып телдән-телгә дә күчеп китә. «Мөслим» — гарәптә дин кешесе, «мусулман» (мөслим + ан) фарсы һәм алман телендә дин кешесе, «мусульманин» урысча ислам динен кабул иткән кеше; «кабу», «капка», «каплы», «капкач», «капчык», «капкан» һ.б. сүзләр татарның «кабу» тамырыннан. Шулай ук инглиз, француз телендәге «cad» (каплы арба), «cap» (кепка), «cup» (чынаяк) сүзләренең төркиләрдән кергәне шик тудырмый. Инглизнең баш киеме «сор» урыс телендә «кепка» исеме белән керә, ә алардан «кепка» татар теленә килеп керде;

5) татар теленең язу кагыйдәләрендә дә каршылык барлыкка килде: «мәгънәви яктан» (мәгънә ягыннан) дибез, «урмани яктан» түгел бит, «урман ягыннан» дибез; «унбер» дибез, ә нигә алайса — «егерме бер» һ.б.

Болар барысы да алфавитыбыз язмышы турында тагын бер тапкыр уйланырга куша түгелме?!

Равил ҺАДИ.
Казан.

«И»не ничек укырга?

И хәрефе һәм авазы турында фәнни әдәбиятта җентекле тикшеренү юк әле Ә бит бу бәрәмлек күп вазифалы: ул татар телендәге нечкә сүзләрдә дә (**җиләк, нәтиҗә, икмәк, тирәк** һ.б.), калын сүзләрдә дә (**ризык, китап, инану** һ.б.) — ягъни сингармонизм законына буйсынган сүзләрдә һәм кайбер очракларда, калын һәм нечкә сузыклы сүзләрдә (**никадәр, самимилек, хакимлек, шигырь** һ б) — сингармонизм законына буйсынмаган алынма сүзләрдә дә языла.

Татар теленең үз сүзләрендә **и** авазы (һәм башка сузыклар) иҗек башында бары сүз башында гына языла **иген, иртә, илче, истәлек** һ.б.ш. Кайбер алынма сүзләрнең уртасында иҗек башында килгән **и** хәрефенең функциясе нинди соң? **Наил, Наилә, даирә, саилче (хәерче), хаин (хаинлек, хаиннәрчә, хаинәнә), Рәис, Раисә, Раил, Фаил, Саимә, яисә** кебек сүзләрне ничек укырга? Ничек юлдан юлга күчерергә? Ул сүзләрдә кайсы сузыкка басым төшә? Мәктәп укытучысы өчен болар гадәти кагыйдәләрдә яктыртылмаган, өзер калып, шаблон белән сыеша алмаган нәрсәләр Боларны хәл итү өчен укытучыга сиземләү сәләте, фантазия һәм фикер мөстәкыйльлеге кирәк.

Алынма сүзләрнең уртасында иҗек башында килгән и авазының функциясе аерым иҗек ясау түгел, ә үзеннән алда килгән басымлы озын сузыкны (а ны, ә не) кыскарту

Сүз уртасындагы иҗек башында килгән и сузыгы үзе генә иҗек ясый аламы? Иҗек ясый алса, шул сүзләрнең әйтелешенә хилафлык килә түгелме?

Ул сүзләрне юлдан юлга күчергәндә **и** авазы, бәлки, үзеннән соң килгән сузыклы иҗек белән бергә генә күчерелергә яки иҗек ясарга мөмкиндер: **На-ил, На-илә, га-илә, да-ирә, я-исә, Са-имә, Ра-илә** һ.б. Андый сүзләрне әйткәндә басымлы иҗектән соң килүче өлеш кисәк бүленә Болай сөйләшергә өйрәткәндә укучылар ул сүзләрне дөрес итеп әйтә һәм юлдан юлга дөрес күчерә белер иде.

Без татар телендәге аерым сүзләрнең семантик (мәгънәви) үсеше турында күп язып, күп сөйләшсәк тә, авазлардагы үсеш мөмкинлеге турында бик аз уйланабыз Бу нәрсә дигән сүз? Татар телендәге кайбер авазлар, билгеле бер фонетик чолганышта һәм, контекст эчтәлегенең таләбе белән, төрлечә әйтелеп, мәгънәне үзгәртүгә китерергә мөмкин Сүзебез и хәрефе һәм авазы турында.

Кайбер язучылар яки шагыйрьләр һәр авазның мәгънәви үсеш мөмкинлекләрен сиземли, алар ярдәмендә үзенә генә хас соклангыч эмоциональ аһәң тудыра. Татар шагыйрьләре арасында бөек Тукай бу юнәлештә дә бүгенгә кадәр беренче урында тора дисәк, ялгышмабыз. Әсәрләреннән күренгәнчә, и авазының мәгънәви үсеш мөмкинлекләрен аннан да нечкә сиземләүче шагыйрь бүген дә юк кебек.

Туган телебездә шагыйрь тапкан шундый төсмерле матурлыкны без — Тукайдан соң яшәүче ничәнче буын — бүген дә аңлап, тиешенчә укый (һәм укыта) белмибез әле.

Фәнни һәм методик әдәбиятта **и** хәрефенең аерым язылганда укылыш үзенчәлеге турында әйтелмәү укытучы өчен төрле авырлыклар китереп чыгара. Мәсәлән, Г Тукайның **«Эшкә өндәү»** шигырендәге түбәндәге юлларны ничек укыганда, текст тукымасына тәэсирлек, эчтәлеккә ятышлы эмоциональ яңгыраш өстәлә:

И сабыйлар, эшләгез сез. Иң мокатдәс нәрсә — эш.

И урынына әй дип укып карыйк:

Әй сабыйлар, эшләгез сез. Иң мокатдәс нәрсә — эш.

Беренче очракта **и** язылышы буенча дөрес кулланылса да, әйтелеше буенча урынлы файдаланылмый, чөнки, гадәти сөйләмдә мөрәҗәгать формасы итеп, гадәттә **әй, эй** дифтонглары кулланыла Шулай сөйләшергә өйрәнгән бала шагыйрь әйтергә теләгән фикерне бөтенләй ялгыш аңларга мөмкин.

И сабыйлар дигәндә, **и** аша мәгънәгә кимсетү, кечерәйтү төсмере бирелсә, **әй сабыйлар** дигәндә исә, көр һәм өмет тулы яңгырашлы **әй** аркылы балаларга, олысымагайтып, булачак хезмәт кешесенә мөрәҗәгать итү мәгънәсе салына Болай укыганда, шигъри аһәң көчәя, эчтәлек тиешенчә аңлашыла.

Эй сабыйлар дигәндә, мәгънәви басымны үзендә туплаган **сабыйлар** сүзе үзенең алдында ишетелгән **и** авазының семантик яңгырашы белән назлау, иркәләү, ярату аһәңе иләэ тулыландырыла.

Инде **«Пар ат»** шигырендәге түбәндәге юлларны укып карыйк:

Әйтә иртәнге намазга бик матур моңлы азан;
И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан!
Нурлы Казан!

Казан шәһәренә — барлык татарларның белем һәм мәдәният үзәгенә зур өметләр белән ашкынып килгән шагыйрь, яшь көр тавыш белән, яратып, якын итеп, үз итеп сагынып **әй** дип эндәшкәндер. Әгәр шундый олы өметләр белән килгән бөек Тукайны, Казан шәһәрен күргәч, **и** дигән дип уйласак, ялгышырбыз. **И** салкынлык, ятсыну, кимсетү билгесе булыр иде.

Бу уңайдан, **и** авазының Г.Тукай әсәрләрендә контекст шартлары белән тудырылган семантик үсеш мөмкинлеге ачыла торган башка очраклар да аз түгел. Мәсәлән, түбәндәге контекстта **явыз** сүзенә ияргән **и** аша алар белдергән уртак мәгънәгә көчәйткеч төсмер өстәлә Шуның нәтиҗәсендә, фикер көчә тагын да үткенләнә:

И явыз карчык, тарагыңнан коры калдың, дидем.

Шигырьдәге **и** авазының ярдәме белән тудырылган ятсыну, салкынлык, усал ният мәгънәсе түбәндәге юлларда да сиземләнелә:

— Ни кирәк? Кем бу? Кара төндә вакытсыз кем йөри?
Нәрсә бар соң төнлә белән, и пычагым кергери!

Икенче бер очракта исә, шагыйрь, **и** авазының семантик үсеш мөмкинлекләреннән контекстта дөрес файдаланып, мәгънәви бәйләнештәге тулы фраза барлыкка китерә. Ләкин **и** һәм ул ияргән сүзләрнең мәгънәсе бу юлы кылган ялгыш эшкә үкенү һәм ачыну, ялгышны аңлау нотасы белән сугарылган:

Су анасыннан котылгачтын, тынычланган, әни
И орышты, и орышты, и орышты соң мине.

Шулай итеп, аңлавыбызча, Г.Тукай **и** авазын контекстта үзенчәлекле кулланып, сүзләр бәйләнешенә үзенә генә хас мәгънә салып, шигырьләрендәге мәгънәви якны көчәйтә, тулыландырып бирә. Әсәр телен аңлау дәрәҗәсен арттыра.

Бу урында Г Тукайның **«Туган тел»**ендәге беренче юлларының укылышы турында да бер-ике сүз әйтми ярамас. Мең еллык шанлы тарихлы халыкның ничәмә йөз еллар буена эшкәртелеп, камилләштереп киленгән теленең барлык матурлыгын тоя алган шагыйрь генә, бәлки, үзе язган әсәрләрдә, аңлы рәвештә, шундый алымны кулланган дыр. Шагыйрь яратып һәм олылап, **И туган тел** дип түгел, ә:

Әй туган тел, әй матур тел... — дигәндер.

Әй яңгырашы белән төп мәгънәне үзендә туплаган логик басым төшкән **туган** сүзенең эчтәлеге никадәр ярату, үз итү тойгысы ала, туган телне ярату аһәңе белән тулыландырыла.

Шагыйрь күңеле кылдан нечкә, дип юкка гына әйтмәгәннәр, күрәсең. Кыскасы, безгә Г Тукай язганнарның хәрефен генә түгел, мәгънәсен дә укырга өйрәнеп һәм өйрәтеп, шагыйрьнең бөеклеген тагын да раслыйсы бар. Шуларны эшли алсак, кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәт, берсен-берсе аңлый алу, аңларга теләү тагын да яхшырыр иде, бәлки.

Без, бу юлларны язып, халкыбызның горурлыгы булган Тукайны төзәтмибез. Ләкин телебезнең шагыйрь күңеленең нечкәлеге белән генә сиземләнелә алынган һәм әсәрләренә салынган матурлыгын халкыбыз теленә (шул исәптән,башка төрки телләргә) хас булган үзенчәлекле аһәңне югалтмасак иде, дибез.

Н.МАКСИМОВ,
Укытучылар белемен камилләштерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты.

Дейл КАРНЕГИ

Ничек үзеңдә ышаныч булдырып, халыкка тәэсир итәргә

(Дәвамы. Башы 14 нче санда).

Беренчесе. максатыгызга ирешү өчен сүзне көчле һәм нык омтылыш белән башлагыз

Моның әһәмияте сез күз алдына китергәннән дә зуррак Әгәр укытучы күңелегездә ни барын белеп, омтылышыгызның ни дәрәҗәдә икәнен үлчи алса, уңышка кайчан ирешәчәгегезне әйтә алыр иде омтылышыгыз сүлпән һәм көчсез икән, уңышыгыз да шундыйрак булыр; әгәр максатыгызга үҗәтләнеп, мәчә артыннан ыргылган бульдог кебек. гайрәтле омтыласыз икән, дөньяда сезне берни тоткарлый алмас.

Димәк, үзаллы өйрәнүгә нык теләк, күтәренкелек белән алынырга кирәк Аның файдасын истән чыгармагыз, үз-үзеңә ышаныч һәм кешеләргә тәэсир итәрлек сөйли алу сәләтен булдыруның сезгә ничаклы әһәмиятле икәнен уйлагыз Акчага күчергәндә бу әһәмиятнең күпме торырын күз алдына китерегез Иҗтимагый дәрәҗәгезне күтәрер, яңа дуслар табар өчен, шулай ук җитәкче урынга күтәрелгәндә моның өчен файда итәсен уйлагыз Чыннан да, мондый сәләт җитәкче урынга сез күз алдында тоткан теләсә нинди эшчәнлектән дә тизрәк китерәчәк. Чонси М Депью болай дигән «Карьерага, җәмгать хөрмәтенә ирешүдә алдында чыгыш ясар алдыннан курку хисе белән сугышканда шундый ихтыярлы булмаска?

Икенчесе. Нәрсә сөйләвебезне яхшы белергә кирәк.

Чыгышын алдан уйламаган, планлаштырмаган, нәрсә сөйләсен күз алдына китермәгән кеше тыңлаучылар алдында үзен ышанычлы хис итә алмый Ул бөтен сукырны җитәклегән сукыр хәлендә булачак Мондый очракта ораторыбыз һичшиксез уңайсызланырга, үзен гаепле санарга, илтифатсызлыгы өчен оялырга тиеш

«Штатымның Закон җыенына 1881 елның көзендә сайландым, — дип яза «Автобиография»сендә Тедди Рузвельт — һәм бу органның иң яшь әгъзасы булып чыктым Яшь һәм тәҗрибәсез кешеләргә хас булганча. миңа да сөйләргә өйрәнү бик тә авыр булды Күпне күргән өлкән якташымның киңәше зур файда бирде — ул миңа герцог Веллингтон сүзләрен җиткерде. герцог та аларны кемнәндер ишеткәндер, әлбәттә «Нәрсәдер әйтергә кирәк булганда гына һәм аны яхшы белгәндә генә сөйлә Әйт тә урыныңа утыр»

Әлеге «күпне күргән өлкән якташ» Рузвельтка дулкынланудан котылуның тагын бер чарасын әйтергә тиеш иде Ул «Каушауны җиңү сиңа аудитория алдында нәрсә дә булса эшләсәң, кәтләр ясамагыз Әгәр нервлы хәрәкәтләрдән тыела алмыйсыз икән, кулларны артка күчереп бармакларны кешегә күрсәтми генә хәрәкәтләндерегез яисә аяк бармакларын селкетегез

Кагыйдә буларак, ораторга мебель артына «яшеренү» килешми Шулай да беренче чыгышлар вакытында өстәл яисә утыргыч артына басып, аларга каты гына тотыныгыз яки учыгызга тиен акча кысыгыз. бу ихтимал, берникадәр кыюлык бирер

Тедди Рузвельт аңа хас кыюлыкны һәм югалып калмау сәләтен үзендә ничек булдырган соң? Кыюлык, үтә тәвәккәллек рухы аңа тумыштан бирелгәнме? Юк. әлбәттә «Бала чакта чирләшкә һәм авыр сөякле булганга, үсмер елларда да баштарак нервлы, үз-үземә ышанмаучан идем, — дип искә ала ул «Автобиография»сендә — Миңа тәнемне генә түгел, җанымны, рухымны да каты гына, азаплый-азаплый күнектерергә туры килде»

Ул мондый үзгәрешкә ничек ирешүен безгә сөйләп тә бирә «Бала чакта, — дип яза ул. — Марриеттаның бер китабыннан бер күренеш бик нык тәэсир иткән иде Анда әллә ни зур булмаган инглиз хәрби корабы капитаны әсәр героена ничек куркусыз булырга икәнен аңлата Ул болай ди сугышка кергәндә һәркем диярлек башта курку хисе кичерә. әмма үзеңне кулда тоту өчен һич тә курыйкмыйм дип хис итәр ышанмаганлыктан һәм томаналыктан туа» — дип яза

Икенче төрле әйткәндә курку хисе үз-үзеңә ахыргача ышанып бетмәгән очракта туа Соңгысы каян килә? Үзегезнең нәрсәгә сәләтле икәнне белмәүдән Ә анысы тәҗрибәнең аз булуы белән аңлатыла Уңышлы тәҗрибәң булса, курку-каушаулар июль кояшы күренгәч таралган томан кебек юкка чыгачак

Бер нәрсә бәхәссез йөзәргә өйрәнер өчен суга керергә кирәк Моны барыбыз да беләбез Сез инде бу китапны шактый озак укыйсыз Ә нишләп менә хәзер үк сезгә китапны читкә куеп практик эшкә алынмаска?

Үзегезгә таныш бер теманы сайлап алыгыз да өч минутлык чыгыш әзерләгез Ялгыз калып чыгышыгызны күп тапкыр кабатлагыз Аннан соң мөмкинлек булса, шушы темадан хәбәрдар бер төркем кеше яисә дусларыгыз алдында чыгып сөйләгез Моңа бөтен көчегезне салыгыз

Йомгак

1 Шушы курсларны тыңлаган меңләгән кеше бу китап авторына ни өчен ораторлык осталыгына өйрәнергә теләүләрен һәм нинди нәтиҗәләргә ирешергә җыенуларын аңлатып хатлар язды Барысы да диярлек төп сәбәп итеп менә нәрсәне күрсәтә каушаудан котыласы зурмы-кечкенәме аудитория алдында торып уйларга каушамыйча, ышаныч белән сөйләргә өйрә-

кешенең бер генә сәләте дә яхшы сөйли белү сәләте кадәр мөмкинлек бирми» Миллионнарга ирешкән Филип Армор: «Атаклы оратор булуны мин атаклы капиталист булудан өстенрәк куяр идем», — дигән.

Белемле кешеләрнең һәркайсы диярлек шуңа омтыла лабаса. Эндрю Карнеги[1] үлгәннән соң, аның кәгазьләре арасында 33 яшендә төзегән яшәү планы табылган Шул чагында ул ике елдан соң ике мең долларлык еллык керем алырга ниятләгән.

Моның өчен ул 35 яшендә бөтен эшен ташлап, Оксфорд университетына укырга кереп, системалы белем алырга һәм «публика алдында чыгыш ясауга аерым игътибар бирергә» карар кылган.

Яңа сәләтегезнең сезгә канәгатьләнү, шатлык бирәсен дә уйлагыз. Шушы юлларны язган кеше Җир шарының шактый төбәкләрендә булып, бай гына тәҗрибә туплады, тик ул кешеләр алдында чыгыш ясап, аларны үзе уйлаганча уйларга күндергән кеше ала торган канәгатьлек хисе белән чагыштырырлык нәрсәләрне күп атый алмый.

Мондый хис сезгә яңа көч-гайрәт бирәчәк. Ул сездә уңышларыгыз белән горурлану тудырачак. Шулай итеп сез башкаларны узып китеп, алардан өстен булачаксыз. Бу — гомергә истә кала торган сихри бер мизгел. «Чыгышым башланырга ике минут кала мин сүз башламас өчен үземне каеш белән яруларына да риза, — дип эчсерен бушаткан иде бер оратор, — ә чыгышым бетәргә ике минут кала сөйләүдән туктатканчы атып үтерүләренә дә риза».

Өстәмә көч түгәргә кирәк булса, кайберәүләр суына һәм эшне азагына җиткерми — менә ни өчен сезгә бу сәнгатькә ирешүнең нәрсә бирәсен даими уйлап торырга кирәк; аңа омтылышыгыз дөрләп торган ут кебек сүрелмәс булырга тиеш. Дәресләргә дәртләнеп тотынырга кирәк, шунда гына җиңүгә ирешеп була. Атнага бер кичне шушы китапны укуга бүлегез. Кыскасы, алга баруыгызны ничек тә җиңеләйтегез, чигенергә юлны кыенлаштырыгыз.

Юлий Цезарь үзенең легионерлары белән Галлиядән Ла-Маншны кичеп, хәзер Англия дип аталган илгә килеп төшкәч, гаскәренең уңышын тәэмин итәр өчен нишләгән? Нәкъ кирәкле, акыллы эш эшләгән: солдатларына Дувр кыяларында туктарга әмер биргән; тегеләр диңгез тигезлегеннән ике йөз фут биеклегеннән аска карасалар, үзләре килгән корабларның ялкын телләре белән чорналуын күргәннәр — алар инде дошман илендә, үз илләре белән соңгы бәйләнеш чарасы да янып бетеп бара. Легионерларга бер генә юл калган: һөҗүм итәргә һәм җиңәргә. Һәм алар нәкъ шулай эшлиләр дә.

Үлемсез Цезарьның ихтыяры шундый булган. Ә нигә сезгә дә халык — кулыңа берәр нәрсә алсаң, тактага ни дә булса язсаң, картадан күрсәтсәң, утыргычны күчереп куйсаң, тәрәзәне ачып җибәрсәң, китап-кәгазьләрне күчереп куйсаң, — җиңелрәк булыр Теләсә нинди максатлы физик хәрәкәт сиңа үзеңне иркенрәк тотарга ярдәм итәр», — дип өстәргә тиеш иде.

Дөрес, мондый хәрәкәтләр ясарга сәбәп гел чыгып тормый, шулай да мөмкин булганда алардан файдаланырга кирәк. Тик аларны кабатламаска тырышыгыз: тәпи йөреп киткән бала башта ябышкан утыргычына кабат ябышмас.

Өченчесе: нык ышанып эш итәргә кирәк

Американың иң танылган психологларыннан берсе профессор Уильям Джеймс болай дип язган: «Башта хис, аннан эш, дип уйланыла, ә чынында алар бергә барлыкка килә ихтыяр көче белән контрольдә тотыла торган эшне идарә иткәндә без шул контроль астында булмаган хисне дә читләтеп идарә итә алабыз.

Нәтиҗә: әгәр чын күңел күтәренкелеген югалткансыз икән, күңелегез күтәренке кебек кыяфәттә утыру дәртегез бар кебек хәрәкәтләнү һәм сөйләү — күңел күтәренкелеген булдыру өчен бер дигән юл. Бу очракта башка юл юк.

Шуңа күрә кыю хис итәр өчен үзегезне чыннан да кыю итеп сизегез, моның өчен бөтен ихтыярыгызны җигегез һәм курку бизгәген, мөгаен, кыюлык җиңә барыр»

Профессор Джеймс киңәшен тотыгыз. Аудитория алдында кыюлык сәләтен булдыру өчен сездә инде шундый сәләт бар дип эш итегез. Әлбәттә, әзерлегегез булмаса, сезгә берни ярдәм итмәс. Ә нәрсә сөйләгәнегезне яхшы белгәндә, кыю гына торып басыгыз да тирән итеп сулыш алыгыз. Аудитория каршына килеп басканчы, утыз секунд тирән итеп сулагыз. Кислородның мул керүе күңелегезне күтәрер һәм кыюлык бирер. Атаклы тенор Жан де Решкә. «Шундый сулышыгыз булса, шуңа «атланыгыз», дулкынлануыгыз бетәр» — дигән.

Кайчан гына, кайда гына булмасын кешеләр кыюлыкка соклана белгән, шуңа күрә дә йөрәгегез ничек кенә какмасын, кыюланып алга чыгыгыз, тыныч кына басып торыгыз һәм үзегезне, миңа шулай рәхәт, дигән кыяфәттә тотыгыз.

Гәүдәгезне төмам турайтыгыз, тыңлаучыларның күзенә туры карап, шундый кыю ышаныч белән сөйли башлагыз ки, гүя алар барысы да сездән өҗәткә акча алып торган кешеләр. Нәкъ шулай дип күз алдына китерегез. Алар сездән шул өҗәтне кичектерүне үтенергә килгәннәр дип фараз кылыгыз. Бу сезгә уңай психологик тәэсир ясар.

Нервлы хәрәкәтләр белән пиджәк төймәләрен каптырып-ычкындырып төймәләрен тартматашмагыз, тәсбих төймәләрен тартматашмагыз, тәсбих төймәләрен тартмаламагыз яисә бүтән тынгысыз хәрәгә тиешсең Бераздан максатка ирешелә Күрәсең, кеше чыннан да үзен батыр итеп хис кылганга күрә генә чынлыкта батырга әверелә

Мин шушы теориягә таянып эш итә башладым Башта мин курыккан нәрсәләр аз түгел иде аюлар, чыгымчы атлар, башкисәрләр Шулай да башта мин алардан курыкмыйм дип фараз кылдым һәм акрынлап чыннан да курыкмый башладым Бик күп кеше, теләге булганда, нәкъ менә шулай эшли ала»

Теләсәгез сез дә моны эшли аласыз «Сугыш барышында, — ди маршал Фош, — саклануның иң уңышлы чарасы ул — һөҗүм» Куркуга да карамастан, һөҗүмгә күчегез! Куркуга каршы ташланыгыз. аның белән сугышыгыз, мөмкинлек чыккан саен аны кыюлык, тәвәккәллек белән җиңегез!

Әйтик, сез йомышчы ди телеграмма китердегез ди Гадәттә йомышчының үзенә артык игътибар итмиләр, күбрәк телеграмманың эчтәлеге кызыксындыра. Бөтен хикмәт шуңарда. Игътибарыгызны шуңа юнәлтегез Аны күңелдә тотыгыз Биш бармагыгыз кебек белегез Күңелегезгә якын алыгыз Шуннан инде аның хакында инанып, тәвәккәл итеп сөйли башлагыз Шулай эшләгәндә сез тиз арада сүзегезнең хуҗасы булырсыз һәм үзегезне кулда тота алырсыз.

Дүртенчесе. Күнегегез! Күнегегез! Күнегегез!

Менә бу соңгысы — бүген әйтеп үтелгәннәрдән иң әһәмиятлесе Тегеләрен оныткан очракта да хәзер әйтеп үтеләчәк мисалны истә тотыгыз Үз-үзеңә ышаныч булдыруның бердәнбер дөрес ысулы ул — булдыра алган кадәр күп сөйләү Асылда барысы да бер төп үзәккә төенләнә күнегү ясарга, күнегү ясарга һәм тагын күнегү ясарга! Бу sine qua non[2] аннан башка бернәрсә дә килеп чыкмый торган мәҗбүри шарт

«Беренче башлаганда һәркемдә «поши бизгәге» дигән өянәк булуы ихтимал», — дип кисәткән Рузвельт — Бу — нервның чиктән тыш киеренке халәте Аны юашлык, кыюсызлык дип аңлатырга ярамый Ул зур аудитория каршында беренче чыгыш ясаучыда гына түгел, ә бәлки ауда беренче тапкыр поши күргән кешедә дә беренче тапкыр сугышта катнашучыда да булырга мөмкин Бу минутта кешегә батырлык түгел, ә үзен-үзе тота алу салкын канлылык кирәк.

Моны исә бары практикада күнегүләр ясап кына булдырырга мөмкин Кеше өзлексез үзконтроль ярдәмендә нервларын идарә итәргә өйрәнергә тиеш. Моңа асылда гадәтләнеп, өзлексез көч куеп, ихтыяр көчен даими күрсәтеп кенә ирешеп була.

Аудитория алдында каушаудан котыласыгыз киләме? Башта карыйк курку хисе ничегрәк барлыкка килә икән.

«Аң үсеше» дигән китабында профессор Робинсон «Курку үз-үзеңә нәсе килү

2 Моңа сәләт булдыру әллә ни кыен түгел Бу — кәрт уйный белү кебек һәр ир-ат һәр хатын-кыз гомумән һәр кеше теләге зур булганда, моңарчы күрелмәгән сәләтен үстерә ала

3 Күп кенә тәҗрибәле оратор аерым кеше белән сөйләшкәнгә караганда зур аудитория алдында яхшырак уйлый һәм сөйли Кешенең күп булуы аларны дәртләндерә илһамландыра. Әгәр шушы китапта бирелгән киңәшләрне катгый тотсагыз. шундый сәләт сезгә дә килер һәм сез алда торган чыгышыгыз турында ләззәт белән уйлый торган булырсыз

4 Сезнең хәл — бердәнбер очрак дип уйламагыз Атаклы ораторларның күбесе эшчәнлекләрен башлап җибәргәндә аудитория алдында оялган куркудан паралич суккандай югалып калганнар Брайан Жан Жорес Плойд Джордж Чарлз Стюарт Парнелл Джон Брайт Дизраэл. Шеридан һәм башка бик күпләр дә шулай булган

5 Ничаклы гына еш чыгыш ясауга карамастан, сүз башлар алдыннан барыбер каушарсыз. әмма сөйли башлап берничә секунд үтүгә каушау юкка чыгар

6 Бу китаптан файданы күбрәк һәм тизрәк алу өчен түбәндәге дүрт кагыйдәне үтәргә кирәк

а) чыгышыгызны максатка ирешүгә нык, көчле омтылыш белән башлагыз Өйрәнүгә сарыф ителгән көчтән сезгә кайтасы әҗерләрнең барысын да истә тотыгыз Үзегездә күңел күтәренкелеге булдырыгыз Бу чыгышның сезгә финанс һәм социаль яктан да, дәрәҗәгезнең үсүендә дә җитәкче урыннарга күтәрелү өчен дә ярдәм буласын уйлагыз Максатка омтылу көче күбрәк булган саен уңышка тизрәк ирешәчәгегезне онытмагыз.

б) чыгышка әзерләнегез Сөйлисе нәрсәгезне яхшы белмәгәндә үзегезне кыюсызрак хис итәчәксез.

в) кыю эш итегез Профессор Уильям Джеймс тәкъдим иткәнчә үзеңне батыр тотар өчен үзеңне чыннан да кыю кеше дип хис итегез моның өчен бөтен көчне җигегез Шунда гына куркуны кыюлык алыштырыр

г) даими күнегү ясагыз Максатка ирешүдә иң мөһиме шул Каушау үз-үзеңә ышанмаудан килә Ә ышанычсызлык — үзеңнен нәрсәгә сәләтле икәнеңне белмәүдән Ә белмәү — тәҗрибә аз булудан Димәк уңышлы тәҗрибә хәзинәсе булдырганда, барлык куркуларыгыз юкка чыгар

[1] *Карнеги, Эндрю* (1835-1919) — шотланд милләтеннән америкaн миллиардеры Мохтаҗларга иганә биргән — *Редакция искәрмәсе*

[2] *Sine qua non (латинча)* — мәҗбүри шарт — *Редакция искәрмәсе*

(Дәвамы бар).

МИРАСЫБЫЗНЫ БАРЛЫЙБЫЗ

Муса АКЪЕГЕТ

(1864-1923)

ХИСАМЕДДИН МЕНЛА. Милли роман яки хикәя Казан университеты тәбгыханәсендә 1886 елда басма улмышдыр

М Акъегетнең «Хисамеддин менла»сыннан башлап татар әдипләре күренекле кешеләр әйтеп калдырган сүзләрне. билгеле бер хакыйкатьне генә түгел. ә кешенең реалистик мохитен. уй-кичерешләрен эш-гамәлен — гомумән. реаль тормыштан алынган яисә шулай булырга тиеш дип ышанган берәр күренеш вакыйганы үзләре исеменнән сөйләп хикәя итәргә омтылалар сәнгатьле сөйләм яңача «җан»лана һәм «зат»лана Автор. вакыйганы сөйләүче кеше буларак. алгы планга чыга укучысына йөзен ача. аңа мөрәҗәгать итеп сүзен башлый әсәрдә сөйләнелә торган вакыйга хәлләргә персонажларына мөнәсәбәтен турыдан-туры белдерә бара әсәрдә хикәяләнәчәк хәлләрнең кайда кайчан һәм нинди җирлектә баруын конкрет күрсәтә вакыйга күренешләрнең тәртибен. хәрәкәтен билгели. аңлатма бирә укучысына эндәшә Уңай персонажы турында автор билгеле бер хакыйкатьне белдергәндәй. турыдан-туры мактап сөйли. ә кире персонажы хакында сүзләр аның иронниясенә төрелә «Җан»лы автор сөйли башлаганчы әсәрнең үзегендә билгеле бер изге фикер ята иде ә хәзер шул фикерне әйтүче мәйданга чыга. укучыга җиткерелергә тиешле сәнгати фикер гомумилектән котылуга йөз тота — аны фәкать үзенчә генә сөйләргә омтылган аерым шәхеснең рухы белән өретелә Персонажларның үзара сөйләшүе табигый диалогик формага корыла. «Хисамеддин менла» повестеның тел үзенчәлеге татар филологиясендә дөрес бәяләнгән «. шул чорда таралган төрек теле үзенчәлекләре шактый сизелә. М Акъегет. З Бигиев һ б. кайбер язучыларның әсәрләрендә төрек сүзләренең һәм формаларының кулланылуы аларның төрек теле һәм әдәбияты белән таныш булуы, шул чорда татарлар арасында таралган әдәбият традициясен дәвам итәргә омтылулары белән дә аңлатыла Шуның белән бергә. М Акъегет үзенең әсәрен. аңлы рәвештә «Тәрҗеман»ның теленә охшатып язарга омтыла. чөнки әлеге гәзитне ул халыкка аң-белем тарата торган басма дип саный. Хисамеддин кебек бар яктан да килгән уңай персонажы хакында нәкъ әнә шундый гүзәл тел белән генә хикәяләргә мөмкин дип уйлый».

* * *

М Акъегетнең «Хисамеддин менла» әсәрендә татар теле белеменә караган яңалык та чагылыш таба татар филологиясендә беренче мәртәбә тыныш билгеләре хакында белешмә бирелә Хәзер менә шуңа игътибар итик Автор аны китаптагы ишарәтләр дип атый һәм түбәндәгечә санап үтә.

Гыйбарәне яхшырак аңлатмак өчен. госманлы. мисыр вә һинд голяма исламийен шул ишарәтләри мәкъбул күрделәр.

1) Нокта тынышыдыр вә җөмләнең тәмам улдыгыны күстәрүр. Ноктага йетешкәч. эстәнледәге кадәр укудан туктамак мөмкин. Вә бу ноктадан соңра яңы сүз башланадыр Мисал бән базара вардым. Сөнең атын йөкерекдер.

2). Виргул адлы ишарәдер ки буйлә язылыр яки Җөмләдә лязем булынан ләфезләри бер-берендән аерыр. яки мәфһүменчә бер-беренә ике якын ике җөмләне аерыр Мисал бән базарда табдым алма, алманы сәңә кәтүрдем Бу ике җөмлә арасында виргул куймасак. мәфһүмә төшенеп булмас, зира укымак мөмкин ки тапдым. соңра алма алманы. тәмам башка төрле мәфһүм чыгадыр. Укыганда виргулдән соңра бер кат җан алмак мөмкиндер

3). ? бу сөәл галәмәтедер Мисал Базарда нә алдыңыз? Җөмләдән соңра буңы куймак кирәк.

4) ! Тәгаҗҗеб яки кычкырмак галәмәтедер Бу ишарәле җөмләне йә тәгаҗҗеб идеп яки тавышны күтәреп укымак кирәк Мисал Әй тиз бире кәл! Кычкырып укымак. Билгакес. бу нә хикмәт! дигәндә тәгаҗҗебле тавыш илә укымак кирәк

5) ... Күп нокталар сүзнең бердән кәселмәкне. яки бер сүз бетмәенчә бердән яңа. сүз башланмакны күстәрүрләр.

: ике нокта санамакдан мөкаддәм вә бәяндан мөкаддәм куеладыр Мисал бән базарда шушыларны алдым. чәй. шөкәр вә бал

6). ( ) яки « » бу ишарәтләр арасында кеше сүзләре языладыр. Мисал (Кит бундан) диде Зәет

Ишарәтләр хакында тәфсиллә эстәйән адәм госманлы нәхүләренә мөрәҗәгать әйләсүн Без исә вирдегемез мәгълүмат илә иктифә әйләдек Муса Акҗегет.

Татар теле белемендә тыныш билгеләре беренче мәртәбә менә шулай аңлатыла Хәзерге графикага күчергәндә. гарәп язуы үзенчәлекләре нигездә сакланды Кыскача сүзлекчә бирү зарур булса кирәк гыйбарә — язылган сүз. җөмләләрнең тышкы ягы (мәгънәсе түгел). голяма исламийен — ислам дөньясындагы галимнәр. мәкъбүл — яраклы. яхшы. эстәнледәге — теләгән кадәр. виргул — төрек теленә французтеленнән кабул ителгән сүз — өтер. Ләфыз — сүз, сүзнең мәгънә калыбы, мәфһүм — аңланган төшенелгән нәрсә, җан алмак — хәл. тын алмак, тәгаҗҗеб — гаҗәпләнү; билгакес — киресенчә. мөкаддәм — алда, нәхү — грамматика (синтаксис), иктифә — канәгатьләнү.

Шунысы да игътибарга лаек М.Акъегет әлеге тыныш билгеләренең барысын да романының тел тукымасында эзлекле рәвештә файдалана, барысын да куллана. димәк, үзенең теориясен гамәлдә дә тормышка ашырырга омтыла.

Илида БӘШИРОВА,
филология фәннәре кандидаты

ЭТИМОЛОГИК ТАБЫШЛАР

Дәстүр. дүстер

Иске татар дәүләтчелегеннән калган тагын бер сүз — **дәстүр** яки гади халык телендә **дүстер** «зур рәсми урын рәсми эш» Фарсы теленнән кергән бу сүздән **дәстүрханә** (яисә **дәстүр** үзе генә) «приемная» сүзе ясалган булган

Нигә бүген дә начальникка керүне **дәстүр** дип атамаска икән? Югыйсә «кабул итү бүлмәсе» дип азаплану озынга китә

Дәү һәм дию: дуамал һәм дивана

Дәү сүзе төрки һәм башка телләрдәге күпсанлы лексик материал күрсәткәнчә **дию** «гаять зур гәүдәле таулар күтәрерлек пирик зат» сүзе белән бердәй икесе дә борынгы фарсы **дэв** «тәңре» сүзеннән килеп чыккан (бу һинд-европа сүзе теология сүзенең тамыры **тео** «Алла» өлешендә һәм башка күп кенә сүзләрдә шул хисаптан **зевс** ~ грекларның баш илаһы сүзендә чагылыш таба)

Дәү һәм **дию** татар телендә дә күп сүзләргә нигез булганнар **дәвәни. дәвәти** кебек сүзләрдән тыш **ирдәвәй** «ирләр кебек зур гәүдәле хатын» (**ирдавай** бозылган форма) **ирдәүкә** «ирсәк таза хатын» **дуамал**, элеккерәк яңгырашы **дәүамал** «дию шикелле» (**амал, аман, әмән** «кебек. шикелле» мәгънәсендәге диалекталь сүз) **дивана** фарсыча шулай ук «дию шикелле» һ б

Дүрткел

Гомумтөрки **дүрткел** «дүртпочмаклы» сүзе бөтенләй ялгыз түгел төрле чыганакларда татар телендә тагы **өчкел, биткел** сүзләре теркәлгән **Кел** биредә күп кенә төрки телләрдән теркәлгән **кәл, күл** «почмак почмактагы башня» (шуннан чувашча **кил** «өй үз почмагың»). сүзеннән булса кирәк Ихтимал татарча **киләк** «умарталык умарта саклау һәм кышлату бинасы» сүзе дә шул **килдән** ясалгандыр

Дүрткел, өчкел сүзләре татар халкынын геометрик фигураларны атау өчен махсус сүз моделе иҗат иткәнлеге турында сөйли Шул модель буенча **алтыкел, җидекел, сигезкел** һ б сүзләр ясап була

Җайдак һәм сыбай

Татар әдәби телендәге **җайдак** (диалекталь сөйләмдә **җәйдәк, йайтак**) сүзенең бүтән төрки телләрдәге параллельләре **яйдак, ябыдак, җабыдак,** тувача **чавыдак**, якутча **сабыдах** һ б «яланат иярсез (атлану)» дигән сүз

Иярләп җайлап атланган кеше элек **сыбай** (әдәби телдә **синаһи**) дип аталган Күп кенә сөйләшләрдә мәсәлән Көньяк Урал — Себер регионында әйбәтләп җайлап атланган кеше **сыбай** дип йортелә Башкорт әдәби телендә дә андый атлы **һыбай** диелә

Шулай итеп кызык кына манзара килеп туа «мәдәни» татар **җайдак**, ягъни иярсез-нисез атлана, ә башкорт **һыбай** — иярләп менә

Җайдак сүзе төрки-монгол сүзе ә **сыбай, синаһи** исә фарсы теленнән алынган

Рифгать ӘХМӘТЬЯНОВ,
филология фәннәре докторы

ЯҢАЛЫК! ЯҢАЛЫК!

Котлыйбыз!

Шушы елның 26 октябрендә Татарстан Фәннәр академиясенең Г Ибраһимов исемендәге Тел. әдәбият һәм тарих институтында танылган фольклорчы Хуҗиәхмәт Мәхмүтов «Татар фольклорының афористик жанрлары» дигән темага докторлык диссертациясе яклады

Моңа кадәр Казанда халык иҗаты буенча докторлык диссертациясе якланганы булмады. чөнки моның өчен тиешле шура юк иде Беренче доктор-фольклорчылар Хәмит Ярми һәм Фатих Урманчиев үз диссертацияләрен Алма-Ата һәм Ташкентта якладылар Бу юлы шундый шура (бер мәртәбә яклау хокукы белән) Казанның үзендә югары аттестация комитетының (ВАК) махсус фәрманы белән оештырылды Аның эшендә Казан, Мәскәү, Уфа, Йошкар-Ола шәһәрләреннән күренекле галимнәр катнашты

Рәсми оппонентлар А Алиева (Мәскәү), С Галин (Уфа), Н Юзиев (Казан) һәм тикшерүдә катнашучылар Х Миңнегулов, А Китиков (Йошкар-Ола), Ә Сөләйманов (Уфа). Н Хисамов, Ф Солтановлар диссертациягә югары бәя бирделәр. аның татар фольклор фәненә зур өлеш кертүен билгеләп үттеләр

Х Мәхмүтов үзенең хезмәтендә афористик жанрларга нигезле фәнни төркемләү үткәрә, аларның 14 төрен аерып күрсәтә (мәкальләр. әйтемнәр, канатлы сүзләр. ышанулар, сынамышлар, алкышлар, каргышлар, ырымнар, антлар, әзер җаваплар, үртәвечләр, тел көрмәкләндергечләр, җор сүзләр, табышмаклар) Бу жанрларның байтагы автор тарафыннан беренче мәртәбә тикшерелгән Хезмәттә халык афоризмнарының барлыкка килүе. тарихи үсеше, аларның сәнгатьчә эшләнеше турында да җентекле һәм дәлилле төстә бәян кылына

Г.САБИРОВА.

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

НОЯБРЬ

Латинча november дип аталган ай Рим календарендә тугызынчы ай (novem — тугыз) Славяннарга бу атама грек теленнән алар әйтелешендә керә Башта төрле әйтелештә, төрле язылышта йөри (гадәттә йа авазының төрлечә әйтелешенә, язылышына бәйле рәвештә), шул исәптән, ноямбрь, ноембрий вариантлары да була

И туган тел...

1995 ел
24 ноябрь
№ 4 (27)

Мифтах ВӘДҮТ
(1915-1942)

Яшьлек

(өзек)

Яшьлек өчен үнсигездә
Булу шарт түгел
Тик көрәш ялкыны белән
Янсын саф күңел.

Көрәш ялкыны эчендә
Чыныксын йөрәк,
Көрәш, җиңү — яшьлек өчен
Менә шул кирәк.

Алдымда ашымны ашыйлар, артымда башымны ашыйлар

Күңел габу да һөнәр

Киләсе саннарда:

- Туган телне – гамәлгә! Телләргә ихтыяж турында сөйләшәбез
- Мәктәпләрдә сөенечләр һәм көенечләр
- Югары уку йортларында. Авылдан килеп тә татарча укымагач...
- Тел кабинеты Тәҗрибә уртаклашабыз. Хатлар көтәбез.
- Сөйләмият дәресләре
- Агач – авыз, балта – тел
- Балаларыгызга укыгыз
  Укучылар иҗаты
- Этимологик табышлар һәм бүтәннәр

Сәхифәнең мөхәррире Илдар НИЗАМОВ.
Адресыбыз 420503,
Казан, Бауман урамы, 19
«Мәдәни җомга»,
«И туган тел »

Сакләбиләр патшасына

әл-Мөктәдирдән илче булып барган Әхмәд ибне Фазлан китабы

(Борынгы текстны СОЛТАН ШӘМСИ эшкәртте һәм тәрҗемә итте

(Дәвамы. Башы 16, 17, 18 саннарда).

Аларда читтән килгән сәүдәгәр яисә башка берәүнең кон яктысында кеше күз алдында тәһарәт алырга, госелләнергә хакы юк Күрәсең, бу эш төнлә кеше күрмәгәндә эшләнәдер Бу эш аларда катгый тыела һәм алар моны бер дә яратмыйлар, күрсәләр бик нык ачуланалар. Шундый чакта «Бу кеше безне сихерләмәкче була Күрәсезме, ул суга ничек текәлеп карый!» — диләр Андый кешене алар салым түләргә мәҗбүр итәләр.

Аларда тагын шундый гадәт бар: бу илгә килгән һәрбер мөселман кешесе үзе туктаган гаиләдәге берәр ир-ат белән дуслашырга тиеш була. Кунак аңа мөселман илләреннән кием-салым, ә хатынына бүләк итеп бөркәнчек, бераз борыч, тары, йөзем һәм чикләвек алып килә. Кунак дустына килеп төшү белән, тегесе шундук аның өчен тирмә яисә чатыр кора, күпме булдыра ала, шул кадәр сарыклар куып китерә Кунак мөселманга аларны теләгән кадәр суеп ашарга гына кала Төрекләр үзләре терлекне суймыйлар, ә башына сугып үтерәләр.

Әгәр дә кунак мөселман китәргә җыенса, моның өчен аңа дөяләр, атлар яисә юлга акча кирәк булса, ул төрек дустында берәр нәрсәсен калдыра. Ул хуҗа кешедән үзенә кирәгенчә дөяләр, атлар яисә башка нәрсәләр ала да юлга чыгып китә. Юлыннан әйләнеп кайткач, алган бурычларын түли, дөяләрне, атларны хуҗага кайтарып бирә. Әгәр дә берәр төректә таныш булмаган кеше туктапып: «Мин синең кунагың, миңа фәлән кадәр дөя, атлар һәм дирһәмнәр кирәк» дип әйтсә, хуҗа кеше аңа теләгәнен бирә.

Әгәр дә бурычка алган сәүдәгәр сәфәр чыгып киткән юлында үлеп калса һәм кәрван аннан башка әйләнеп кайтса, аларны каршы алган төрек «Минем кунагым кайда?» дип сорый. «Ул үлде инде», дип җавап бирсәләр, кәрванны бушатырга тиеш булалар. Төрек исә кәрваннан иң бай бер сәүдәгәрне сайлап ала да аның йөкләрен бушата, шаһитлар алдында аңардан үлеп калган сәүдәгәргә биргән кадәр дирһәмнәр дөяләр, атлар кайтарып ала. Моны ул «Мәрхүм бит синең туганың иде, сиңа аның бурычын кайтарырга кирәк», — дигән сүзләр әйткәләп башкара.

Әгәр дә төректән бурычка алып торган сәүдәгәр качып киткән булса, төрек әлеге бай сәүдәгәргә:

«Качып китүче синең кебек үк мөселман иде. Әҗәтен кайтар», — ди, аннан үзенә тиешле малны кайтарып ала. Әгәр дә тегесе малын бирергә теләмәсә, төрек качкан сәүдәгәрнең кайда булуын сораша. Бәхете басып, качкынның эзеннән дөрес җибәрсәләр, ул вакытын кызганмыйча аның артыннан бик еракларга да китәргә мөмкин. Тапкач, биргән малын, бүләкләрен кайтарып ала.

Төрекләрдә тагын шундый гадәт тә бар Җөрҗаниягә килгән төрек тә гел үзенең берәр дустында туктала, кайтып киткәнче шунда тора Әгәр анда торганда төрек кинәт үлеп китсә һәм төрек җирләреннән үтеп баручы кәрванда әлеге йорт хуҗасы булса, бел дә тор — төрекләр аны үтерәчәкләр. Бу очракта мөселман өстенә шундый гаеп ташлана «Аны зинданда тотып син үтергәнсең. Зинданга китереп тыкмаган булсаң, ул үлмәс иде», — диләр Мөселман кешесе төреккә набыз[11] эчереп, тегесе исерек килеш дивар өстеннән егылып төшеп үпсә дә мөселманны үпем көтә Кәрванда теге гаепле мөселман булмаган очракта төрекләр арадан иң күренекле бер мөселманны сайлап алалар да, шулай ук җанын кыялар

Ирләр арасындагы зиначылыкта аларда җинаять санала. Шулай бервакыт төрекләр башлыгының җирле идарәчесе Күзәркин ыруында куйлар сатып алырга килгән бер Харәзем кешесе торган. Бу адәмгә йорт хуҗасының әле сакал да чыкмаган яшь улы бик ошап киткән Ул аны, бер алдына, бер артына төшеп дигәндәй, зина кылырга үгетли башлый һәм, ниһаять, теләгенә ирешә Шушы эш белән шогыльләнеп ятканда, боларны йорт хуҗасы тота Бик нык ачуы чыккан төрек бу хакта Күзәркинга барып әйтә. Теге аңа төрекләрне җыярга куша.

Халык җыела. Күзәркин кеше алдында теге төректән:

— Син нинди хөкем булуын телисең гадел хөкемнеме, әллә инде исеменә генәме?

Моңа каршы төрек:

— Гадел хөкемне, — дип җавап бирә.

— Ул вакытта улыңны монда китер, — дип боера Күзәркин

Төрек улын алып килә. Күзәркин исә

— Бу эш өчен улың да, сәүдәгәр дә үтерелергә тиеш, — дип белдерә.

Моны ишеткән төрек шашып кала:

— Юк, мин улымны бирмим, — дип кычкыра.

Күзәркин

— Алайса, сәүдәгәргә үзе өчен йолым түләргә кирәк булыр, — ди.

Әлбәттә, Харәзем сәүдәгәренә шактый чыгым күтәрергә туры килә. Төрекнең улын гөнаһка тартканы өчен дә, Күзәркин аны җәзадан йолып калган өчен дә сәүдәгәр куйлар белән түли һәм ашыгыч рәвештә төрекләр иленнән китеп бара.

Аларның идарәчеләреннән без очраткан беренче кеше Йынал исемле иде Ул моңарчы ислам диненә күчеп караган икән дә, ырудашлары аңа «Әгәр син ислам динендә булсаң, безгә башлык түгелсең», — дигәннәр. Әлбәттә, аңа исламнан ваз кичәргә туры килгән. Аның биләмәләренә килеп кергәннән соң ул безгә

— Мин сезгә юлыгызны дәвам итәргә рөхсәт бирә алмыйм, чөнки мондый хәлнең бездә беркайчан да булганы юк иде Андый илчелек турында белгәнебез-ишеткәнебез, хәтта уйлап караганыбыз да булмады, — дип белдерде.

Без аның күңелен күчтәнәчләр, бүләкләр бирү белән яулап алырга булдык Аңа ун дирһәм бәясе торган җөрҗан кафтаны, пайбәф дип аталган тукыма кисәге, көлчәләр, учлап йөзем һәм йөз чикләвек бүләк иттек Бу әйберләрне кулына тоттырганнан соң ул бил бөгеп рәхмәт әйтте Аларда гадәт шундый — берәр кеше икенче берәүгә хөрмәт күрсәткәндә тегесе аның каршында бил бөгә

Ул безгә

— Йортым кәрван юлына якын торган булса, мин сезгә күп итеп куйлар куып китереп бүләкләр биргән булыр идем — диде

Бераздан ул каядыр китеп барды

Без сәфәрне дәвам иттердек.

Иртәгесен юлда фәкыйрь генә киенгән, мескен кыяфәтле бик ябык бер төрекне очраттык. Бу вакытта көчле яңгыр ява иде

Төрек безне күреп алу белән бик гайрәтләнеп

— Туктагыз! — дип кычкырды

— Өч мең аттан биш мең кешедән торган кәрван шунда ук туктап калды Төрек күзен дә йоммыйча

— Берегезгә дә ары китәргә рөхсәт юк! — дип белдерде

— Без Күзәркин дуслары, — дидек без

Ул шаркылдап көлде дә

— Кем соң ул Күзәркин? Төкерәм мин аңа! — диде

Аннан соң ул «пакәнд» дип бездән ипи сорады Мин аңа көлчәләр бирдем Төрек аларны алганнан соң.

— Узып китегез, мин сезгә мәрхәмәт күрсәтергә булдым, — диде.

Без кузгалып киттек Юлны дәвам иттердек.

Аларда тагын шундый йола бар икән әгәр дә таза тормышлы ир һәм хатын-кыз коллары да булган берәр төрек авырып китсә якыннарыннан берәү дә аның янына килми Аңа читтәрәк аерым бер чатыр корып куялар да, терелгәнче яисә вафат булганчы ул шунда яши Әгәр авырып китүче фәкыйрьләрдән яисә коллардан булса, аны, гомумән, далада калдырып китәләр

Әгәр дә берәрсе үлеп китсә иң әүвәл аның өчен зур тирән чокыр казыйлар. мәетне шунда төшергәнче өстенә куртка киертәләр билен каеш белән буалар янәшәсенә ук-җәясен куялар.. Мәетнең кулына набыз эчемлеге салынган агач савыт тоттыралар шундый ук эчемлек тутырылган савытны янәшәсенә куялар Каберг шулай ук аның мал-мөлкәтен, төрле әйберләрен салалар Аннан соң кабер өстенә агачлар түшиләр дә биек итеп балчык өяләр[12] Җирләгәннән соң мәрхүмнең калдырган мөлкәтенә карап йөз ике йөз әгәр дә ул фәкыйрь булса, исеменә дип бер генә атны сугып үтерәләр дә итен пешереп ашыйлар Атның башын, аякларын, тиресен һәм койрыгын шул килеш калдыралар Соңыннан аларны агач корылмаларга элеп куялар «Ул шушы атка утырып теге дөньяга керәчәк». — диләр

Әгәр дә мәрхүм сугыш-бәрелешләрдә катнашып зур батырлыклар күрсәткән күп дошманнарны юк иткән булса, үтерелгән дошманнары санында агачтан сыннар юнып ясыйлар аларны мәрхүм кабере өстенә утырталар да: «Бу адәмнәр теге дөньяда аңа хезмәт итәчәк». — диләр Әгәр дә мәрхүмнең туганнары корбанга атлар бирү йоласын үтәүне берничә көнгә кичектереп торсалар, ыруның берәр аксакалы килә дә алардан йоланы үтәүне таләп итә «Төшемдә мәрхүмне күрдем ул миңа «Менә күрәсеңме аркадашларым мине куып узды җәяү йөрүдән аякларым бозылып-ярылып бетте Аларны куып җитә алмыйча япа ялгызым торып калдым» дип әйтте». — ди

Аксакалдан шундый сүз ишеткәннән соң туганнары мәрхүмнең атларын сугып үтерәләр дә итен пешереп ашагач тиреләрен кабер өстенә җәеп салалар Бер-ике көн үтүгә аксакал кабат аның туганнары янына килә дә «Төшемдә мәрхүмне күрдем ул миңа «Туганнарыма, аркадашларыма тапшыр — мин башкаларны куып җиттем җаным тынычланып калды» дип әйтте» — ди

Без монда төрекләрнең. мыекны калдырып сакалны бөртекләп йолка торган гадәтен дә күрдек Миңа сакалы йолкынган бетешкән картларны монда еш очрагырга туры килде бары ияк турысында гына бераз төкләр кала иде Шундый карт өстенә тун да киеп алса, кәҗә тәкәсенә охшый да кала

Төрек угызларның кабилә башлыгын «йабгу» дип йөртәләр Бу аның рәсми титулы Аның урынбасары уң кулы «күзәркин» дәрәҗәсен йөртә Гомумән кабилә башлыгын алыштыручы һәр кеше «күзәркин» дип атала

Төрек угызлар җиреннән чыгып барганда, без аларның гаскәр башында тукталдык Ул Катаган улы Әтрәк атлы иде Гаскәр башы төрек тирмәләре кордырды да безне шунда урнаштырды Аның яраннары хезмәтчеләре бик күп тирмәләре зур һәм иркен Аның боерыгы белән безгә күп итеп куйлар куып китерделәр атлар белән тәэмин иттеләр — бу исә куйларны суеп ашасыннар атларга атланып йөрсеннәр дигән ният белән эшләнде Ул шулай ук үзенең якыннарын абзасының улларын мәҗлескә җыйды барысын да куй ите белән сыйлады

Без дә килү белән аңа бүләкләр күчтәнәчләр биргән идек кием-салым йөзем чикләвек борыч тары Мин аның хатынын да күрдем — ул элек аның атасында булган икән Шушы хатын бераз ит белән сөт алып, шуңа без иренә бүләк иткән әйберләрне дә өстәп урдадан ялан кырга ачык далага чыкты анда чокыр казыды да шул әйберләрне күмеп куйды Үзе туктаусыз ниндидер сүзләр әйтеп үзенчә дога укыды

Мин тылмачтан

— Нинди сүзләр әйтә ул? — дип сорадым

Тылмач миңа

— Бу әйберләр Әтрәкнең атасы Катаганга гарәпләр алып килгән бүләк дип әйтә — дип аңлатты

Караңгы төшкәч мин тылмач белән гаскәр башы Әтрәк тирмәсенә кердем Ул бу вакытта ял итә иде Миндә Надыйр әл-Хураминың аңа тапшыру өчен язылган хаты да бар иде Хатта ул Әтрәкне ислам диненә күчәргә өнди Өстәвенә ул аңа бүләк итеп илле динар акча да җибәрде Әлеге динарлар арасында мусәййәбә динарлары да аз түгел моннан тыш өч мыскал мускус, кызылга буялган күннәр ике мерв кием дә бар иде Соңгысыннан без аңа ике куртка кисеп бирдек Шуларга өстәп аңа кызыл күн читекләр, парчадан тегелгән киемнәр биш данә ефәк киемнәр дә бүләк иттек Шулай итеп әлеге бүләкләрне без аның кулына тапшырдык һәм хатынына бөркәнчек белән йөзек бүләк иттек

(Дәвамы бар).

---

[11] Набыз — исерткеч эчемлекнең бер төре

[12] Төркиләрдә кабер өстенә курган өю гадәтен Ибне Фазлан шулай тасвирлый

Көзге рәнҗү

(Хикәя)

Кояш ТИМБИКОВА

(Ахыры. Башы 18 нче санда).

Озак тормыйча, шул ук урынга малайлар да җыелышты Алар арка капчыкларын чөгендер белән тутырганнар Дыңгычлап Бусы — бер Икенчедән, алар Камәриягә булган карашларын да үзгәрткәннәр кебек Әллә кайдан сизелеп тора Чөгендер йолкыгандай: «Әй әби, артка калма!» — дип мыскыл итүчеләре дә. «Бу урын кирәкмиме? Утырыгыз!» — ди-ди аны якын күрүләрен сиздерәләр. Мөгаен, теге хәсис «җитәкче»нең явыз нияте барып чыкмавын белеп өлгергәннәр, Камәриянең теләсә нинди иргә ястык булырдай арзанлы хатын түгеллеген аңлаганнар.

Шуңа охшаш тынычланупарга «таянып». Камәрия башында узган яман хәлләрдән арынырга тырышты. Күзләре — юлда куллары кыска бишмәт кесәсенә яшерелгән ике чөгендерне йомарлаган Хәтта рәхәт тә кебек әле. Иртәгә, эшкә барганчы ук, ул Гаҗилә дусты янына керәчәк. аңа, үз куллары белән йолкыган чөгендернең шифалы суын эчерәчәк!

Шәһәргә керер алдыннан машина тукталып калды. Сөлектәй егетләр боерык биргән икән Өсләренә алалы-колалы кием кигән, кулларына аршин буе таяк тоткан, әзмәвердәй егетләр машина ишеген ачтырып.

— Күпме бәрәңге урладыгыз? Бушатыгыз! — дип кычкырдылар.

Бу тавыш Камәриягә «җитәкче» бәндәнең «.. син юк монда! Монда — мин генә!» — дигән һәм шул сүзләре белән котын алган өмерен хәтерләтте Ул кыска бишмәтенең ике кесәсендә ике учы белән йомарланган ике кеп-кечкенә чөгендерне чыгарып, алга суз-ды

— Менә ..

— Бәрәңгене күпме урладыгыз? — дип акырды туктатучыларның берсе.

— Без бәрәңге алмадык, — диде «җитәкче».

— Алайса ник баш катырып торасыз? Безгә бәрәңге сакларга кушылган...

Чиләк-чиләк чөгендер тутырып кайтучы малайлар хахылдаштылар. Камәрия Гаҗиләсенә илтергә ниятләгән шифалы ризыгыннан да мәхрүм калды Йа Алла, нәрсәгә генә таянырга соң? Нинди бер якты өмет йолдызы табарга?!

Камәрия, тәмам вәйран булып, бүлмәсенә кайтып егылды Аңа бөтен гаделсезлекләр читтә, бу җылы җыйнак бүлмәсендә генә рәхәт кебек иде. Өстен-башын алмаштырып та өлгермәде — телефон чылтырады

— Гаҗилә Салихова вафат. Сезне бик көткән иде, — диделәр...

Бу бер көндә кичергәннәренең тагын да артыгына чыдар хәле калмаган иде инде Камәриянең Аны тулы битарафлык биләп алды Хәзер аның һәр әгъзасы үзенчә тарткалаша — тупаем омтылыш юк. Әйтик, телефон чылтыравын ишетә, ә аяклары ул якка барырга теләми, колаклары ниндидер хәбәр ишетүне өнәми. Ишектә кыңгырау яңгырый — шул ук хәл. Мондый гөзсоратларның гайрә табигый икәнлеген Камәрия үзе дә чамалап ятты Чамалады һәм иртән Гаҗилә вафат булган шифаханәгә китте. Киттееe...

Күзен ачканда ул инде үзен шифаханә ятагында күрде. Әүвәл уеннан ни узганнарны кичерде ул Яман булган икән шул, ул күренүгә. «Соңгардыгыз!» — диделәр. Гаҗиләне үзенең туган авылына күмәргә үк алып киткәннәр икән инде. Татарлар ашыга бит ул. Шуннан соңгысын ул аерым-ачык белми. Егылды Гаҗилә яткасына туры килмәгәнлектән, аны җәһәннәм чокырындагы башка шифаханәгә йөрәк-нерв авырулары бүлегенә китереп ташлаганнар. Әллә нинди тузга язмаган хәлләр уйлап ятты Камәрия. «И-и бу кеше гомере! Әллә ниләр ниятләп яшисең — кырт кисә дә куя. Гаҗилә шундый иде,үземә дә килеп җиткән... Шул чөгендерне генә дә уып китерә алмадым... Алланың каһәре суксын!..» Бу каһәренең кемгә әйтелгәнен дә исәпләп бетерә алмады, аның янә аңы китте

Кабат күзен ачканда Камәриянең каршында ак халатлы кешеләр мәйхәнә килә иде:

— Миннән сезгә ни кирәк? — дип сорады ул. — Тукайның «Шүрәле»сен хәтерләп.

Тирә-юнендәгеләр, хәтта Камәриягә дә аңлашылырлык рәвештә мыскыллы итеп, бер-берсенә карап елмаештылар.

Арадан тәвәккәл-ваемсызы Камәриянең авызын томалады:

— Үз хәлеңне чамалабрак сөйлә, ханым!..

«Тагын миңа тиешле булмаган сүзне әйтәләр», — дип кимсенде Камәрия.

Аннары ачыргаланып, кычкырып салды:

— Мин — ханым түгел, мин — карт кыз Тик, уйлавымча, моның әллә ни аермасын да күрмим...

Шифаханәдәгеләр аптырашта калдылар Алар әле моңарчы бу «четерекле» мәсьәләне уртага салып бәхәсләшүче пациентны күрмәгәннәр иде Алар өчен — нинди аерма бар инде илледән узган нәмәрсә үзенең кызмы хатынмы икәнлеген дәгъвалап маташсын, имеш?!

— Шупай да . сезне ни-нәрсә шул кадәр борчыды соң? — Ниһаять, көндезге тикшерүгә кергәннәр аңарда психик чигенеш барлыгын сиземләделәр «Аңарга һич көтелмәгән стресс булган», — диде берсе.

Камәрия тыңлап тик ятты, үз кичерешләренә үзе генә нәтиҗә ясарга тырышты.

Әмма мондый нәтиҗәнең очына чыгарлык түгел икән бит әллә нинди атасыз балачак, теш-тырнак белән «яулап алынган» югары белем, шуңа бәрабәр — оч тиенлек хезмәт, үзеңә тиң мәхәббәтне көтү һәм... югалту... Кая гаделлек? Тырышуның нәтиҗәсе? Ни генә булды соң бу гомердә?..

Бөтен табибларның, палатадагы сырхаудашларының сорауларына, аннан да бигрәк, үз бәгырен телгәләгән мең төрле шик-шөбһәләренең

берсенә генә дә җавап таба алмый интеккән мизгелендә Камәрия ятагы янына аның баш бухгалтеры үзе (!) килеп керде. Баш очында аны күргәч, Камәрия, канына сеңгән буйсынучанлыгына каршы торалмыйча, хәтта аягүрә басарга азапланды. Баса алмады. Ак мендәреннән башын гына бераз күтәрде.

— Исәнмесез! — диде ул. — Ник борчылып килеп йөрисез инде?..

Ул әле тагын ниләрдер өстәмәкче иде — баш бухгалтер сүз җебен үз кулына алды.

— Карале, син әзрәк чамалыйсыңмы соң, әллә инде бөтенләй ычкындыңмы? Сине бит шифаханәнең дә адәм кермәслек бүлегенә салганнар. Монда тиләләр генә ята... Анда безнең квартальный план яна Шундый чакта һичнинди кысаларга сыймаслык чарага барырга ярыймы? Моны яшь-яшь малайлар да эшләмәс иде Син бит инде — шактый ук карт хезмәткәр Бухгалтериянең генә түгел, бөтен предприятиенең эше сиңа бәйле...

Камәрия дәшмәде Мондый мәсьәләләр инде кырык ел буе аңа бәйле Ул бер генә айда да аларга хыянәт итмәде Хәзер ни булды соң?!

Аның фикерләрен сиземләгәндәй, баш бухгалтер сорый куйды:

— Карале, ни булды соң сиңа? Шундый чак икәнен дә бик яхшы беләсең, ни булды? Температураң да, кан басымың да, йөрәгең-үпкәң дә гадәттәгечә эшли, диләр Ни булды?..

Үзенә ни булганын Камәрия үзе дә белми иде. Тик әлеге баш бухгалтерның шифаханәгә килүе (гомер булмаганча), аннары үзенең шифаханәгә ятуы (гомер булмаганча) аның акылына сыймый иде. Мондый очракта нишләргә, кемгә, ни дип җавап бирергә — ул белми иде Башында бер генә акыллы фикер дә тумады. Чыннан да, ни генә булды соң әле?! Баш бухгалтерның гел саннарга гына корылган акылындагы сорауга ул җавап бирергә тиешлеген яхшы чамалый иде инде. Аңа нинди дә булса туры җавап бирмичә котылып булмый Бу — бухгалтерия Саннар өчен генә түгел, кешеләр язмышы өчен дә төп-төгәл җавап таләп ителә монда Бу да — бухгалтерия!

Камәриянең уй-фикерләрен раслаган шикелле, баш бухгалтер үзенең бәгырь кискеч соравын кабатлады:

— Ни булды! Син миңа шуны гына әйт ни булды?

Камәрия тагын да сүзсез ятты әле. Шактый ятты. Теге баш бухгалтер дигәннәре дә, үзенең зур ук түрә булуына карамастан, аның тын торуын көтеп утырды Икесе дә сүзсез генә байтак вакыт уздырдылар Ниһаять, Камәрия үзе сүз башлады:

— Бүлекнең бу кварталга караган бөтен эш планнары, балансслар — минем тартмада...

— Ничек инде ул — «тартмада», син аны үз кулларың белән тапшырырга тиеш!

— Теләмим... — Камәриянең бу бәндә белән ярты сүз дә сөйләшәсе килми иде. — Теләмим дә, бүтән сезнең якка аяк та атламыйм. Бетте, киттем. Рәнҗеп.

Камәрия иң соңыннан гына әйтелгән сүзенең теленә ничек килеп керүен сизми дә калды. Бик туры-төгәл фикере иде бу аның, моңарчы яңгырарга тиешле сүзе генә табылмаган икән бит. Чыннан да аның бөтен вөҗүде, һәр күзәнәге бу тирәлектәге һәр нәрсәгә, кичергәннәренең һәр мизгеленә бары тик рәнҗү белән генә тулып ташыган: ятимлектә узган балачак, ачлы-туклы укып йөрүләр, югары белемле килеш тә йортсыз-җирсез интегүләр, затлы адәм балаларыча ашарга да җитми торган хакка эшләүләр, шәфкатьсез җитәкчеләргә бил бөгәргә мәҗбүрлек, ниһаять, гомерең көзгә авышканда, бер сасыкның кочләргә ябышуы...

— А-а-ай! — Аның бәгырь түреннән чыккан ыңгырашуына башта игътибар итүче булмады. Шифаханәдә мондый авазлар адым саен яңгырый. — А-ай! Рәнҗи-и-имен! Рәнҗи-имен!..

Кемдер Камәриянең сөйләшә башлавын хәбәр иткән, күрәсең. Бүлек табибы аның янына хәтта бер өлкән врачны да ияртеп килеп керде Ятагы янына тукталдылар да бүлек башлыгы өлкәнрәгенә Камәрия турында сөйләргә тотынды: «Ничәнче көн инде, гел шул бер сүзне кабатлый. Ашамый Дару бирүче тә йокламый...»

— Минем үземне генә аның белән калдырыгыз әле, — диде карт врач. — Авыру тарихын беләм...

Ул, башкалар шикелле, урындыкка-фәләнгә түгел, Камәриянең ятагы читенә үк утырды Шоп-шома учларына Камәриянең чөгендер басуыннан соң кытыршыланып каткан кулларын алды.

— Мин синең хәлне аңлыйм шикелле, кызым...

— И-и-и, минем шул «кызым» сүзен тансыклаганымны каян белдегез?

Карт табиб гүя аның бу сүзләрен ишетмәде дә Үзенекен дәвам итте.

— Гаҗәп. сезнең һөнәр кешеләрендә рәнҗешне болай тирән кичерү сирәк. Сез исәп-хисап, коры саннар белән генә эш итәсез .Югары белемле, хәзер компьютерга гына ышанырга өйрәнгән финансист алай нечкәреп китмәскә тиеш иде кебек. Килешми дә. Исәпләп карагыз әле?! Безнең чынбарлыкта рәнҗетелмәгән зат бармы? Табыгыз, ичмасам, берне генә! Иң якын кешеләрегезнең гомерен хәтерегездән кичерегез — аңлашыла төшәр. Инде башлап китү өчен менә мин үземнекен сурәтләп күрсәтәм. Миңа уники яшьләр чамасы иде — раввин булганы өчен генә (бу — без, яһүдләрнең дин әһеле) әтине төрмәгә яптылар. Әнием, гаилә авызыннан өзеп, аңа ел буе ризык ташыды. Әй, сөенеп кайта иде: «Алдылар, бүген дә алдылар! Руәиның туйганчы ашагандыр! Башта айга бер генә китерегез, дип кисәткәннәр иде — хәзер, кайчан илтсәң дә, алалар, рәхмәт төшкерләре...» — дип сөйләнә. Әле бу елларда, барлык «халык дошманнары» аклангаң соң гына белешеп чыктым: әтиемне, кулга алынганнан соң, өченче көнне үк атып үтергәннәр...

Табибның куллары калтыравын сизде Камәрия, йөзенә күз салды, әмма тәҗрибәле невропатолог елмаюлы җылы карашын үзгәртмәде Камәриянең, тынычлана төшеп,үз хәленнән башканы да уйлый башлавын тоеп, ул әңгәмәне дәвам итте.

— Теге коточкыч сугышка да эләктем мин. Ул дәвердә яһүдләргә карашны беләсездер инде: теге яктан да, бу яктан да — «аллага шөкер» булды. Исән-имин кайткач, укып, юрист булдым. Кулда — югары белем дипломы! Киттем эшкә. Тот капчыгыңны! «Халык дошманы» баласына юристлык хәрәм икән бит! Аны ник башта ук әйтмәгәннәрдер?! — Карт тагын да сөйкемлерәк иттереп елмайды. — Башка һөнәрлеккә, врачлыкка укырга тотындым... Инде әйт: ул чакларда мине рәнҗемәгән??? Әй, кызым, бездә теләсә кемне, хәтта патшаларның үзләрен дә теләсә ничек рәнҗетәләр. Аларын — әле ничек кенә?! Хәтта каберләрен, кабер ташларын җимереп-җимереп аталар... Без — адәм балалары — туган җирне сайларлык көчебез юк. Сабыр булырга гына кала...

Табиб кузгалды.

— Шулай да дөнья гел яманлыктан гына тормый, кызым — Ул саубуллаша кебек иде инде. — Сез күбрәк күңелле мизгелләр турында уйлагыз! Мин сезгә даруларның зур дозаларын яздыртмам.үзегезне кулга алу хәерлерәк. Тизрәк терелерсез... — Табиб тагын да ихласрак елмаеп куйды. — Ә хәтерегезгә һич рәнҗетелмәгән берәр якыныгызның язмышы килеп төшсә, миңа да сөйләрсез! Гомер кышымда минем дә бер шатланасым килә лабаса!..

Камәрия, аның ярым шаяртып, ярым бик тә үтемле итеп сөйләгән сүзләренә рәхмәт йөзеннән, елмаерга тырышты Булдыра алмады. Чыраен үзгәртүнең мөмкин түгеллеген сизде. Әмма җанының тынычлану кысасына керә башлавын, аңа сабыр итүдән башка чара калмаганлыгын аңлый иде инде ул.

Карт табиб, инде чыгып китәргә борылды дигәндә, тагын бер киңәш әйтте:

— Төмам үзегезгә үк төшкән булсалар, ул эштән китүегезне карагыз! Һөнәрегез әйбәт! — Ул, күкрәк кесәсеннән бер кәгазь кисәге алып, Камәриянең учына кыстырды. — Минем яшь бер дустым гаепләнүчеләрне яклау ширкәте ачты — адвокатлар ширкәте. Теле... Сөйләшеп куярмын. Телисәгез, аңа шалтырата аласыз. Бик шәфкатьле кеше, рәнҗетергә бирмәс!..

Камәрия бу тәкъдимгә рәхмәтле залыгын белдереп тә, рәхмәт хисләрен сиздерергә омтылып та, инде ничә тәүлек йокы күрмәгән күзләрен йомды...

Ник күзгә төтен җибәрәләр?

Хәзер көндәлек матбугатка язылуның иң кызган вакыты. Шуңа күрә һәр басма көн саен бу хакта укучыларының исенә төшереп тора, язылырга онытмагыз, дип искәртә.

Әмма шунысы эчне пошыра, кайбер басма хезмәткәрләре үзләрен башкалардан өстен куярга тырышып, турыдан-туры ялган юлына басалар, күзгә төтен җибәрәләр Мәсәлән, яңа чыга башлаган «Мәдәни җомга»ны алыйк. «Мәдәни җомга» — һәр атнаның бишенче көнендә 24 битле чыгучы иң саллы басма. «Мәдәни җомга» күләменә карата иң арзан гәзит, язылу бәясе 6 айга — 18 мең сум» дип язалар анда Шулаймы соң? Аның форматын зур форматка күчерсәк, атнага өч тапкыр чыга торган гәзит була бит ул. Ә нишләп әле, шулай булгач, «иң саллы»? Атнага зур форматта чыга торган «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан», «Шәһри Казан» аннан салсызрак буламы? Инде бәяләргә килик. Алты айлык бәяләрен чыккан саннарга бүлгәндә, киресенчә, «Мәдәни җомга» югарыда саналган басмаларга караганда иң кыйммәте булып чыга бит Моны исәпләү өчен һич тә баш ватасы түгел

(«Ватаным Татарстан»).

P.S. Чыннан да, көндәлек матбугатка язылуның иң кызган вакытында, яңа гына тәпи йөри башлаган сабый хәлендәге «Мәдәни җомга»га шундый зур игътибар күрсәтеп, безгә бушлай реклама ясаган җитмеш биш яшьлек олпат «В Т » гәзитенә һәм аның хезмәткәрләренә ихлас рәхмәтебезне ирештерәбез.

Иделгә «ашыгыч ярдәм» кирәк

Идел — күп республикаларның яшәү чыганагы. Ләкин аның бассейны авыру: һавасы пычранган, үсемлекләр дөньясы ярлыланган, суы да чиста түгел. Шунлыктан бу регионда яшәүче халык та күбрәк чирли һәм үлә башлаган. Шуңа күрә Идел бассейнын дәвалауга Русия Федерациясе хөкүмәте 267,7 триллион сум (1994 елгы бәяләрдә) бирергә ниятли.

(«Российская газета»).

Ата торган ручка

КамАЗның кою заводында эшләүче тыйнак кына ир-егетнең кесәсеннән милиция хезмәткәрләре авторучка тартып чыгаралар Аның янында кече калибрлы 7 патрон да була. Патрон тыккач, әлеге ручка ата торган коралга әйләнә. Тик бу «рационализатор» үзенең ачышына патент алу турында уйламаган да, билгеле

(«Вести КамАЗа»).

Салам өстендәге эт шикелле...

«Независимая газета» (10.11.95) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Василий Лихачев белән әңгәмә урнаштырган. Ул үзәк белән төбәкләр арасындагы мөнәсәбәтләргә багышлана. Шушы әңгәмәдән В.Лихачевның берничә кызыклы фикере белән танышып узыйк. Әлегә үзәк «бүлгәлә дә хакимлек ит» дигән принцип белән эш итә. Хәзер «берләштер дә җитәкчелек ит» дигән формуланы кулланырга вакыт. Бүгенге көндә төбәкләргә караш һич тә канәгатьләнерлек түгел. Мәскәү телевидениесе бары тик үзәк эшчәнлеген генә яктырта. Төбәкләрдән мәгълүмат юк дәрәҗәсендә. Димәк, аларның үз каналы булырга тиеш.

Мәскәү белән Казан арасындагы мөнәсәбәт исә салам өстендәге этне хәтерләтә. 80 процент кредит ресурслары Мәскәүдә тупланган. Без җибәргәч, финанс министрыбыз Дмитрий Нагуманов та эт астындагы саламны электерә дә кирегә йөгерә. Шунда электерсәләр, аның һичшиксез ыштанын салдыралар. Шуңа күрә министрыбызның Мәскәүдән еш кына ыштансыз кайткан чаклары да була, ди В.Лихачев.

Кеше тәне дә тимер кебек тутыгырга мөмкин

Дейтон, Огайо

Олпат гәүдәле Кристоффер Фермюллер, буыннары бөгелми, аяк-куллары авырлык белән хәрәкәтләнә башлагач, үзендә артрит дип уйлый. Табиблар аның иске тимер кебек тутыга башлавын әйткәч, ул артына авып китә яза.

Бу — бик гаҗәп хәл, әмма 22 яшьлек егетнең тән күзәнәкләренә шулкадәр күп тимер сеңгән, тәне хәтта тутыккан тимер төсенә кергән Табиблар егетнең гемохроматоз дигән бик сирәк авыру белән интегүен раслыйлар һәм эшләр алга таба да шулай барса, тән тимер кебек ватылачак, дип искәртәләр табиблар.

— Буыннарыңа тимер утырган, дигәч, мин шаярталар дип торам, — ди культурист егет — Алар составында тимер күп булган ризыклар һәм дарулар куллангансың диләр. Хәзер тәндәге кислород белән тимер реакциягә кергән дә мин тутыгам икән

«Күгәрүче» буйдак егет моннан өч ай элек уң җилкәсе селкенми башлагач, хафага төшә. Аннары берничә атна эчендә буыннары, аяк-куллары бик авырлык белән хәрәкәтләнә башлый Табибка мөрәҗәгать иткәндә Кристофферның муены һәм бер тезе бөтенләй хәрәкәтсез була.

Егетнең күгәргәнен белгәнче, аңа ничә төрле анализ бирергә туры килә, тәне кызгылт-җирән төскә керә

— Инвалид булып калам икән инде, — дип котым очкан иде, — ди Фермюллер, — әмма врачлар терелтергә вәгъдә бирде.

(«Всемирные новости»).



Сүз ирегән — иреккә!

«Русия Федерациясендә массакүләм мәгълүмат чараларына һәм китап басуга дәүләт булышлыгы турында» ике ел көтелгән Закон, ниһаять, Федерация Советы тарафыннан хупланды һәм Президентка кул кую өчен тапшырылды

«Известия» гәзите хәбәр иткәнчә, бу Закон гәзит һәм журналларны сату әйләнешеннән алына торган өстәмә кыйммәткә федераль бюджетка күчерелә торган табышка, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларын үстерү өчен тотыла торган капитал салуларга салым түләүдән коткара Редакцияләр импорт һәм экспортка бәйле пошлиналар бетерелүгә дә шатланачак Матбугатның икмәге булган кәгазь өчен, электрон мәгълүмат чаралары өчен аудио һәм видеоинформация, технологик һәм инженерлык җиһазлары өчен таможня пошлинасы түләүдән азат ителәләр Редакцияләргә почта, телеграф һәм телефон элемтәсеннән файдаланганда, федераль милек саналган биналарны арендага алганда ташламалар ясала Полиграфия предприятиеләрен акционерлаштырганда яңа тәртип журналистлар коллективларына нәшриятлар милкенә бергәләп хуҗа булу хокукы бирә

— Бу исә матбугатның бәйсезлеген сүздә түгел, эштә раслау өчен зур җиңү — ди Русия Журналистлар берлеге рәисе Всеволод Богданов. — Хәзер инде хакимият башлыклары үзләренә ошамаган басмаларның редакцияләрен урамга куып чыгара алмаячак Матбугат таратуга почта чыгымнары да кимер, мөгаен.

Нуриев миллионнары

Лондонда Рудольф Нуриевның әйберләрен — мебель, картиналар, шәхси әйберләрен чираттагы сату булачак. Сатуны оештыручы «Кристис» фирмасы бәяләвенчә, моннан 16 миллион франк чамасы акча киләчәк.

Иң кыйммәтле әйберләрнең берсе — француз рәссамы Жерико картинасы, анда ялангач ир-ат сурәтләнгән. Аннары — 1627 елда эшләнгән клавесин. Каты авыру хәлендә биюче бу уен коралында Бахны уйнаган.

Әлеге миллионнар, суд дәгъвачыларны ачыклап, хәл итеп бетергәнче, беркемгә дә бирелмәячәк. Мирасны, бер яктан, Рудольфның сеңлесе Роза һәм туганнан-туганы Гүзәл, икенче яктан, Рудольф Нуриев фонды дәгъвалый.

(«Известия»).

Аерылмагыз, аерылмагыз, булса да сәбәпләре...

Казанда җомга-шимбә көннәрендә ЗАГС янында бизәлгән машиналар байтак була. Узган ярты елда 2867 парның никахы ЗАГСта теркәлгән. Монысы күңелле хәл. Ләкин шуның янында ук күңелсезе дә бар: ярты ел эчендә 2487 пар аерылышкан.

(«Вечерняя Казань»).

Мәккәгә — автобуста

30 кеше автобуска утырып Мәккәгә хаҗга китте. Корбан гаете вакытындагы хаҗдан аермалы буларак, бу «өмрә хаҗ» (кече хаҗ) дип атала. Аны Борнай мәчете оештырган.

(«Татаринформ»).

Кырым татарлары буйсынмаска чакыра

Кырым тагын Украинаның тотрыксыз төбәгенә әйләнеп бара. Кырым татарлары Мәҗлесенең шәһәр һәм бистә подразделениеләре «коч кулланмыйча буйсынмау акциясенә» әзерләнергә чакырдылар. Бу — утрауда яшәүче 200 мең Кырым татарын сәяси көрәшкә чакыру дигән сүз.

Кырым парламентындагы Кырым татарлары фракциясенең депутатлары 11 тәүлек сәяси ачлык тотканнан соң (9 депутатның 5се госпитальгә салынган) бернинди нәтиҗәгә ирешмәүләре ачыклангач, Мәҗлес шундый карарга килгән. Ник дигәндә, Кырым Конституциясендә дәүләт хакимияте органнарында депортацияләнгән халыкларның гарантияләнгән вәкиллеге һәм Кырымда өч дәүләт теленең тигезлеге турындагы положение кертелмәгән.

Террорның да була төрлесе

Зеленодол районы прокуратурасына килеп кергән бер ир, бу бинаны шартлату белән янап, Ф-1 гранатасын тартып чыгарган һәм шуның белән техник секретарь өстәленә шакыган. Бераздан чыгып киткән. Ярты сәгатьтән әлеге «террорчыны» тотканнар. Ул бер мәктәпнең бизәүче-рәссамы булып чыккан. Прокуратурага бернинди ачуы да булмавын әйткән, бары тик әлеге учреждениедә эшләүче элекке хатынын шул рәвешле куркытырга гына теләгән.

(«Вечерняя Казань»).

Безнең заман Шүрәлесе

53 яшьлек фотограф Шридхар Шилал үзенең сул кулындагы тырнакларын инде 35 ел үстерә. Аның биш бармагындагы тырнакларның гомуми озынлыгы 5,5 метрга җитә, ул инде Гиннесс рекордлар китабына теркәлгән.

Шридхар тырнакларына ныклык бирү өчен аларны махсус лак белән буяуга көнгә берничә сәгать вакытын сарыф итә «Тырнакларым тормышта күп уңайсызлыклар тудыра: аларның сынуыннан куркып, төнлә начар йоклыйм, велосипедта йөргәндә дә кыен, үзем ясаткан уеннарны да уйный алмыйм, иң кыены — ялгызлыкта калуым, — дип зарлана әлеге каһарман — Күршеләр мине гарип, ә балаларымны — психик авыру, диләр Хатыным исә 5 ел инде мине үзенә якын да җибәрми»

Нигә кирәк соң мондый газаплар? Шридхар — ярлы кеше, ул әлеге тырнакларны сатарга теләвен белдереп, үзенең бу хәзинәсен 100 мең долларга алучы булмасмы дип, «Нэшнл Инквайрер» журналы укучыларына мөрәҗәгать итә.

● Шридхар Шилал тырнакларын күрсәтә.

(«Нэшнл Инквайрер» журналыннан).

Куян күчтәнәче

Язучылар һәм язылучылар

Иярәнде бер болыт — килә дә ява, килә дә ява дигәндәй, шагыйрьнең шундый юллары гел искә төшә дә тора:

Акылыннан яза-яза,
Бар кеше дә яза!..

Өүвәлге заманнарда бабаларыбыз имана җире сорап, патшага прошение язганнар Барыбер ярык тагарак янында утырып калганнар!..

Тора-бара милли җаны булган кешеләр: «Милләтебез бетә, телебез киселә!» — диеп язганнар һәм, кара мөһерле путевкаларын учлап, «ял йортлары»на — Себер һавасын суларга китеп барганнар!..

«Нык үскән социализм» җимерелгәч, тагын да күбрәк яза башладылар. Донья «язучылар» белән тулды.

Президентлар указ арты указ яза.

Депутатлар эшләми торган законнар яза

Думага ыргылган әфәнделәр, бер-берсен пычратып, газитләргә гайбәтләр яза.

Җитәкчеләрнең йомышчы-сәркатипләре юбилей уңаеннан сугыш ветераннарына тәбрик-котлаулар яза.

Олкән агай-апалар, ипилек-чәйлек омет итеп, үтенеч-гозерләр яза.

Ичкерия илендә газиз балалары

кырылган мескен аналар, канлы яшьләрен түгә-түгә, түрәләргә үтенеч хатлары яза.

Китаплары доньяга чыгудан туктаган талантлы язучылар да һаман язалар икән әле!

...Бик әрнетә икән чынлык,
Әрни җирем-кырым?!
Өер-өер саллар сыман
Йөзә матәм җыры.
Бер якында, бер еракта
сәер кара колеш...
...Бии кемдер ыштансыз да
Тәһарәтсез килеш...
Җибәрмәсләр иде Җирнең
болай ук кадерен —
бу җир минем әткәй белән
әнкәем кабере!!!

Әнә шулай язган икән Ростәм Мингалим дигән шагыйрь дә.

Мондый язучыларга «кукиш» күрсәтәләр, ялагайларына кәнфит суырталар...

Әмма чын язучылар нишләсен соң?! һаман язалар да язалар!

...Килә күрмә, какма, бала,
ачма донья капкасын!
Күзләреңә ут кабыныр,
Куркыныч якты монда;
Качып кал син гел караңгы
гасырлар карынында.

Йа, Хода! Нәрсә соң бу! Доньяга тумый калган балаларга шагыйрьләр онә ни дип әйтәләр!

Шаярта гына торганнардыр ла алар! Ә, бәлки, йөрәкләренең әрнүенә түзә алмыйча уфтанулары, сызлануларыдыр?!. Мөгаен, шулайдыр... һәрхәлдә, шулай булуына бик тә ышанасы килә!

Җаннарында өмет уты балкыган ата-аналар, шулай буласына ышана-ышана, сабыйларын: «Тәүфыйклы булып үс, балам!» — дия-дия тәрбия кыла.Бүген кайлардадыр атом бомбалары сынала, кайдадыр... Ләкин боларның берсендә дә сабыйларның гаебе юк. Алар бу доньяга килгән икән, алар бу җирдә яшәргә, көләргә, шатланырга тиешләр!

Пычрак гайбәтләр язылсын, тау-тау булып өелсен, әмма сабыйларыбыз өчен курчаклар ясыйк әле, аларны сөендерерлек әсәрләр языйк! Алар өчен китап-журналлар чыгарыйк әле!

Менә алтынчы ел инде тарихыбызда беренче мәртәбә тосле, матур «Салават күпере» журналы балаларны сөендереп килә. Язучылар «Салават күпере»нә яңадан-яңа әкият-хикәятләр язалар.

Элемтә бүлекләрендә эшләүче апалар исә сабыйларын куандырырга теләүче һәр кешене дә киләсе ел өчен «Салават күпере» журналына язалар! Рәхим итегез!

Менә мин дә сабыйлар өчен бер әкият яздым әле. Шуны сезгә дә сөйләп карыймчы.

Зиннур ХӨСНИЯР,
«Салават күпере» журналының баш мөхәррире.

Салават күпере һәм «Шүрәле шаяруы»

Хөрмәтле олкәннәр!

Сезгә мәгълүм булганча, киләсе елның апрель аенда сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 110 ел тула. Бу — шигърият бәйрәме генә түгел, ә бөтен татар халкының олуг бәйрәме!

Билгеле, бүгенгесе көндә Тукай әсәрләре һәр гаиләнең дә ой түрендә Инде менә ничәмә буын Тукай рухы белән тәрбияләнеп үсте Мәсәлән Су анасы Шүрәле, Былтыр һәм бүтәннәр олкәннәр күңелендә дә яши.

Шуларны искә алып, «Салават күпере» журналы редакциясе Тукай юбилеена «Шүрәле шаяруы» дип аталган махсус китап әзерли. Әлеге җыентыкта шагыйрь әсәрләрендәге геройлар тормышка бөтенләй бүтән сыйфатта сурәтләнәләр Гомумән, бу китапта Тукай геройлары Яңа заман рухында тасвирлана Анда урын алган әкият һәм хикәяләрдә, пьеса һәм җырларда Су анасы, Шүрәле, Кәҗә белән Сарык һәм башка образлар бүгенге кон балалары белән аралаша, төрле хәлләргә тара. Мәсәлән, бу юлы Тукай заманындагы Шүрәле белән Былтырның малайлары очраша!

Хөрмәтле укытучылар!

«Шүрәле шаяруы» дип аталган әлеге җыентык, Тукай иҗатын өйрәнгәндә, сезгә зур таяныч, ярдәм булыр, дип уйлыйбыз!

Кадерле ага-аналар!

Бүгенге заман шүрәлеләре сабыйларыгызның иң якын дусларына әверелеп китәр, дип чын күңелдән ышанабыз!..

Бу җыентык «Салават күпере» журналы китапханәсе» сериясеннән донья күрәчәк. һәм, димәк, киләсе 1996 елга «Салават күпере»нә язылган абунәчеләрнең өйләренә, «Шүрәле шаяруы» китабын элемтәчеләр үзләре китереп бирә!

Зиннур ХӨСНИЯР

Эт белән мәче

(Г.Тукайның «Кәҗә белән сарык» әкиятенә ияреп)

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер ир белән хатын Боларның эт белән мәчесе булган Эт ишегалдындагы чебиләрне тилгәннәрдән саклаган, ә мәче печәнлектәге тавык йомыркаларын күселәрдән каравыллаган.

Эт тә, мәче дә бер-берсен яратмаганнар, үзара дошманнар икән, ди. Мәче берәр яман эш кылса, эт аны шундук хуҗаларга әйткән Ә мәче этне әләкләп торган.

Менә бер заманны эт кояшта кызынып, чебиләрне тилгәннәрдән саклап ята икән, печәнлеккә таба ике зур күсе йөгергәнен күргән Эт аларны куркытмаган да, куып та җибәрмәгән. «Әһә!» — дип куанган ул. — Хәзер болар печәнлектән күкәй чәлдерәчәкләр! Моның өчен хуҗалар мәченең кирәген бирә инде! Ә мәче бу вакытта күрше песиенә кунакка киткән булган икән.

Дөрестән дә, теге күселәр печәнлектән күкәй урлап чыгып киләләр, ди. Шаккатмалы хәл күсенең берсе, аркасына ятып, аяклары белән күкәйне кочаклаган, ә икенчесе аны койрыгыннан өстерәп бара ди! Менә әкәмәт! Менә хәйләкәрләр!

Ә эт тынын да чыгармаган, ди. Күселәр теге күкәйне икесенә бүлеп, тәмләп кенә ашагач, тагын урларга килгәннәр. Эт дәшмәгән. Эченнән генә: «Тагын килегез, тагын!» — дип уйлап яткан Теге ач күз күселәр янә килгәннәр Шулай итә торгач, печәнлектә бер күкәй дә калмаган ди Күселәр ташып бетергәннәр «Хуҗабикә моның өчен мәченең кирәген бирә инде!» — дип, эт тик куанып ята, ди.

Менә өйдән хуҗабикә килеп чыккан Эт, ләң-ләң өреп аның каршысына йөгергән һәм ялганнарга керешкән. «И, хуҗабикәм! Беләсеңме син, мәче печәнлектәге күкәйләрне җыйды да күрше песиенә кунакка китте!» — дигән Моны ишеткәч, хуҗабикә кулына таяк алган да мәчене эзләп китәргә җыенган Шулвакыт мәче үзе дә кайтып килә икән Йөзе бик шат, кунакта булгач, тамагы да тук, бертуктаусыз иреннәрен ялый, ди Хуҗабикәнең кулындагы таякны күргәч: «Әһә, эткә эләккән икән!» — дип сөенгән. Ә хуҗабикә, мәчене күрүгә, таягы белән аңа ташланган. «Аһ! Син карак! Үзең сакларга тиешле күкәйләрне үзең үк урлагансың! Мә сиңа! Мә!» — дип мәчене кыйнаган хуҗабикә.

Ә эт, эчен тота-тота, көлә икән. Песикәем хуҗабикәгә «Мин урламадым, минем гаебем юк!» — дип тә әйтә алмаган Авыртуга түзә алмыйча, мыраулап кычкыра-кычкыра, чыгып йөгергән ишегалдыннан.

Мияубикә моның кем эше икәнен сизенгән, әлбәттә «Хуҗабикәне салпы колак эт котырткан!» — дип уйлаган ул һәм үзе дә аннан үч алу җаен эзли башлаган Менә бер заман эт күләгәдә йоклап ятканда ишегалды өстендә иләмсез зур канатлы тилгән күренгән.

«Әһә!» — дип уйлаган песи. — Бу тилгән эт саклый торган чебиләрне алып китсә ярар иде! Менә аннан соң хуҗабикә этне чукындырыр иде!»

Дөрестән дә, тилгән, тиз генә ишегалдына төшеп, бер тавык чебиен эләктереп тә киткән Ачыргаланып кыткылдаган тавышка эт уянып китсә, тилгәннән җилләр искән инде Ишегалдына хуҗабикә дә йөгереп чыккан Мәче аның янына атылган. «Хуҗабикәм! — дигән ул. — Бер чебине тилгән алып киткән! Ә эт йокы симертә иде!»

Шуннан соң хуҗабикә, таяк алып, этнең сыртына берне сыптырган! «Нигә йоклап яттың? Нигә чебиләремне сакламадың?» — дип ярсыган ул. Ә мәче рәхәтләнеп көлә икән, ди Үз башына колгән икән песи. Хуҗабикә ире белән киңәшкән дә: «Сез әрәмтамакларны асрап ятмыйм!» — дип, мәчене дә, этне дә куып чыгарган.

Нишләсеннәр инде, капчык асып, чыгып киткәннәр болар. Баралар икән, баралар икән, бара торгач, бер кара урманга килеп җиткәннәр. Җитмәсә әле, юл буе талашып, сугышып барганнар Шуннан эт мәчегә әйткән: «Син минем дошманым! Бар, үз юлыңда бул! Минем арттан ияреп йөрмә!» — дигән Мәче дә аптырап калмаган: «Син дә минем арттан ияреп йөрмә! Мин сине яратмыйм!» — дигән.

Шулай итеп, болар икесе ике якка китеп барганнар, ди.

Мәче ерак китә алмаган, моның каршысына елтыр күзле бер төлке килеп чыккан. Ул мәчене тотып алган да: «Тамагым да ачыккан иде, хәзер мин сине ашыйм!» — дигән. Мескен мәче куркуыннан кычкырып елап җибәргән. Аның елаган тавышы бөтен урманны яңгыраткан. Әлбәттә, моны эт тә ишеткән. Дошман булсалар да ничә еллар буе бер ишегалдында гомер иткәннәр бит инде Эт мәчене кызганган. «Берәр хәл булды микән?» — дип, шул якка таба чапкан.

Этне күрүгә, төлкенең аяк буыннары калтырый башлаган, ул бар көченә качып киткән. Ә мәче куанычыннан янә елап җибәргән: «Әй, эт дускаем! Рәхмәт инде сиңа! Син минә явыз төлкедән коткардың! Әйдә, гел бергә булыйк!» — дип ялварган мәче. Эт моңа риза булмаган. «Юк, мин синең белән беркайчан да дуслашмыйм!» — дип үз юлы белән китеп тә барган, ди. Бара икән бу, бара икән, шулай бара торгач, мескен эт бүреләр өеренә очраган. Бүреләр этне чолгап алганнар да: «Без хәзер сине тотып ашыйбыз!» — дигәннәр. Эт куркуыннан каты итеп өрергә, еларга керешкән Әлбәттә, этнең елаган тавышын мәче дә ишеткән. Ишеткән дә, эткә ярдәмгә йөгергән. Килеп җитсә, ни күрә явыз бүреләр, тешләрен ыржайтып, этне ботарларга җыеналар, ди Мәче озак уйланып тормаган, шыпырт кына янәшәдәге юан агач куышына кереп киткән Агачның куышы бик зур, ди Куыш эчендә аз гына тавышлансаң да, ул тавыш, мең мәртәбә көчәеп, бик каты ишетелә икән, ди. Мәче, куыш эченә кергәч, бар көченә мыраулап, кычкырырга тотынган Куыш эченнән гайрәтле арыслан тавышы ишетелгән кебек икән. Тавыш шулхәтле көчле яңгыраган, куркуларыннан тиеннәр, тукраннар агач башларыннан егылып төшкәннәр. Җиргә яңгыр кебек нарат күркәләре, имән чикләвекләре ява, ди. Ә бүреләрнең исә котлары алынган Алар, арыслан килә дип уйлап, койрыкларын бот араларына кыстырганнар да тиз генә сыпыртканнар.

Эт, мәчене күргәч, шатлыгыннан нишләргә дә белмәгән Мәчене кочаклап ук алган, аңа мең-мең рәхмәтләр әйткән.

Шулай итеп, элекке ике дошман дуслашканнар, гомергә бергә булырга сүз куешканнар.

Эт белән мәче, култыклашып, җырлый-җырлый, урман буйлап киткәннәр:

Их, дусларым, дусларым,
Дусларым, дус-ишләрем.
Әгәр сездән аерылсам,
Ялгыз башым нишләрем?..

Бу вакытта эт белән мәченең элекке хуҗасы урманда куян куып йөри икән. Ике дусны — эт белән мәчене — күреп шаклар каткан. «Кара, ничек дуслашканнар!» дип куанган ул һәм аларны өенә алып кайтып киткән.

Шуннан соң эт белән мәче тагын бер ишегалдында яши башлаганнар.

Шулай бер кон узган, ике кон, өч кон... Бәрәч, болар янә әләкләшә, сугыша башламасыннармы!

Мәче — эткә, эт мәчегә дошман булган! Бер дә тыныша алмыйлар, гел талашып торалар икән!..

Мөгаен, бу ике дошманны — эт белән мәчене — янә кара урманга чыгарып җибәрергә кирәктер?! Тагын дуслашып кайтсыннар әле...

ЗАМАН ҺӘМ ТАРИХ

Октябрь инкыйлабыннан соң язылган тарихыбызда бөек милләтпәрвәребез, Русиянең II һәм III Дәүләт думалары депутаты, эчке Русия һәм Себер төрек-татарларының милли-мәдәни мохтарияте рәисе, татар халкының эмиграциядәге вәкиллеге рәисе, Төркиянең Бөек милләт мәҗлесе депутаты, хокук тарихы, хокук белеме буенча беренче фундаменталь хезмәтләр авторы, Истанбул университеты, Парижның Сорбонна университеты каршындагы славян институты профессоры Садретдин Низаметдин улы Максудиның тормыш юлы, аның татар милләте, мөселман халыклары хакына җәелдергән эшчәнлеге моңарчы аз яктыртылды. Үзенең чын тарихын, мөхтәбәр милләтпәрвәрләрен, үз милләтенең асыл затларын белмәгән берничә буын үсте, укыды, яшәде. Ләкин шуңа да карамастан, халкыбызның хәтер тирәнлегендә милләтебезнең алтын баганалары булган Гаяз Исхакый, Габделбари Баттал, Фатих Кәрими, Һади Атласи, Зыя Камали, Муса Бигиев, Һади Максуди, Садри Максудиларның исемнәре, аларның хезмәтләре төрле җирләргә таралган архивларда, Сталин чорының дәһшәтле елларын узып сакланган.

XX гасыр башында татар милли хәрәкәте идеологларының берсе булган Садри Максудиның II һәм III Дәүләт думаларында кимсетелгән, буйсындырылган татар милләтенең, мөселман халыкларының хокукларын яклап сөйләгән нотыклары турында җәмәгатьчелек күпмедер дәрәҗәдә хәбәрдар.

Әлеге язма С.Максудиның 1909 елда III Дәүләт думасы делегациясе составында Англиягә булган рәсми визиты турында. Аның Татарстан архивларында бер-ике данә генә сакланып калган китабы һәм аның Англиягә булган рәсми визиты турында язмалар моңарчы матбугатта күренмәдә булса кирәк. С.Максуди үзе исә бу сәфәре турында 1914 елда «Өмид» литотипографиясендә басылып чыккан «Англиягә сәяхәт» дигән китабының кереш өлешендә: «Мәмләкәт вәкиле булып баргач, анда кылган эшләремнән, анда сөйләгән сүзләремнән үз милләтемне хәбәрдар итәргә тиеш булдым», дип яза.

XX гасыр башында Англиядә Русия белән мөнәсәбәтләрне якынайту максатыннан чыгып, «Россия әхвалиятен өйрәнү» җәмгыяте төзелә. Русиядә Дәүләт думалары чакырылып, анда халык тарафыннан сайланган депутатлар дәүләт эшләрендә катнаша башлагач, патша хөкүмәте идарә итүнең демократик тәртибенә юл тота дип, бу җәмгыять III Дәүләт думасында төп рольне уйнаган фиркаләрнең вәкилләрен Англиягә рәсми визит ясарга чакыра.

Чакыруны югары дәрәҗәдә оештыру максатында, әлеге җәмгыятьтә бер комитет оештырыла, аның составына Англиянең танылган сәясәтчеләре, министрлары, галимнәре, әдәбият-сәнгать әһелләре керә. Комитет җитәкчесе профессор Перс депутатларны Англиягә чакыру өчен Петербургка үзе махсус килә. Думаның үзеннән — 15, ә Дәүләт Советыннан 5 кеше чакырыла. Алар арасында октябристлар, урталыктагы уңнар, кадет, поляк, мөселман фиркаләреннән вәкилләр (шул исәптән, октябристлардан — 7, урталыктагы уңнардан — 3, мөселман фракциясеннән 1 кеше) була.

Сигез кешелек мөселман фракциясеннән делегат итеп С.Максуди тәкъдим ителгәч, профессор Перс «Һиндстан мөселманнарының бездә сайлау хокуклары юк, Русия мөселманнарыннан Дәүләт думасы депутатының Англиягә килүе аларда каршылык тудырмасмы?» дигәч, аңа каршы сул октябристлардан булган А.Звягинцев: «Садри Максудов аз санлы фракция әгъзасы булса да, ул 20 миллионлы Русия мөселманнарының хакыйкый вәкиледер. Думадагы башка бер генә депутат та үзен Русиянең 20 миллионлы халкы вәкиле дип игълан итә алмас. Без мөселманнарга үзебез илән тиң хокук вә хакка лаек булырга тиешле ватандашлар дип карыйбыз» ди. Аның фикерен Дума рәисе Хомяков, депутатлардан Милюков һәм Гучков хуплыйлар. Перс та «Русия мөселманнарын күреп, бәлки, безнең хөкүмәт тә гыйбрәт алыр, бер нәтиҗә чыгарыр», дип риза була һәм, шулай итеп, Садри Максуди Англиягә рәсми визит белән барачак Русиянең III Дәүләт думасы делегациясе составына кертелә.

Англиягә баручылар арасында Дума рәисе Хомяков, депутатлардан Звягинцев, граф Бобринский, Шидловский, граф Алсуфьев, Стахеевич, князь Волконский, Маклаков, «Новое время» гәзитеннән Б.Суворин, «Биржевые ведомости» хәбәрчесе Александровский да була.

С.Максуди Англиягә барганда, үзләре узган юлларга, илләргә, аларның халыкларына, хәятләренә сокланып: «Галәм хәлләренә һәрвакыт үз даирәң офыгыннан гына карау мәгъкуль түгел. Бераз башка офыклардан да карарга тырышырга кирәк» дигән. Ул Русия өчен әрнеп, борчылып бара һәм соңыннан үзенең «Англиягә сәяхәт» дигән китабында юлда күргәннәре турында болай дип нәтиҗә дә ясый: «Бу илләрнең, андагы халыкның таза, матур яшәвенең ике сәбәбе бар: беренчесе — бу илләрнең халыкларының эшчәнлеге, тырышлыгы, икенчесе — хөррият». Бельгия аша узганда, мәсәлән, аны әлеге 7 миллионлы халыклы илнең («Безнең Русиянең бер зуррак өязе кадәр мәмләкәттер») төзек, таза яшәве сокландыра: «Бельгиялеләрнең фәлсәфәсе: дөньяда тормыш никадәр авырайган саен, шулкадәр эшчәнлекне арттырып, хурлыклы ачлык хәленә калмау. Бельгиядә ач кеше юк, простой рабочий көнгә ике мәртәбә итле аш ашыйдыр. Мәмләкәт шулкадәр бай, гади эшче аена 40 сумнан ким алмый. Ничек итеп болар бу хәлгә килә? Күп эшләп. Шул вакытта дөньяда тору көннән-көн читенләшә барадыр, истикбалда хәят дәһшәтле бер вакыйга халәтен алачактыр» дип, ул киләчәкне алдан һәм дөрес күрә белгән.

Халык тормышын яхшы белгән, халыкның ихтыяҗларын бала вакытыннан эчтән күреп үскән, шул изелгән, кимсетелгән халыкның бер вәкиле булган С.Максуди юлда үзенең граф Алсуфьев белән булган бәхәсендә: «Менә безнең вазифабызда яңа бер тормыш ачыладыр. Вазифабыз хәятнең һәр тарафы ислахка мохтаҗ, алдымызда бик күп хезмәтләр күренәдер. Әйдәгез, әзрәк үзегезнең интересларыгызны онытып, халыкның күтәрелүенә аякка басуына, ислахларның тәмам итүләренә ярдәм итегез, халык сезне хөрмәт итәр». — ди.

Дәүләт думасында Русиянең киң катлау вәкилләре белән бергә берничә ел буе эшләү дәверендә, патша хөкүмәтенең, самодержавиенең урыс булмаган милләтләргә карата булган сәясәтен үз җилкәсендә татыган Садри Максуди Русия халыкларына барлык хокукларны бары тик хөррият кенә китерә алачагына ныграк ышана бара. Соңыннан, еллар узгач Англиядә күргәннәренә анализ ясап ул: «Англиядәге төхсин бер эш күрсәгез, бу хәлне вөҗүдкә китергән сәбәпләрнең иң тирәне хөррият икәнлегенә, хөррият шәхсиянә ихтирам иткәнлегенә мин көннән-көн ныграк ышанам» диячәк.

Англиядәге визиты вакытында С.Максудиның үзенә иң тәэсир иткәне — Дума делегациясен Англия короле кабул итү, чөнки бу беренче мәртәбә Русия Дәүләт думасы депутатларын чит дәүләт җитәкчесенең рәсми кабул итүе була. С.Максудига әлеге мәҗлестә сүз бирелә һәм ул: «Без Русиядә яңа бер

Садри Максудиның Англиягә сәяхәте

хәятнең башындамыз. Кирәк партияләрдә, кирәк Русиядә мөҗүд милләтләр арасында яңа мөнәсәбәтләр ясала торган замандыр. Русиянең якты киләчәген теләүче вәкилләр тарихи хаталардан сакланган кеби, мөмкин кадәр киләчәктә милләтләр арасындагы суыклык ясаган эшләрдән качарга тиешмез» ди. С.Максуди үзенең чыгышын француз телендә ясый, ә Англия короленә мөрәҗәгать иткән беренчә җөмләсен исә инглиз телендә әйтә.

Англия парламенты эшчәнлегендә С.Максудины сокландырганы — парламенттагы эшче депутатларның хөкүмәтне курыкмыйча тәнкыйтьләүләре, төрле запрослар ясаулары һәм хөкүмәтнең шул запросларга җавап бирергә мәҗбүр булуы. С.Максуди III Дәүләт думасында, аның төрле комиссияләрендә закон проектлары каралганда Русиянең мөселман халыкларының хокукларын яклап күп мәртәбәләр чыгышлар ясый. Ул үзенең Думадагы эшчәнлегендә, могаен, Англия парламентындагы әнә шул депутатларның тәҗрибәсенә дә таянгандыр.

Дәүләт думасының Англиягә визиты ике атнага сузыла. Бу делегацияне рәсми һәм җәмәгать оешмалары, төрле уку йортлары һәм Англиянең атаклы аксөякләре кабул итә. С.Максуди үзе катнашкан һәрбер мәҗлестә диярлек чыгыш ясый. Башкалар, авырсынып, тегә яки бу мәҗлестә катнашудан, чыгыш ясаудан баш тартканда да С.Максуди үзләре чакырылган һәр җирдә булырга, делегация исеменнән сүз әйтергә тырыша. Бу аның Англиянең югары даирәсенә, аның укымышлыларына, киң җәмәгатьчелегенә Русия дигән илдә татар халкы да барлыгын, аның дөнья мәйданында үз урыны булырга тиешлеген дә исбат итәргә тырышуы. Үзенчә әйткәндә, «бу чыгышлар дөньяның иң куәтле бер халкында үзеңнең милләтең хакында тугры уй, тугры фикер бирү, үзеңнең милләтеңне инглиз күзендә күтәрү, һич булмаса, төшермәүгә» омтылышы да булгандыр. Ливерпульдә киң җәмәгатьчелек алдында С.Максудига чыгыш ясарга, «Бүре дә тук, сарыклар да исән калырга тиеш» дигән принциптан чыгып сүз әйтергә туры килә. Монда чыгыш ясаудан хәтта С.Максуди: «ул күп укый, күп йөри, күп белә. Милюков гыйкмәгә Милюков түгел!» дип сокланган Милюков та баш тарта, чөнки биредә һәртөрле сорауларга җавап бирергә туры киләчәк. Дума рәисе Хомяков та, С.Максудига бик дустанә мөнәсәбәттә булган Милюков та аның үз нотыгында Англиянең Һиндстан мөселманнарына карата булган сәясәтә, андагы мөселманнарның сайлау хокуклары булмавы турында әйтүеннән куркалар. Әмма шуңа да карамастан, С.Максуди Һиндстан мөселманнары турында хакыйкатьне әйтмичә кала алмый. «Миңа кадәр сөйләгән нотыклар бик дустанә иде. Бу дуслыкның һәр ике тарафның гражданнарыннан булган мөселманнарның хокукларына яхшылык илән тәэсир итүен өмид итәм» ди.

Ливерпульнең иң асыл затлы аристократлары һәм Русиянең аксөякләре җыелган әлеге мәҗлестә С.Максудиның Русиядә 20 миллионлы мөселман милләте барлыгын белдергәненә эче пошкан, ачуы килгән һәм мөселманнарны «честный дворник» лакей итеп кенә күрергә теләгән: «Татар баласы синең боларны сөйләргә ни хакың бар?» дип кычкырасы килгән бер Дәүләт Советы әгъзасына карата соңыннан үзенең әлеге китабында ул: «Ләкин татар баласы буны аннан сораячак түгел иде инде» дип язачак.

Русия Дәүләт думасы делегациясенең Англиягә визиты дөнья җәмәгатьчелеге өчен дә зур вакыйга була. Чит илләрнең Англиядәге матбугатчылык җәмгыяте журналистларны җыеп, Дума вәкилләре белән очрашу оештыра. Бу мәҗлестә башка мәмләкәтләрдән килгән йөзләгән хәбәрче һәм күп кенә Лондон гәзитчеләре дә катнаша. Һәр сүзе энә күзеннән үткәреләчәк дөньяның иң оста каләм ияләре җыелган әлеге очрашуда С.Максуди түбәндәгеләрне сөйли.

«Матбугатчылык вазифасы бик авыр вазифадыр, нәфис бер сәнгатьтер. Заманыбызда тарих ясалуында иң мөһим фагыйль гәзитләрдер. Бу заманда министрларны төшергән, мәмләкәтләрне сугыштырган һәм килештергән — һәрберә гәзитләр. Европа матбугаты тырыша-тырыша Европаны хөррият юлына төшереп бетердә. Бүгенгә көндә ике ислам мәмләкәте халкы үзләренә хөррият вә тәрәккый урнаштырырга тырышып ятадыр, бу илләрдә идарәи мәшрутә тәмам урнаштыру өчен, һичшөбһәсез, үзләренең халкының иҗтиһады, гайрәте лазем булган кебек, Европаның да мәхәббәте вә симпатиясе шарттыр. Бу — сезнең кулыгыздадыр. Хөрриятка сусаган бу ике мәмләкәткә хөррият кертүгә ярдәм итә аласыз һәм зарар да итә аласыз. Бинаи галия һәрберегез каләмегез илә галәм исламның хөрриятләнүенә тырышачагыгызга ышанганга, мин сезне галәм исламда хөррият урнашуына, тәрәккыйның тәмам җәелүенә хезмәт итүчеләр дип уйлап, сезнең шул фикеремне раславыгызны көтәм». Аның чыгышы көчле күп чабулар астында тәмамлана.

Фуад Туктаров үзенең 1908 елда Усал М.Ф. имзасы белән чыккан «I — II — III Думада мөселман депутатлары һәм аларның кылган эшләре» дигән китабында иң «усал» характеристиканы С.Максудига биргән: «Садретдин әфәнде үзе бик әрсез адәм. Шул әрсезлегә өстенә чибәррәк тәрбиясе, төплерәк гыйльме булса, халык өчен дә файдалы булыр иде». Сорбоннаны тәмамлап юрист дипломы алып кайткан, Казандагы Учительская школаны бетергән, чиста татар телендә «Мәгыйшәт» романы язган С.Максуди турында ул: «Бичараның мәгълүматы бик өстән генә. Сөйләр өчен хәтта татарчага да куәте юк, урысчаны простой татар сәүдәгәре кадәр дә сөйли алмыйдыр, шуның өстенә табигате һәм акылы да, татар әйткәнчә, килделе-киттеледер» ди. Менә шушы «килделе-киттеле» С.Максуди Англиядә Дума рәисе Хомяков, Милюков һәм Звягинцевның соравы буенча Байронга багышланган кичәдә һәм Дарвинның 100 еллыгына багышланган конференциядә катнаша, Бикенгем сараенда Англия короле белән очрашуда, Ливерпульнең аксөякләре алдында һәм Лондонның дөнья матбугаты үзәгендә француз телендә чыгышлар ясый һәм аның һәр чыгышы көчле күп чабулар астында тәмамлана. С.Максудиның берничә елдан соң басылып чыккан әлеге китабының Байронга багышланган бүлеге аның фикер йөртү киңлеген, белеменең тирәнлеген, Байронның иҗатын һәм ул яшәгән чорны, тарихны югары дәрәҗәдә яхшы белүен ачык күрсәтә. Ул дөнья язучыларына бәя биреп, алар арасыннан иң яхшысы һәм үзенең яраткан язучысы Диккенс дип: «укып әхлак яхшыланасы килгән кешегә мин бу язучының әсәрләрен димлисем киләдер. Руссо, Толстой, Диккенс, В.Гюго кебек адәмнәргә тирән мәхәббәт. Бу язучыларның берсенең әсәрен укып бетергәндә инсан үзендә бер инкыйлаб рухани хис итәдер» дип яза. Моннан С.Максудиның сәясәтче генә түгел, ә чын мәгънәсендә зыялы кеше булганлыгын, дөнья әдәбиятын, урыс әдәбиятын, татар әдәбиятын тирәнтен белүен, тоюын аңларга мөмкин.

С.Максудиның Русия Дәүләт думасы делегациясе составында Англиягә рәсми визит белән баруы аңа алга таба Думада үзенең эшчәнлеген киңрәк җәелдерергә, Русиянең 20 миллионлы хокуксыз мөселман халыкларының хокукларын яклап чыгышлар ясаганда үзенең хаклыгын тирәнтен тоеп, кыюрак булырга мөмкинлек тә биргәндер. Әлеге визиттан соң, ягъни 1910 елның сентябрь аенда ул сайлау хокукларыннан мәхрүм ителгән, мәдәниятсез кавем дип хисапланып Дәүләт думасына депутатлар сайлаудан читләштерелгән Төркестан мөселманнары белән очрашу өчен Коканд шәһәренә бара, Сәмәркандта була. Ул әлеге сәфәре вакытында «Англиягә сәяхәт» китабында урын алачак фикерләрен дә әйткәндер: «Иң мөһим хокук һәр мәмләкәттә дә сайлау хокукыдыр. Бу — иң мөһим мәсьәләдер. Бу хокукны алган кешегә башка хокукларны алыр өчен ишек киң булып ачыладыр. Еламаган балага сөт бирмәгән кебек, сорамаган кешегә дә хокук бирмиләр. Сорагач та әле тиз генә бирмиләр. Гайрәт вә үзеңнең хокукыңның мөкатдәслегенә, газизлегенә тирән бер иман лазем. Үзенең теләгәненә үзе ышанмаган кеше инсан түгел кеби, үзенең мөтлабаларына [illegible] бер ышану белән ышанмаган милләтләр дә [illegible] түгелдер. Французлар, инсан үзенең язмышының тимерчесе булырга тиеш диләр. Хәрәкәтсез, гамәлсез ходайдан ялваручылардан, кулын баглап ялкау зарланучылардан да мескен кеше юк».

С.Максудиның Русия Дәүләт думасы делегациясе белән Англиягә булган визиты, анда сөйләгән нотыклары, француз парламенты делегациясен Петербургтан Мәскәүгә озата баруы, 1910 елда Англия парламенты делегациясен кабул иткән мәҗлестә катнашуы һәм чыгыш ясавы Дәүләт думасының Пуришкевич, Гучков кебек шовинистларында ризасызлык тудырса, Казан миссионерларын бөтенләй чыгырдан чыгара. «Казанский телеграф» гәзите исә: «Без мөселманнарга ирек бирдек, әгәр аларга шуның кадәр ирек бирелмәгән булса, бу мөселман хәзер Дума мөнбәренә чыгып «Без бар һәм булачакбыз!» дип кычкыра алмас иде» дип язып чыга.

Фәридә ГАФФАРОВА,
Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре

Фәрит ЯХИН

ИСЛАМ ДИНЕНЕҢ ТӨП НИГЕЗЛӘРЕ БӘЯНЕ

(Дәвамы. Башы 15 — 17 нче саннарда).

Төквин. Аллаһы Тәгалә бар итүче, терелтүче, ризык бирүче, үтерүче, ягъни бәндәләргә вә башка затларга үлем тынычлыгы бирүче зат. Бу эшләр барысы да Аллаһы Тәгаләнең теләге белән башкарыла, шунлыктан безнең язмышлар аның кулында. Бер бәндәнең икенчесен үтерүе кебек гонаһ эш исә Аллаһы Тәгаләгә каршы кул күтәрү. Аның белән ярышырга теләү билгесе буларак аңлатыла һәм шундый хәрам гамәлләр рәтенә керә дә. Аллаһы Тәгалә бар кыла, әмма адәм балалары кебек түгел, бәлки, Үзенә хас рәвештә. Аллаһы Тәгалә ризык бирә, әмма кешеләр яки башка затлар кебек пешереп яки өзеп алып, яисә башкача иттереп түгел, бәлки, туфракта, суда, башка урында ризыкларны хасил кылырга, алардан тукланырга мөмкинлек тудыра. Әгәр дә Аллаһы Тәгалә ризык бирмәсә, бәндәләр туклык тапмас, ачлык заманнары ирешер иде. Моны белеп торырга кирәк. Аллаһы Тәгалә бәндәләрне йөртүче дә, хәрәкәтләндерүче дә. Әгәр дә Ул булмаса, без дә булмас идек. Аның барлыгына без үзебез дәлил. «Иннә Аллаһа һуар-раззаку», ягъни, хакыйкатьтә Аллаһы Тәгалә ризык бирүче. Кешенең ризыгы бетмичә торып, аның әҗәле дә килми. Берәү икенчесенең ризыгын ашый алмас, гыйбадәт белән ризык күбәймәс яки мескенлек белән артык калмас, гонаһ эшләүдән азаймас. Барчаларның ризыгы һәм гомере алдан ук билгеләнеп куелган булыр. Әмма монда бер сер бар: әгәр дә кылган гамәлләрең изге икән, ул вакытта ризыгыңның да бәрәкәте күп булыр, мәгәрем ки, эшләгән эшләрең яманлык икән, ул вакытта ризыгыгызның да бәрәкәте юктыр. Шул сәбәпле, әгәр дә ризыгыңның бәрәкәтен табасыгыз килсә, яшәгән гомерегез заяга үтмәсен дисәгез, ул вакытта гамәлләрегез дә изгелектә булсын. Кешегә кылган җәбер-золымыгыз коннәрнең берсендә үзегезгә үк авырлык китерер, башкаларга күрсәткән яхшылыкларыгыз исә савап вә рәхмәт рәвешен табар, гомерегез бәхетле көннәр эчендә үтәр. Болар түгелме Аллаһы Тәгаләнең берлеген вә барлыгын дәлилләүче сүзләр? Иманыгыз камил вә ныклы булсын! Мәгәрем ки, шулай икән, сезнең һәрвакыт терәгегез — Аллаһы Тәгалә!

Шәригать дәлилләре

Без күп тапкырлар ишеткән һәм сөйләгән шәригатебез нигезләре нәрсәләр соң? Алар ничәү? Шәригатьнең дәлилләре дүртәү, алар — китап, сөннәт, әҗмагу өммәт, кыйас фикъһа. Китап дип әйткән вакытта Коръәне шәриф күз алдында тотыла, ягъни мөселманнар үзләренең йола-гамәлләрендә Аллаһы Тәгалә сүзе — Коръән өйрәтмәләренә таянып эш йөртергә тиеш. Сөннәт дигән вакытта тагын да өч нәрсә игътибарда тотыла: пәйгамбәребезнең әйткән сүзләре, кылган фигыль-гамәлләре, аның тәкрарлары. Пәйгамбәр әйткән сүзләр аерым рәвештә хәдисләр дип йөртелә. Фигыль-гамәлләре исә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең белеп эшләгәннәре, ягъни ул теге яки бу гамәлне шиксез башкарган икән, димәк, мөселманнар өчен шушы эшләре үрнәк санала, һәммә кешеләргә дә шулай эшләү гонаһ түгел. Тәкрарлар исә, Мөхәммәд пәйгамбәр теге-бу бәндәнең эшләвен күреп торып та, аны туктатып, нигә алай эшлисең, дип кисәтмәве, хуплавы яки кире кагуы. Әҗмагу өммәт дигән вакытта ислам галимнәренең, мөселманнарның һәммәсе дә бер фикергә килеп, теге яки бу гамәлнең асылда хәрам түгеллеген дәлилләр белән ачыклап, җыен корып кабул итүләрен әйтәләр. Алар әгәр дә уртак фикергә киләләр икән, димәк, бу канун да шәригатькә кертелә вә дөрес дип табыла. Кабул ителгән ул канунны бозмау өммәттән таләп ителә. Бу канунга нигезләнеп алга таба җәмгыятьтә хөкем тоту, хөкем йөртү шулай ук дөрес эшләрдән санала. Кыйас фикъһа дигән вакытта, мөҗтәһидләрнең, ягъни дин галимнәренең моңа кадәр булмаган эшнең ни-нәрсә икәнлеген ачыклап, башка кануннарга туры китереп, аларның тәңгәллеген ачыклаганнан соң, бу эш дөресме-түгелме икәнлеген төшенеп, аны канунлаштырулары атала. Мәсәлән, Хаҗга самолетка-очкычка утырып бару дөресме-түгелме дигәндә пәйгамбәрләребезнең гамәлләреннән булган эше исәпкә алына, ул исә дөягә утырып барган. Димәк, самолетта бару да хәрам түгел.

Балигълык яшенә җиткән бәндәләрнең гамәлләре

Адәм балалары бер-берсеннән бары тик балигълык яшенә җитү-җитмәүләре белән генә аерыла. Кемнәр әлегә балигъ түгел, алардан зур вә җитди эшләрне артыгы белән таләп итү дөрес эш түгел. Аларны, икенче төрле, сабыйлар, үсмерләр дип йөртәләр. Акыл ягыннан нинди генә камиллеккә ирешмәсеннәр, алардан мәҗбүри рәвештә иман китерүне таләп итү, биш вакыт намаз укыту, хаҗ, зәкят, уразаны үтәтү дөрес түгел. Чөнки Аллаһы Тәгалә каршында да, өммәт каршында да, олуглар вә түрәләр алдында да сабый баланың, әгәр дә ул кешелексезлек күрсәтмәсә, көчләмәсә, кимсетмәсә, гонаһы юк. Балигъ булмаган кеше белән балигълык дәрәҗәсенә ирешкән, балигълык яшеннән үткән бәндәләр арасында, алар каршына куелган таләпләр ягыннан чыгып караганда, аермалар шактый күп. Алар шәригать каршында да, өммәт алдында да бар. Сабый бала эшен аңламыйча кылырга мөмкин, аның күңел күзе әлегә «йокламаган» санала. Балигълык яшенә ирешмичә торып, ул баладан дингә керү таләп ителсә, бу эштә зур гонаһ бар. Христиан-носарилар сабый балаларны үз рөхсәтләреннән башка чукындырып, гонаһлы гына булалар. Тарихлардан билгеле, әчке Русия мөселманнарының сабый балалары шул рәвешле үтә мәсхәрә кылынганнар, падишаһлар әмере белән чукындырылганнар. Бу — аларның мөселманнар доньясы каршында гафу ителмәслек гамәлләре иде! Шулай итеп, балигълык яшенә ирешмәгән баладан дин таләп итү дәрес эшләрдән саналмавы аңлашылып тора. Әмма бу әле алар дини йола вә тәртипләргә өйрәнә тормасыннар дигән сүз түгел. Дини йола-гадәтләргә өйрәтү эше аларның тәрбиячеләренә, ата-ана, әби-бабаларына йөкләнелә.

Балигълык яшенә ирешкән ир балага шәригатькә «мөкәлләф» дип әйтәләр. Мәгәрем ки хатын-кыз икән, «мөкәлләфә» диләр. Шушы рәвешле атау өчен, балигълык яшенә ирешүдән тыш, тагын бер сәбәп бар, ул да булса, моның өчен аның акыллы булуы, ягъни акылга камиллегә таләп ителә. Әгәр дә кеше дивана яки мәҗнүн икән, ул шулай ук балигълык яшенә ирешмәгән, камиллек тапмаган, мөкәлләф булмаган кеше хисаплана. Алар урталыкта да дип исәпләнми. Балигъ затлардан соралган гамәлләр болардан таләп ителми.

Балигълык яшенә ирешкән бәндәләрнең эшли торган эшләре, ягъни гамәлләре, шәригать өйрәтмәләре буенча, сигез төргә аерылып йөртелә. Болар: фарыз, ваҗип, сөннәт, мөстәхип, мөбах, хәрам, мәкруһ, мөфәссәд.

Әгәр дә бер бәндә балигълык яшенә ирешеп, акылы камил, ягъни дивана түгел икән, ир-ат яки хатын-кыз булуына карамастан, ул менә шушы сигез нәрсәне яхшы белергә тиешле һәм аларга таянып гамәл йөртергә бурычлы (әгәр дә үзен мөселман дип исәпләсә). Диваналыкта шикле бәндәләрне мулла итеп танымаслар, эш вә гамәлдә аларга иярмәсләр, аларны нинди яшькә җитүләренә карамастан, һаман да сабыйлар рәтендә күрерләр, әмма мохтаҗлыгына ярдәм итү, аңа киң күңеллелек күрсәтү дөрес булыр.

Фарыз

Фарыз гамәл дип Аллаһы Тәгалә тарафыннан бәндәләргә әмер ителгән, шиксез рәвештә эшләнергә тиешле, дәлилле гамәлләргә әйтәләр. Фарыз гамәлләр үз чиратларында тагын да өч төрлегә бүленә. Беренчесе — фарыз даим. Мондый гамәлләр һичкайчан ташланмыйлар вә үзгәрмиләр, һәрдаим вә һәр җирдә үз тәртипләре белән кылыналар. Һәрвакыт фарыз булган нәрсә — иман, ягъни бәндәләр һәрдаим инанып, шул инанырга тиешле нәрсәләрдән баш тартмаска, иманда камил калырга, шиккә төшмәскә тиеш. Алай гына да түгел, әгәр да инанасың икән, ул инанган нәрсәләргә һәрдаим таянырга да тиешсең.

Моның өчен «Әмәнтү билләһи...»не ахырына кадәр укып, шуңа таянып эш йөртү сорала. Бәндәләргә ачык билгеле булырга тиешле, ирләргә һәм хатыннарга йөкләнгән иң ачык билгеле, шиксез гамәл, төп фарыз менә шушы, ягъни иман. Әгәр дә иманы юк икән, бәндә аңа таянмыйча эшкә керештеме, иманын оныттымы, ул кеше мөселман дип атала алмый. Иман һәрдаим күңел түрендә булырга тиешле. Аны икенче төрле «фарыз гайн» дип тә йөртәләр. «Фарыз гайн» ул шундый нәрсә ки, бер кеше эшләп, икенче кешедән бу бурыч төшми. Аны һәркем белергә һәм башкарырга тиешле. Мин бу тиешле эшне үти алмыйм, минем өчен син башкар, дию белән ул бәндәгә иман керми, аның белән ул мөселман саналмый. Бу фарыз бер кешедән икенчесенә йөкләнми вә күчми, бәлки һәркемнең үзе белән вә үзендә булырга тиешле. Иманның олуглыгы да шунда.

Икенче фарыз гамәлләрне төркемләп «фарыз мүвәккать» дип йөртеләләр. Мондый фарыз гамәлләр билгеле бер вакыт җитү белән эшләнелә, шул вакыт үтү белән (әгәр дә вакытында кылынса!) өстән төшерелә. Бу фарыз мүвәккать дигәне шулай ук фарыз гайн тәртибендә карала, ягъни бу фарызны үзең өчен башкалардан таләп итү белән, үзең үтәми торып, өстеңнән төшерелми. Болар — биш вакыт намаз уку, ураза (руза) тоту, байлыгың бар икән, зәкят тапшыру һәм дә, көчең җиткәндә, хаҗ кылу.

Өченче төр фарыз гамәлләр фарыз кифая (кифайә) дип төркемләнә. Фарыз кифайә булган вакытта, бер кеше тарафыннан ул төр фарызлар үтәлә икән, башкаларның өстеннән ул төр фарызлар төшә. Болар, мәсәлән, җеназа намазы уку (берәү укый, башкалар тыңлап тора, шул рәвешле өсләреннән төшә), сәлам алу. Сәлам алган вакытта, мәсәлән, дүрт-биш кеше җыелышып утырганнар икән, алар янына килеп берәү сәлам бирсә, алар барысы да кайтарып сәлам тапшырырга тиешле, бу эш — фарыз. Әмма алар арасыннан сәламне берәү кабул итеп алса, ул вакытта бу фарыз башкаларның өстеннән дә төшәр. Инде дә берсе дә сәлам кайтармаса, фарыз гамәл өсләреннән төшмәс.

Фарыз гамәлләрнең хикмәте шунда ки, әгәр дә аны ташласаң, сиңа бик каты газап ирешә, әгәр дә шик белдерсәң, фарыз түгел дип исбатларга тырышсаң, диннән чыккан дип саналасың, ә инде үтәп барасың икән, ул вакытта бу гамәлләрең үзеңә үк савап буларак кайтарыла.

Һәр фарыз гамәл эчендә биш фарыз бар. Алар — аның фарыз гамәл икәнлеген белергә тиешлек, белү белән бергә эшләнүе-кылынуы фарыз, микъдары фарыз, инануы фарыз, ихлас күңел бирүе фарыз. Әгәр дә аңсыз рәвештә, мәсәлән, курку-куркыту белән башкарыла икән, ул вакытта фарыз эчендәге биш фарызның тәгәл түгеллеге беленә, шуның белән ихласлыгына шик төшә, гамәле дөрес булып бетми.

Димәк, фарыз гамәл икән, аны кылырга тиешлегеңә һичбер шигеңне калдырмыйча ихлас күңел биреп, инану белән башкару мөслихәт.

Ваҗип

Ваҗип гамәлләр дип Аллаһы Тәгалә һәм аның пәйгамбәре Мөхәммәд галәйһис-сәлам эшләргә кушып та, өмерендә шул нәрсәне кушканы шикле икәнлеге, шөбһәле булганы тәгаен дип уйланган гамәлләргә әйтәләр. Мәсәлән, бәйрәм намазы уку, корбан чалу, садака бирү һ.б. Болар бәндәләргә йөкләтелгән эшләр саналсалар да, аларны Аллаһы Тәгалә һәм Аның пәйгамбәре кушканлыкта шик, дәлилләрдә камиллек җитмәү аркасында шушы төркем гамәлләргә керәләр.

Ваҗип гамәлләрне башкарган бәндәләргә, ваҗипнең хөкеме буенча, савап ирешер, әгәр дә үтәмисең икән, газап бирелер, шик белдереп, бәхәс кыласың икән, ул вакытта диннән чыкмассың, мөселманлыгың сакланыр.

Һәр ваҗип эчендә тагын да дүрт төрле ваҗип бар. Дүрт ваҗип өстенә тагын да һәр ваҗиптә бер фарыз бар — ихлас булу. Әгәр дә соралганлыгы өчен генә башкарылып та, ул гамәлләр ихлас күңелдән үтәлмиләр икән, ул вакытта бу кылган нәрсәләр икейөзлелек була. Бу исә — хәрам. Гамәлдә һичкайчан икейөзлеләнергә ярамый, чөнки эшең савап булып кайтмый, газапка әверелә. Шунлыктан чын күңелдән инанып башкарганда гына камиллеккә ирешергә мөмкин.

(Дәвамы бар).

Атналык манзара TV

Дүшәмбе

27 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы 19 15 «Татарстан» 19.45 «Телебуклет» Тапшырулар анонслары 19.55 «Түгәрәк өстәл» Реформалар программасы ул нинди булырга тиеш? 20.25 «Әлли-бәлли-бәү» 20.35 «Татарча сөйләшәбез» 2 нче дәрес 20 50 «Без кем? Без нинди?» (Восток телевидениесе Чистай шәһәре) 21 15 «Мәңгелеккә күперләр» 21 30 «Консерватория сәхнәсендә» Рубин-Абдуллин. 22.00 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7 10 Эфирда музыка. 7.30 «Тамаша залы» 8.00 «ПОСТ» — музыка яңалыклары 8 15 11 05 «Юл патруле» Атналык йомгак 8 30 14 45 «Даруханә» 8.40 «Сул аяктан!» (MTV) 9.20. 12.50 «90х60х90» 9.40 Диск-канал 10.00 «Канун» 10.30 Сериал «Один к десяти» 11 20 Атна фаразлары. 11 50 «Валюта бәясе» 12.00 Сериал: «Мстители» 13.05 Нәфис фильм «Эрик» 15.00 Телесериал «Флиппер» 15.55 «Минем кино» Лидия Федосеева-Шукшина. 16.30 Нәфис фильм «Ромовый бульвар» (Брижит Бардо) 18 45 «Минем тарих» Генри Резник 19.20 «Лариса» яңалыклары 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.20, 23.45 «Шәһәр» информацион программасы. 20.45 «Видеомода» 21 05 Мультфильм «Старуха, дверь закрой» 21 15 Телеэкспресс. 21.35 «Криминаль хроника тележурналы» 22.05 Нәфис фильм: «Девушка моей мечты» 0.10 Телесериал: «Особое подразделение» 1 нче фильм «Привычка жертвы»

1 НЧЕ КАНАЛ

Иртә: 6.00, 6.30. 7 00. 7 30, 8.00 «Көн хроникасы. Һава торышы» 6.05, 7 05, 8.05 Спорт яңалыклары. 6 10 «Иртәнге физик күнегүләр» 7 10 Мультфильм. 7.20 «Матбугат темe» 7.40 Сәламәтлек моритонингы. 7.50 «Монетный двор». 8 10 «Иртә» кунагы
8.30, 19.05 «Сайлаулар-95» 9.00. 12.00, 15.00, 18.00, 0.00 «Яңалыклар» 9 15 Телесериал: «Тропиканка» 10.00 «Нәрсә? Кайда? Кайчан?» 11 10 Мультфильм «Дядюшка Ау» 11.30 Телеуен: «Көен таны» 12.10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 12.50 Нәфис фильм: «Собака на сене» 1 нче серия 14.00 Сериал: «Тридцать случаев майора Земана» 15.20 Мультсериал: «Виджит спешит на помощь» 15.40 «Марафон-15». 16.00 «Йолдызлар сәгате» 16.35 Яшьләр сериалы: «Элен и ребята» 17.00 «Джем». 17 30, 0.10, 0.40 «Спортның җиде көне» 18.20 Телесериал: «Тропиканка» 19.35 Телеуен: «Көен таны» 20.00 «Әгәр...» В.Познерның авторлык программасы. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21.00 «Вакыт» 21.50 Фантастик детектив: «Электронные жучки-9» «Надежда на успех» 22.50 Э.Радзинский «Тарих табышмаклары. Иоанн Мучитель» 2 нче кисәк. 23.35 Музыкаль программа. «Йолдыз» милли бүлеге тәкъдим итә...»

«РУСИЯ»

7.30 Эшлекле кешеләр вакыты 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр» 8.25 «Кирәк, кирәк...» 8.30 «Йолдызлар сөйли» 8.35 «Ритмика» 8.50 «Барысы да аз-азлап» 9.25 «Телегазета» 9.50, 18.40 «Сайлаулар-95» Дәүләт Думасы. 10.00 «Без әле исән..» 10.40 Мульти-пульти. «Ай-ай-ай» 10.50 «Мөһим мизгел» 11 20 Милиция хроникасы. 11.30 Безнең хәбәрчедән. «Язмышлар» 5 нче фильм 11 45 Мульти-пульти: «Приключения капитана Врунгеля» 12.05 Клип-антракт А.Губин Линда 12 15 «Яңа тармак» (Төмән) 12.30, 14.20 «Эшлекле Русия» 16.05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.20 «Көн дә бәйрәм» 16.30 «Могҗизаларга ярты сәгать» 17 20 «Яңа тармак» «Бәлки..» 17 45 «Коткару-911» 19 10 «Сайлаучылар клубы» 19.15 «Высокая мода» Мәскәүдә» Фестиваль көнделеге 19 25 «Сабый авызыннан» 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 «Дүшәмбе саен детектив» «Инспектор Морс» сериалыннан нәфис фильм. «Почти безнадежное дело» (Бөекбритания) 2 нче кисәк 21 45 Репортер. 22.05 «Хакыйкать мизгеле» 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40 «299-00-00» хезмәте 23.55 «Шәхси коллекция» 0.25 Төнге телесериал Нәфис фильм: «Гонка за жизнью» (Италия) 3 нче серия 1 15-1 45 Джаз-клуб Э Комон 1 нче тапшыру

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

12 40 «Кунак» 13 00, 22 45 ТВ мәгълүматлары 13 10 «Яшәү стиле» 13.25 «Музыка мизгеле» 13 30 ТВ мәгълүматлары Немец дулкыны 13 45 Мультфильм «Песня» 14.00 «Ашыгыч ярдәм» 14.35 Телефильм. «Мануэла» 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр» 15.30, 15 37 «Музыка мизгеле»
Тәнәфес
17 30 ТВ мәгълүматлары Европа калейдоскобы 18.00, 21 00 «Сайлаулар-95»
22.05 Н Мордюкова юбилеена «Актриса тәүбәсе» 23 00 «Спорт, спорт спорт...» 23 15 Оппозиция күзлегеннән караганда президент А.Лукашенконың портреты 23 30 Музыкаль шоу «Телекомпакт».

Сишәмбе

28 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы 19 15 «Татарстан» 19.45 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 19 50 «Әлли-бәлли-бәү» 20.00 «Турыдан-туры элемтә» Телевизор караучылар сорауларына Татарстан Республикасының хокук саклау органнары җитәкчеләре җавап бирә 21 00 «Татарча сөйләшәбез» 21 15 «Пульс» Медицина программасы 21 30 «Мин тормышка гашыйк» Фәнис Яруллин турында документаль фильм («Татнефть» студиясе) 21 50 «Ял сәгатендә» 22.20 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7 10 «Эфирда музыка» 7.30 20 20 23 20 «Шәһәр» информацион программасы 7 55 Телеэкспресс (27 ноябрь тапшыруын кабатлау) 8 15. 11 05 «Юл патруле» 8.30 14 45 «Даруханә» 8 40 «Сул аяктан!» 9.20. 12.55 «90х60х90» 9 40 «Диск-канал» 10.00 «Минем кино» Лидия Федосеева-Шукшина 10 40 Юмористик сериал «Один к десяти» 11 20 «Атна һәпакәтләре» 11.50 «Валюта бәясе» 12.00 Сериал «Спасатели Малибу» 13 10 Нәфис фильм «Странные люди» 15.00 «Музыка һәм матбугат» «Каләм осталары» Борис Зосимов 16.05 «Кинескоп» киноканалы 18.25 «ПОСТ — музыка яңалыклары» 18 40 Сериал «Против течения» 19.30 «Ундүртенче каттан караганда» 19 50 «Кыюлар һәм матурлар» 20 45 «Коммерция өйләнмәсе» 21 05 Мультфильм «Укрощение велосипеда» 21 15 Телеэкспресс 21 35 Русия киносы көне Нәфис фильм «Подмосковные вечера» 23.45 TAP RECORDS коллекциясеннән «Панк»

1 НЧЕ КАНАЛ

Иртә: 6.00, 6.30, 7.00, 7.30, 8.00 «Көн хроникасы Һава торышы» 6.05, 7 05, 8.05 Спорт яңалыклары 6.10 «Иртәнге физик күнегүләр» 7 10 Мультфильм 7 15 Яшьләр өчен яңалыклар. 7.20 «Матбугат темe» 7.40 «Шанс» 7 50 «Монетный двор» 8.10 «Зәңгәр ут»
8.30, 19.05 «Сайлаулар-95» 9.00. 12.00 15.00, 18.00, 0.00 «Яңалыклар» 9.15 Телесериал: «Тропиканка» 10.00 «Әгәр...» В.Познер алып бара 10 45 «Көлкеле манзара» Е.Петросян алып бара. 11 15 Мультфильм «Данило и Ненила» 11.30 Телеуен «Көен таны» 12.10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары 12.50 Нәфис фильм «Собака на сене» 2 нче серия 14.00 Сериал. «Тридцать случаев майора Земана» 15.20 Мультсериал. «Виджит спешит на помощь» 15.40 «Веселая квампания» кварьетесы 15.50 «Мультитроллия» 16 10 «Тылсымлы дөнья, яки Синема» 16.35 Яшьләр өчен сериал «Элен и ребята» (Франция) 17.00 «.. 16 яшькәчә һәм өлкәнрәкләр өчен тапшыру» 17 30, 1.50 «Спортның җиде көне» 18.20 Телесериал: «Тропиканка» 19.35 Телеуен «Көен таны» 20.00 «Тема» 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21.00 «Вакыт» 21.50 Леонид Куравлев Василий Шукшинның «Живет такой парень» фильмында. 23.35 «Мәскәү-Кремль» 23.50, 0 10 Телешоу «50х50» 1 00 Сериал «Твин Пикс»
Төнге канал
2.20 3.00 Музыкаль программа «Шәмәхә томан»

«РУСИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8.00. 11.00 14.00, 17 00. 20.00, 23.00 «Хәбәрләр» 8.25 «Кирәк, кирәк..» 8.30 «Йолдызлар сөйли» 8.35 «Ритмика» 8.50 «Барысы да аз-азлап» 9 30, 18 40 «Сайлаулар-95» Дәүләт Думасы 10.05 «Телегазета» 10 10 Документаль фильм «Константин Симонов. остаюсь военным писателем» 10.30 «...беләһ хәбәрләшүдән сайланмалар» 11.20 «Милиция хроникасы» 11 30 Безнең хәбәрчедән «Язмышлар» 6 нчы фильм 11 45 Клип-антракт «Черный, белый» дуэты. 11.50, 17 50 Мультсериал. «Камень сновидений» 12.15 «Яңа тармак» 12.30, 14 20 «Эшлекле Русия» 16 05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.20 «РОСТ» компасы» 16.50 «Ай тотучы» 17 20 «Яңа тармак» (Самара) 18 15 «Сезнең партнер» 18.30 «Сайлаучылар клубы» 19 10 «L» клубы 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 Юбиляр фильмотекасыннан Н Мордюкова «Женитьба Бальзаминова» фильмында 22 10 «Киноафиша» 22.30 «Әйдәп баручы фаразы» 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40 «299-00-00» хезмәте 23.55 «Карьера» 0.25 «Криминаль хәбәрләр экраны» 0.35 Төнге телесериал «Гонка за жизнью» (Италия) 4 нче серия 1 30-2 00 Джаз-клуб Э Комон 2 нче тапшыру

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

12.30 Фильм-балет «В Мосса» (Франция) 13.00, 22.45 ТВ мәгълүматлары 13 10 «Яшәү стиле» 13 25, 15.30 «Музыка мизгеле» 13 30 ТВ мәгълүматлары Немец дулкыны 13.45 Мультфильм «Мудрость бедной девушки» 14.00 «Ашыгыч ярдәм» 14.30 Телефильм «Мануэла» 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр» 17 50 «Бөтен Русия буйлап» 18.00, 21 00 «Сайлаулар-95» 18,40 Ленинград өлкәсе телекомпаниясе күрсәтә
22.00 Футбол Токиодан кыйтгаара кубок финалы. «Аякс» (Голландия) — «Гремио» (Бразилия) Тәнәфестә (22 45) — ТВ мәгълүматлары 23.45 Нәфис фильм «Долгой жизни сеньоре» (Италия)

Чәршәмбе

29 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7 00—8.00 «Чулпан» информацион программасы 19 20 «Татарстан» 19 50 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 20 00 «Әлли-бәлли-бәү» 20 05 «Сайлауларны каршылап» 20.35 «Татарча сөйләшәбез» 20 50 Телесериал премьерасы «Вспышка» 4 нче серия 22.20 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7 00 «Зарядкага басыгыз!» 7 10 «Эфирда музыка» 7 30 20 20 0 50 «Шәһәр» информацион программасы 7 55 Телеэкспресс (28 ноябрь тапшыруын кабатлау) 8 15 11 05 16 35 «Юл патруле» 8.30 14 50 «Даруханә» 8.40 «Сул аяктан!» 9 20 12 50 «90х60х90» 9 40 «Диск-канал» 10 00 «Минем тарих» Генри Резник 10 40 Юмористик сериал «Один к десяти» 11 20 15 20 «Атна чизагпары» 11 50 «Валюта бәясе» 12 00 Детектив сериал «Ночная жара» 13.05 Нәфис фильм «Лекарство от любви» 15 00 «Тегеләр кемнәр» 15.50 А.Политковский программасы «Новосибирскидан хат» 16.20 «ПОСТ — музыка яңалыклары» 16 50 «Диск-канал 17 35 Тележурнал «Планета кайтавазы» 18.05 Мультфильм «Конек-горбунок» 19 20 «Поза» 19 50 «Кыюлар һәм матурлар» 20 45 «Казан автосалоны» 21 15 Телеэкспресс 21 35 «Үз кешеләр» 22 10 Нәфис фильм «Любовь, любовь, любовь» (Һиндстан)

1 НЧЕ КАНАЛ

Иртә 6.00. 6.30. 7 00. 7 30. 8.00 «Көн хроникасы. Һава торышы» 6.05 7 05 8 05 Спорт яңалыклары 6.10 «Иртәнге физик күнегүләр» 7 10 Мультфильм 7 20 «Матбугат темe» 7 40 «Досье» 7 50 «Монетный двор» 8.10 «Стиль»
8.30, 19 05 «Сайлаулар-95» 9.00 12.00, 15.00, 18 00. 0.00 «Яңалыклар» 9 15 Телесериал «Тропиканка» 10 00 «Тема» 10 45 «Хайваннар дөньясында» 11 20 Мультфильм «Капля» 11 30 Телеуен «Көен таны» 12 10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары «Үзара бәйләнеш — Бердәмлек илләренең эшлекле хезмәттәшлеге» 12.50 Нәфис фильм «Артистка из Грибова» 1 нче серия 14 00 Сериал «Тридцать случаев майора Земана» 15 20 Мультсериал «Виджит спешит на помощь» 15 40 «Кактус һәм К» 15.50 «Күңелле ноталар» 16 10 «Джунглилар чакыруы» 16.35 Яшьләр өчен сериал «Элен и ребята» (Франция) 17 00 Тет-а-тет 17 30, 1 55 «Спортның җиде көне» 18.20 Телесериал: «Тропиканка» 19 35 Телеуен: «Көен таны» 20 00 «Арбат парламенты» Кушыл!» 2 нче тапшыру 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21 00 «Вакыт» 21 50 Нонна Мордюкова «Комиссар» фильмында. 0.10 «Матбугат клубы» 1 05 Сериал «Твин Пикс»
Төнге канал
2.25, 3.00 «Барлык йолдызлар» кабаресы

«РУСИЯ»

7 30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8.00, 11 00, 14.00 17 00 20 00 23.00 «Хәбәрләр» 8.25 «Кирәк, кирәк» 8.30 «Йолдызлар сөйли» 8.35 «Ритмика» 8 50 «Барысы да аз-азлап» 9 10 «Крестьян мәсьәләсе» 9.30, 18.40 «Сайлаулар-95» Дәүләт Думасы 10.00 «Телегазета» 10 05 Телесериал «Санта-Барбара» 11 20 «Гадәттән тыш канал» «Яшибез һәм яратабыз» 11 30 «Популяр булмаган тема» 11 45 Клип-антракт Е.Амирамов 11 50. 17 50 Мультсериал «Камень сновидений» 12 15 «Яңа тармак» 12 30. 14.20 «Эшлекле Русия» 16.05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.20 «Көн дә бәйрәм» 16.30 «Кайсы як?» 17 20 «Яңа тармак» «Ерак Көнчыгыш» 18.15 Кипрас Мажейка «Янәшәләр» 18.25 «Сезнең партнер» 19 15 «Сайлаучылар клубы» 19.25 «Үз уены» 20 25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 Телесериал «Санта-Барбара» 21 35 Михаил Боярский «Домино»сы 22 10 «Гадәттән тыш канал» 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23 40 «299-00-00» хезмәте 23.55 Клублар командалары арасында баскетбол буенча Европа чемпионаты. ЦСКА — «Ираклис» (Салоники, Греция) 0.40-2.34 Киномарафон Нәфис фильм «Гекката» (Швейцария-Франция)

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

12 40 «Кунак» 13 00. 22 45 ТВ мәгълүматлары 13 10 «Яшәү стиле» 13 25. 15 35, 18.40 «Музыка мизгеле» 13.30 ТВ мәгълүматлары Немец дулкыны 13 45 Табиблар фармацевтлар һәм пациентлар өчен тапшыру «Рецепт» 14 00 «Ашыгыч ярдәм» 14 35 Телефильм «Мануэла» 15 25 «Бакчачыларга киңәшләр» 17 10 «Паутиныч яшәгән җирдә» 17 30 «Нәни йолдызлар-95» 18 00, 21 00 «Сайлаулар-95» 18 45 Телеуен-лотерея «Уңышның алты кыры» 19 05 «Телекибет». 19 10 «Зур фестиваль»
22 05 «Блеф-клуб» 23 00 «Спорт спорт спорт » 23 15 Юмористик программа «Золотой телец»

Пәнҗешәмбе

30 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7 30—8 00 «Чулпан» информацион программасы 19 20 «Татарстан» 19 50 «ГАИ мәгълүматлары» 20 00 «Әлли-бәлли-бәү» 20 10 «Сайлауларны каршылап» 20 40 «Татарча сөйләшәбез» 20 55 Лена Бичарина җырлый 21 05 Нәфис фильм «Дама с собачкой» Режиссер И Хейфиц. 22 20 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7 00 «Зарядкага басыгыз!» 7 10 17 30 «Эфирда музыка» 7 30 20 20 0 10 «Шәһәр» информацион программасы 7 55. Телеэкспресс (29 ноябрь тапшыруын кабатлау) 8 15 11 05 «Юл патруле» 8 30 14 45 «Даруханә» 8 40 «Сул аяктан!» 9 20 12 50 «90х60х90» 9 40 «Диск-канал» 10 00 А Политковский программасы «Новосибирскидан хат» 10 40 Юмористик сериал «Один к десяти» 11 20 «Нью-Йорк Нью-Йорк» 11 50 «Валюта бәясе» 12.00 Телесериал «Ночная жара» 13 05 16 00 Нәфис фильм «С тех пор как мы вместе» 15 00 Ток-шоу «Мин үзем» «Котелмәгән аерылышу» 17 40 «Ушуайя» 18.00 «Computerlife» 18 30 «Кыюлар һәм матурлар» 19 00 «Заречье» банкы мәгълүмат бирә 19 10 «Турыдан-туры элемтә» Студиядә Казан мэры К Исхаков «Торак һәм коммуналь хезмәтләр» темасы 20 45 «Коммерция өйләнмәсе» 21 05 «Казанские ведомости» нәрсә турында язды» 21 15 «Телеэкспресс» 21 35 «Бары тик кызык өчен генә» 22.05 Атна фильмы Нәфис фильм «Дилетантка» (Франция-АКШ)

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 Иртә 6.00 6 30 7 00 7 30 8 00 — «Көн хроникасы. Һава торышы» 6 05 7 05 8 05 — «Спорт яңалыклары» 6 10 «Иртәнге физик күнегүләр» 7 10 Мультфильм 7 15 «Яшьләр өчен яңалыклар» 7 20 «Матбугат темe» 7 50 «Монетный двор» 8 10 «Ел буе яшелчә бакчасы»
8.30. 19 05 — «Сайлау-95» 9 00 12 00 15 00 18 00. 0.00 — «Яңалыклар» 9 15 Телесериал «Тропиканка» 10 00 «Арбат парламенты» Кушыл!» 2 нче тапшыру 10 45 «Сәяхәтчеләр клубы» 11 30 Мультфильм «Страшней Бояки зверя нет» 12 10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары 12 50 «Артистка из Грибова» 2 нче серия 14 00 Сериал «30 случаев майора Земана» 15 20 Мультсериал «Виджит спешит на помощь» 15 40 «Лего-го» 16 10 «Яңа чынбарлык» 16 35 Яшьләр өчен сериал «Элен и ребята» 17 00 «Рок-дәрес» 17 30. 1 45 — «Спортның җиде көне» 18 20 Телесериал «Тропиканка» 19 35 «Лотто-миллион» 20 00 «Хәтерләсеннәр өчен» Н.Гринько П Филатов алып бара 20 45 «Тыныч йокы нәниләр» 21 00 «Вакыт» 21 50 «Пора цветения» фильмында борынгы каргыш серe 0 10 «Музыка күзәтүе» 0.55 Сериал «Твин Пикс»
Төнге канал 2 15, 3 00 — «Хит-парад»

«РУСИЯ»

7 30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8 00 11 00, 14.00, 17 00 20 00 23 00 — «Хәбәрләр» 8.25 «Кирәк кирәк» 8 30 «Йолдызлар сөйли» 8.35 «Ритмика» 8.50 «Барысы да аз-азлап» 9 10 «Крестьян мәсьәләсе» 9 30 18.40 — «Сайлаулар-95» Дәүләт Думасы 10.00 «Телегазета» 10.05 Телесериал «Санта-Барбара» 11 20 «Милиция хроникасы» 11 30 Рәссам Павел Шербаум 11 45 «Клип-антракт» «Фристайл» төркеме 11 50 17 50 — Мультсериал «Камень сновидений» 12 15 «Яңа тармак» 12 30 14 20 — «Эшлекле Русия» 16.05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.20 «Көн дә бәйрәм» 16 30 «Көнгерә» 17 20 «Яңа тармак» (Ханты-Мансийск Түбән Новгород) 18 15 «Алыргамы алмаскамы» 18.25 «Сезнең партнер» Русиянең тимер юллары 19 15 «Сайлаучылар клубы» 19.25 «Урысча караоке» 20 25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 Телесериал «Санта Барбара» 21 35 «Битлек-шоу» 22 15 «К 2» тәкъдим итә Е.Максимова, В Леонтьев һәм О Попцов «Сюжет» программасында 23 30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23 40 «299-00-00» хезмәте 23.55 «Криминаль хәбәрләр экраны» 0.05 Музыкаль программа «Эшләпәдә калыгыз» 0.35 Сәүдә йорты «Ле Монти» 1 05 Нәфис фильм «Сатана»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

12 40 «Кунак» 13 00 22 45 — ТВ мәгълүматлары 13 10 «Яшәү стиле» 13 25 «Музыка мизгеле» 13 30 ТВ мәгълүматлары Немец дулкыны 13.45 Мультфильм «Добро пожаловать!» 14 00 «Ашыгыч ярдәм» 14 35 Телесериал «Мануэла» 15 20 «Бакчачыларга киңәшләр» 15 30 15 38 — «Музыка мизгеле»
Тәнәфес
17 25 Мультфильмнар «Песня» «Мудрость бедной девушки» 17 45 «Бөтен Русия буйлап» 18 00 21 00 — «Сайлаулар-95» 18 40 «Ленинград өлкәсе» телекомпаниясе күрсәтә
22 10 Документаль фильм премьерасы «Курортная зона» 23 00 «Спорт спорт спорт » 23 15 Нәфис фильм «Ультра» (Италия)

ҖОМГА

1 ДЕКАБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7 30 8 00 «Чулпан» информацион программасы 18 20 «Татарстан» 19 50 «Видеоспорт» 20 05 «Әлли бәлли бәү» 20 15 «Татарстан Дәүләт Советында» 20 45 «Татарча сөйләшәбез» 21 00 «Җомга көн кич белән» Альманах 21 35 Татарстан сәнгать осталарының хәйрия концерты 1 нче бүлек 22 55 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7 00 «Зарядкага басыгыз» 7 10 11 45 «Эфирда музыка» 7 30 20 20 23 35 «Шәһәр» информацион программасы 7 55 «Турыдан туры элемта» (30 ноябрьдә язылган) 9 00 «Телеэкспресс» (30 ноябрь тапшыруын кабатлау) 9 20 12 50 «90х60х90» 9 40 «Диск канал» 10 25 «Ресторан рейтингы» 10 40 Юмористик сериал «Один к десяти» 11 50 «Валюта бәясе» 12 00 Детектив сериал «Ночная жара» 13 05 Нәфис фильм «Огненное кольцо» 14 45 «Дарухәнә» 15 00 «Тегеләр кемнәр» 15 20 Сериал «Мелочи жизни» 15 55 «Спорт атнасы» 16 30 «ПОСТ — музыка яңалыклары» 16 45 «Юл патруле» 17 00 «Барысы да рок н ролл» 17 55 «Бүгенге Европа» 18 20 «Суперспорт» 18 40 Нәфис фильм «Корабль любви» 19 30 «Ундүртенче каттан караганда» 19 50 «Кыюлар һәм матурлар» 20 45 «Көннәрнең ямьсезләре булмый» 20 55 «Экология көбәрчесе» 21 00 Мультфильм «Золушка» 21 15 Телеэкспресс 21 35 нәфис фильм «Умереть молодым» 0 00 Джентльмен-шоу 0 30 Өлкәннәр өчен мультфильм «Дикая планета» 1 40 «Эротека Венеры» телепрограммасы

1 НЧЕ КАНАЛ

6 00 Иртә 6 00 6 30 7 00 7 30 8 00 — «Көн хроникасы һава торышы» 6 05 7 05 8 05 — «Спорт яңалыклары» 6 10 «Иртәнге физик күнегүләр» 7 10 Мультфильм 7 20 «Матбугат темә» 7 40 «Гайбәтләр» 7 50 «Монетный двор» 8 10 «Детальләр»
8 30 19 05 — «Сайлау-95» 9 00 12 00 18 00 0 00 — «Яңалыклар» 9 15 Телесериал «Тропиканка» 10 00 «Хәтерләсеннәр өчен» Н Гринько Г Филатов алып бара 10 40 «Уйна гармун» 11 10 Мультфильм «Будь моим слоном» 11 25 «Бар да өйдә чакта» 12 10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары «Җомгадан җомгага Бердәмлек илләреннән кызыклы репортажлар» 13 00 Теннис Дэвис кубогына Финал АКШ һәм Русия җыелма командалары Турыдан туры трансляция 18 20 Телесериал «Тропиканка» 19 40 Г Хазанов «Могҗизалар клубында» 20 45 «Тыныч йокы нәниләр» 21 00 «Вакыт» 21 50 «Защитник Седов» фильмында 30 еллар фаҗигасе 22 40 «Караш» 23 40 Спорт программасы «Трасса» 0 10 «Твин Пикс» Огонь иди со мной» Төнге канал 2 30 «Хит конвейер» 3 00-4 10 «Дульсинея Тобосская» 1 нче серия

«РУСИЯ»

7 30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8 00 11 00 14 00 17 00 20 00 23 00 — «Хәбәрләр» 8 25 «Кирәк кирәк» 8 30 «Йолдызлар сөйли» 8 35 «Ритмика» 8 50 «Музыкаль экспромт» 9 10 «Крестьян мәсьәләсе» 9 30 18 40 «Сайлаулар-95» Дәүләт Думасы 10 05 «Телегазета» 10 10 Документаль фильм «Без наследника» 10 50 «Мөһим мизгел» 11 20 «Милиция хроникасы» 11 45 Мульти-пульти «Приключения капитана Врунгеля» 12 15 «Яңа тармак» 12 30 14 20 — «Эшлекле Русия» 16 05 «Шау-шулы яңалыклар» 16 20 «Көн дә бәйрәм» 16 30 «Озынайтылган көн» 16 50 «Ай тотучы» 17 20 «Сезнең хокук» 17 35 «Җомга саен Дисней» Нәфис фильм «Зорро» 35 нче 36 нчы серияләр 18 35 «Беркем дә онытылмаган» 19 15 «Сайлаучылар клубы» 19 25 Вертикаль «Хөкүмәтнең эш көннәре» 20 25 «Бәйнә бәйнә» 20 40 Л Ахеджакова һәм Г Хазанов «Бред вдвоем» фильм-спектакльдә 22 00 Теннис Дэвис кубогына Финал Русия — АКШ 23 30 «Вакыт елгасы» 23 35 «Автомизгел» 23 40 «299-00-00» хезмәте 23 55 1 39 Нәфис фильм «Таис» (Польша)

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

12 40 «Кунак» 13 00 22 45 — ТВ мәгълүматлары 13 10 «Яшәү стиле» 13 25 15 30 15 38 22 05 — «Музыка мизгеле» 13 30 ТВ мәгълүматлары немец дулкыны 13 45 Мультфильм «Далеко далеко на юге» 14 00 «Ашыгыч ярдәм» 14 35 Телесериал «Мануэла» 15 20 «Бакчачыларга киңәшләр» Тәнәфес
17 15 Балалар телевидениесе «Әкият арты әкият» 18 00 21 00 «Сайлаулар 95» 18 40 «Ленинград өлкәсе телекомпаниясе курсөтә» 22 10 «Шәхси эш» 23 00 «Спорт спорт спорт» 23 15 Ток шоу «Наобум» 23 45 Нәфис фильм «Привычная колея» (АКШ)

ШИМБӘ

2 ДЕКАБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7 00—8 00 «Чулпан» информацион программасы 18 15 Балалар өчен «Тамчы» 18 35 «Сомбелә» бәйрәме 19 00 «Татарстан» 19 30 «7 нче стиль» 20 00 «Әлли бәлли бәү» 20 15 Хезмәт һәм сугыш ветераны З Зәкиев турында телеочерк «Зәки абый» 21 05 Татарстан сәнгать осталарының хәйрия концерты 2 нче бүлек 21 55 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7 00 «Бүген Мэрилин белән» 7 30 20 20 0 20 «Шәһәр» информацион программасы 7 50 Телеэкспресс 1 декабрь тапшыруын кабатлау) Узган атна тапшырулары 8 05 «Коммерция өйләнмәсе» (28 ноябрь көнендәге тапшыруны кабатлау) 8 25 «Лариса» яңалыклары» 8 55 «Видеомода» 9 15 «Көннәрнең ямьсезләре булмый» 9 25 «Үз кешеләр» 10 00 «Казан автосалоны» 10 30 Балалар өчен нәфис фильм «Приключения Гекельберри Финна» (АКШ) 3 нче серия 11 30 «Атнага бер тапкыр» юмористик тапшыруы 12 00 Шимбә сериалы «Флиппер» 12 55 Хәрби телевидение 13 25 Сериал «Мелочи жизни» 13 55 Нәфис фильм «Ошибка резидента» 16 15 «Эфирда музыка» 16 20 «Сайлаулар читтән караш» 16 40 Телесериал «Детективы на полставки» 17 35 «Яшерен йомыш» 18 00 «Исәнмесез!» 20 45 «Мавыгулар дөньясы» 21 15 Телесериал «Тропическая жара» 22 10 Нәфис фильм «Небо над Берлином» 0 40 «Red Wave» тәкъдим итә Тэд Нуджент 1 10 «Эротека Венеры» телепрограммасы

1 НЧЕ КАНАЛ

7 45 9 10 — «Уяныгыз» телеканалы 8 45 «Пастырь сүзе» Митрополит Кирилл 9 00 18 00 0 15 — Яңалыклар 10 30 Балалар өчен күңел ачу программасы «Оттырма» 11 00 «Иртәнге почта» 11 35 «Төмле» 11 50 Телесериал «Живопись великие имена — Делакруа» 12 20 «Бомонд» 12 40 «Кеше һәм закон» 13 10 «Кыргый кыр» 13 25 «Европага тәрәзә» Д Киселев алып бара 14 00 Теннис Дэвис кубогына Финал Русия — АКШ Турыдан-туры трансляция 17 00 — «Шулай бервакыт» 17 10 «Бәхетле очрак» 18 00 «Кинематографъ» 19 00 «Алтын серия» 1981 ел «Мужики» 20 45 «Тыныч йокы нәниләр» 21 00 «Вакыт» 21 50 «Нәрсә? Кайда? Кайчан?» 23 00 Русиянең иң яхшы мультипликациясе «Золотые ворота» 23 05 М Козаковның «Покровские ворота» исемле комедиясе 1 нче серия 0 25 Ж Депардье һәм И Юппер «Лулу» фильмында
Төнге канал 2 15-3 15 «Яшьләр өчен музыка»

«РУСИЯ»

8 00 14 00 20 00 23 00 — «Хәбәрләр» 8 25 «Йолдызлар сөйли» 8 30 «Вовкулакия яки Доктор Никодимның табышмагы» 8 45 «РОСТ» компасы «Алтын антенна» 9 00 Балалар өчен телесериал «Одиссея» 9 25 «Алтын ачкыч» 9 45 «Әдәплелек» 9 55 «Клип-антракт» Л Агутин 10 00 «Парламент атнасы» 10 45 «Ретро-шлягер» 11 15 «Декабрь аенда кино» 11 30 «Карьера» 12 00 «Пилигрим» «Русиянең сәяхәтләр бюросы» 12 45 НБАның иң яхшы уеннары 13 45 «Кайнар Унлык» 14 20 «Де факто» 14 35 «Расследования комиссара Мегрэ» сериалыннан нәфис фильм «Старая дама из Байо» 15 25 «Алтынчы сиземләү» 15 55 «Без кем?» 16 25 «Дөнья экраны «Йолдызлары» 16 55 «Хатирәләрем театры» В Смехов программасы 17 25 «Футболга чикләр юк» 18 10 «Шарман-шоу» 19 05 «Утә яшерен» 20 25 «Майя дусларын чакыра» 22 00 «Клип-антракт» Н Королева белән кофе эчкәндә 22 05 Теннис Дэвис кубогына Финал Русия — АКШ 23 30 «Вакыт елгасы» 23 35 «Автомизгел» 23 40 0 55 1 10 — «299-00-00» хезмәте 23 55 «А» программасы

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

10 00 «Яшәү стиле» 10 15 «Исән калырга өмет» 10 35 Балалар өчен нәфис фильм «Шаг с крыши» 12 00 «Йолдыз белән рандеву» Л Успенская 12 30 15 45 18 35 — Төбәкара телевидение Телевизион күпер 13 00 Табиблар фармацевтлар һәм пациентлар өчен тапшыру «Рецепт» 13 10 «Теледоктор» 13 30 «Тарихи альманах» 14 00 Эшкә урнаштыру телевизион хезмәте 14 20 Нәфис фильм «Поезд вне расписания» 16 20 «Агата Кристи» төркемә концерты 16 30 «Гыйбадәтханә»
Балалар телевидениесе 17 20 «Алтын ачкыч» 17 35 «Ыргып өйдә»
22 00 «Оранж» телевидениесе «Телемәсең — карама» каналын тәкъдим итә 22 45 ТВ мәгълүматлары 23 05 «Телевизион күпер» Көн йомгаклары 23 20 «Оранж ТВ» тәкъдим итә «Навигатор» 23 35 Нәфис фильм «Борсалино и Ко»

ЯКШӘМБЕ

3 ДЕКАБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7 00—8 00 «Чулпан» информацион программасы 19 00 «ТОН» (атналык телекүзәтү) 19 35 «Автокалейдоскоп» 19 50 «Телебүләт» Тапшыру анонслары 20 00 «Әлли бәлли бәү» 20 15 «Бер көрәшү — үзе бер гомер» Азнакай якташларына багышлана 21 50 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7 00 «Рик Реннер белән яхшы хәбәр» 7 30 Телеэкспресс (атналык тапшыруларны кабатлау) 9 00 «Шәһәр» информацион программасы Узган атна тапшырулары 9 20 «Коммерция өйләнмәсе» (30 ноябрь тапшыруын кабатлау) 9 40 «Computerlife» 10 10 «Мавыгулар дөньясы» 10 40 Балалар өчен фильм «Приключения Гекельберри Финна» 4 нче серия 10 40 «Барысын да белергә телим» 11 55 «Атна фаразлары» 12 25 Телесериал «Подводная «Одиссея» команды Кусто» 12 55 Г Хазановка 50 яшь тулу уңаеннан тапшыру 13 55 «Атнага бер тапкыр» 14 25 «Барлык кешеләргә кирәк булачак» (П Иванов) 14 50 «Эфирда музыка» 15 00 Телемарафон Халыкара инвалидлар көне 17 30 «Мистер Бин» 18 00 «Кино музыкасы» 18 20 «Юл патруле» 18 35 «Диск-канал» 18 50 Телесериал «Детективы на полставки» 19 45 «Тамаша залы» («КиноМеню») 20 15 «Җирле вакыт» Информацион программа 20 45 Нәфис фильм «Кто полюбит моих детей» 22 30 «Исәнмесез!» (2 декабрь тапшыруын кабатлау)

1 НЧЕ КАНАЛ

7 50 «Спортлото» тиражы 8.00 9 10 — «Уяныгыз!» телеканалы 9 00 18 00 0 20 — Яңалыклар 10 30 «Бар да өйдә чакта» 11 00 «Таң йолдызы» 11 50 «Турыдан-туры» 12 00 «Карачаево-Черкесиягә сәяхәт» 12 30 «Көлкелә манзара» Е Петросян алып бара 13 00 Теннис Дэвис кубогына Финал Русия — АКШ Турыдан-туры трансляция 18 20 «Футбол күзәтүе» 18 55 «Шулай бервакыт» 19 05 «Ак попугай» клубы 20 00 Ричард Гир һәм Джоди Фостер «Соммерсби» мелодрамасында 22 00 «Якшәмбе» 23 00 «Покровские ворота» 2 нче серия 0 30 «Бер күрүдә ярату»
Төнге канал 1 05-2 20 «Дайана Росс Мәскәүдә»

«РУСИЯ»

8 00 14 00 20 00 23 00 — «Хәбәрләр» 8 25 «Йолдызлар сөйли» 8 30 «Теремкәй» 8 45 «Мазай бабай кунакханәсе» 9 00 Балалар телесериалы «Одиссея» (Канада) 9 25 «Хроно» Авто һәм мотоспорт дөньясында 9 55 «Хәерле иртә» «Чемпионнар өчен иртәнге аш» 10 25 «Аты-баты» 10 35 Сәүдә йорты «Шарп» 11 00 «Сәгать 11 дәге хәбәрләр» 11 15 «Урыс лотосы» 12 00 «Хайваннар дөньясында» 12 55 «Зур хоккей» 13 35 «Китап киштәсе» 14 20 «Кисеп бетерә алмаслык» 14 35 «Расследования комиссара Мегрэ» сериалыннан нәфис фильм «Старая дама из Байо» 15 20 «Безнең бакча» 15 50 Н Русланова «Встреча» фильмында 16 25 «Мода хәбәрчесе» 16 55 «Тапшырулар тартмасы» 17 10 «Өч баһадир» 18 00 Мультфильмнар «Чокнутый» «Новые приключения Винни Пуха» 18 55 «Комедия положений» Фредди Старр 19 25 «Ксюшада кунакта» 20 25 Нәфис фильм «Исчадие ада» 22 05 Теннис Дэвис кубогына Финал Русия — АКШ 23 30 «Вакыт елгасы» 23 35 «Автомизгел» 23 40 0 45. 1 00 — «299-00-00» хезмәте 23 35 С Шолохов программасы «Тын йорт»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

9 05 «Сезнең кәнәгез» 9 30 «Шифалы сүз» 10 00 «Яшәү стиле» 10 15 Мультфильм «Как Алдар Косе перехитрил тигра» 10 30 Нәфис фильм «Текс и владыка глубин» (Италия) 12 00 «Якшәмбе лабиринты» 13 10 «Музыка мизгеле» 13 15 Мультфильм «Тяп и Мика» 13 35 «Алкышлап» С Захаров 14 05 «Страсти мордасти» 14 25 «Классика-5» М Бежар балет труппасы һәм Мариинский театры йолдызлары 1987 ел язмасы 15 30 «Депутатларга сүз бирәбез» 16 00 «Хыялллан» студиясе 16 10 Экспресс-кино 16 25 Футбол буенча Италия чемпионаты
21 05 Нәфис фильм «Найдешь друга — обретешь сокровище» (Италия) 22 45 ТВ мәгълүматлары 23 10 «Адәм алмасы» тәкъдим итә «Ноу смокинг» 0 00 «Адәм һәм Хава плюс» 0 30 Баскетбол Русия чемпионаты Супер лига «Спартак» (СПб) — ЦСКА (Мәскәү)

Һәркөнне 8.00 (якшәмбедән тыш), 19.00, 9.00 (шимбә), 10.00 (шимбә, якшәмбе) сәгатьләрдә — Мәскәүдән информацион һәм-аналитик программалар трансляцияләнә.

ДҮШӘМБЕ, 27 НОЯБРЬ

6 00, 19 10 Соңгы хәбәрләр 6 15 Иртәнге дулкында 6 48, 20 50 Татарча өйрәнәбез 6 53, 7 58, 20 55 Һава торышы 6.55, 7.50 Белдерүләр 7 00 Информацион музыкаль программа 7 45, 20.55 Тапшырулар программасы 18 20 «Борын-борын заманда» 19 40 Лениногорск районы һәвәскәрләре концерты 20 35 «Дүшәмбедән дүшәмбегә» Мәдәният-сәнгать яңалыклары

СИШӘМБЕ, 28 НОЯБРЬ

6 00, 7 00, 13 10, 19 10 Соңгы хәбәрләр 6 15 «Иртәнге дулкында» 6 48, 20 55 Татарча өйрәнәбез 6 53, 7 58, 13.30, 21 00 Һава торышы 6.55, 7 50 Белдерүләр 7 15 Концерт 7 45, 12 25, 21 00 Тапшырулар программасы 9 25 «Гасырлар чоңгылыннан» (Татарстан радиосы) 12 25 – 14 20 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы Чыгарылышта 12.30 Башкортстан артистлары концерты 13 15 Республика газеталарына күзәтү 13 35 «Русия Федерациясе Федераль җыелышының Дәүләт Думасына сайлауларга карата» 14.20 «Юллар чатында» Информацион программа 18 20 «Яшьлек» студиясе 19 40 Татарстанның атказанган артисты С Йосыповның иҗат кичәсеннән трансляция буенча язма 20 40 «Көн темаларына» Әңгәмәләр, аңлатмалар

ЧӘРШӘМБЕ, 29 НОЯБРЬ

6 00 «Татарстан дулкынында» 6 48, 20 48 Татарча өйрәнәбез 6 53, 7 58, 13 30, 20 53 Һава торышы 6.55, 7 50 Белдерүләр 7.00, 13 10, 19 10 Соңгы хәбәрләр 7 15 Концерт 7 45, 12.30, 20 53 Тапшырулар программасы 12.30 13 35 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы Чыгарылышта 12.35 Концерт «Без Татарстан җирендә яшибез» 13 15 Республика газеталарына күзәтү 18.30 «Эшмәкәрләр клубы» 19 40 Сораулар буенча концерт

ПӘНҖЕШӘМБЕ, 30 НОЯБРЬ

6 00, 7 00, 13 10, 19 10 Соңгы хәбәрләр 6 15 «Иртәнге дулкында» 6 48, 20 35 Татарча өйрәнәбез 6 53, 7 58, 13 30, 20 40 Һава торышы 6 55, 7 50 Белдерүләр 7 15 Концерт 7 45, 12 30, 20 40 Тапшырулар программасы 12 30 13.35 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы Чыгарылышта 12 35 «Балалар җырлый» 13 15 Республика газеталарына күзәтү 18 20 «Сәламәтлек» 19 40 «Музыкаль Татарстан» (Радиокүзәтү)

ҖОМГА, 1 ДЕКАБРЬ

6 00 «Балкыш» 6 48, 20 28 Татарча өйрәнәбез 6 53, 7 58, 13 30, 20 33 Һава торышы 6 55, 7 50 Белдерүләр 7 00, 13 10, 19 10 «Соңгы хәбәрләр» 7 15 Концерт 7 45, 12 30, 20 33 Тапшырулар программасы 12 30 14 20 «Көн үзәге» информацион нәфис каналы Чыгарылышта 12 15 Концерт 13 15 Республика газеталарына күзәтү 13 35 Русия Федерациясенең Федераль Җыелышының Дәүләт Думасына сайлауларга карата 18 20 «Чишмәләр» (чуваш теленнән) 19 40 «Лирик музыка концерты»

ШИМБӘ, 2 ДЕКАБРЬ

6 00, 7 00 Соңгы хәбәрләр 6 15 Авыл хезмәтчәннәре өчен концерт 6 58, 7 58, 9 55 Һава торышы 7 15 Иртәнге концерт 7 45, 9 55, 14 05 Тапшырулар программасы 7 50 Белдерүләр 8 10 «Сезнең хатлар буенча» 8 20 «Мәсьәләгә бер караш» 8 15 «Көмеш кыңгырау» 8 55 С Сәйдәшевнең тууына 95 ел тулуга карата тапшыру 9 20 «Кардәшлеккә чикләр юк» 10 20 «Көн артыннан көн» 11 20 «Көзге» 11 50 «Пар канатлар» 12 20 «Татар музыкасының яңа язмалары» Әңгәмә-концерт 13 15 Яңалыклар эстафетасы 13 35 «Яшьлек» студиясе

ЯКШӘМБЕ, 3 ДЕКАБРЬ

6 00 «Татарстан дулкынында» 6 48, 7 45, 13 35 Тапшырулар программасы 6 48 7 58, 13 35 Һава торышы 6 55, 7 50 Белдерүләр 7 00 «Хәерле иртә» 8 00 «Идел белән Урал арасында» Алты республиканың берләштерелгән радиожурналы 9 10 М Мәһдиев «Бәхилләшү» Әсәрдән өзек 11 10 «Яңа китап — яңа дус» 11 40 «Табигать турында хикәяләр» Декабрь 12 10 «Тел күрке — сүз» 12 40 С Сайдашев әсәрләреннән концерт 13 40 Р Файзуллин «Сайлау» Радиокомпозиция

Иҗтиһат

Дамир ХИСАМИЕВ:

Чын эшмәкәр сәнгатьтән читләшмәс...

Дамир 1957 елда Казан шәһәрендә туган. Хәзерге Әтнә районының Кече Әтнә авылында үскән. Белгечлеге буенча — югары белемле зоотехник. Эше-шөгыле — эшмәкәрлек. Түбән Кама шәһәрендә яши. Хатыны Асия белән ике кыз үстерәләр. Өлкәне — Эльмира, кечесе — Лилия, икесе дә Түбән Каманың 13 нче мәктәбендә укыйлар. Дамир үзе әйткәнчә, укулары әйбәт...

— Дамир, мин синең үзең эшләп тапкан акчаның бер өлешен республика балалар клиник хастаханәсенә күчерүең турында ишеттем. Шулай ук Татарстан Диния нәзарәте каршында «Өмет» дип аталган шәфкатьлелек фонды оештыруда да булышлык иткәнсең. Эшмәкәрләрнең мондый игелекле гамәлләре турында, сирәк булса да, ишетеп торабыз. Тик, кулны күкрәккә куеп әйтсәк, бу — бер кесәдән алынган акчаны икенче кесәгә салу һәм шуның исәбенә шәфкать иясе булып күренергә тырышу гына түгелме?

— Бу соравыңны аңлыйм мин. Мондый сорауны, гомумән, беренче тапкыр гына ишетүем түгел. Менә син балалар клиникасына ярдәм турында әйттең. Ул минем өчен зур да түгел, кечкенә дә түгел, ә бәлки ихлас күңелдән, хәлдән килгәнчә, гади бер ярдәм.

— Мондый ихласлылыкның да сәбәбе-нигезе булырга тиештер бит?

— Беләсеңме, мин үзем Казанда туганмын. Ике яшькә кадәр «Дом ребенка» дип аталган бер урында үскәнмен. Минем әнием шунда эшләгән. Күкрәк сөте булмаган аналарның балаларын имезгән ул.

Әтиемне мин бөтенләй хәтерләмим. Соңыннан без авылга, Кече Әтнәгә күченеп кайтканбыз. 1965 елда үги әтием дә вафат булды. Аның белән Әтнә базарына йөргәнемне хәтерлим. Сукыр Хаҗи дип әйтсәләр, өлкән буын кешеләре аны шундук искә төшерер. Әтнә ягында. Базарга аны җитәкләп йөри идем.

Бәлки, менә шундый авыр тормышта үсү ятимлекне тату, әниемнең күкрәк сөте белән кергән тәрбия миндә. — инде менә шундый мөмкинлеккә ирешкәч, башкаларга азмы-күпме ярдәм итә алу мөмкинлеге тугач, — әнә шундый бер-бер игелек кылу теләге уяткандыр.

Аннан соң Кече Әтнәдәге күршеләремне-авылдашларымны һаман да сагынып, зур ихтирам белән искә алам мин. Күршеләребез Лотфулла абый белән Гөлбикә апа, Ваһап абый белән Фәризә апа, миңа белем биргән мәктәп укытучылары... Кешеләргә игелекле булып калырга өйрәткән өчен меңмең рәхмәт аларга.

— Дамир, авылдашларны, күршеләрне искә төшереп, син мине дә балачакка алып кайттың. Ә бит шулай иде: кайчак күршеләргә килеп керәсең (ә безнең буын балачагы — «денсез» буын балачагы бит инде), ә анда фәлән әби яки фәлән бабай намаз укып утыра. Ни хәтле генә «денсез» булсак та, намазны бүлү-бүлдерү юк иде бит бездә...

— Безнең буын шуның белән бәхетле дә: ул өлкәннәргә ихтирам хисен тоеп-сеңдереп, әнә шул намазлыктан күтәрелгән әби-бабайларның изге, фатихалы сүзен ишетеп калды бит. Дин бит ул беркайчан да начарлыкка өйрәтмәгән. Менә мин үзем намаз да укый белмим, ләкин әнә шул күршеләрнең акыллы-мәртәбәле сүзе, мөгамәләсе миндә дингә карата да олылау хисе тәрбияләдә. Бигрәк тә күршеләребез Насыйр абый белән Әминә апа (алар хәзер мәрхүмнәр инде) бик тә, бик тә динле кешеләр иде. Чыннан да шулай, нәкъ син әйткәнчә, әни йомыш белән күршеләргә кертеп җибәрә дә, кайчак намаз вакытына туры киләсең. Сабыр гына көтеп торасың, әллә нинди бер илаһи көч белән аралашкандай тоясың үзеңне.

Менә, син бая Татарстан Диния нәзарәте каршындагы «Өмет» дигән шәфкатьлелек фондын оештыруым турында әйттең. Беләсеңме, андый теләк ничек туды? Менә шул дин мәсьәләләре, дин эшләре нисбәтендә күп кенә кешеләрнең, хәтта зур-зур җитәкчеләребезнең дә кайчак бик үк дөрес булмаган караш тотуы борчыды мине. Мин, шул хакта уйлап, Габдулла хәзрәткә хат-мөрәҗәгать юлладым. Бу теләгемә ул фатиха бирдә, куәтләдә. Шулай итеп, әлеге «Өмет» шәфкатьлелек фонды туды, тиешле оешмалар тарафыннан теркәлде-расланды. Мәдрәсә шәкертләренә, дини белем алырга теләүчеләргә, гомумән, мохтаҗ кешеләргә ярдәм итә алырлык, шәфкать хисен ихласлылык белән тыгыз бәйләгән фонд булачак ул.

— Дамир, бу эшең турында ишеткәч, әниең дә нык шатлангандыр, шулай бит?

— Әни инде җитмеш сигез яшьтә. Безнең белән яши. Әтнәне сагынып искә ала. Яшерен-батырын түгел, туган авылга инде шактыйдан бирле кайтканым юк. Әни, әлбәттә, шатланды. Ул бит теге «Дом ребенка»да эшләгән, балаларны туйдырган чакларын яхшы хәтерли. «Савап булыр, улым» — диде әни миңа.

— Ә хатының? Хатыннар бит кайчак акчаны читкә өләшкәнне өнәп тә бетермиләр...

— Менә син янә баштагы сүзгә урап кайттың. Мин инде болай дип әйтәм: мин ул акчаны, мәсәлән, хатынга да кайтарып бирә ала идем, кем әйтмешли, баҗайга да бирергә мөмкин иде. Ә балалар клиникасына ярдәм итүне без бергәләшеп уйлашып хәл иттек. Ихластан.

Инде менә тагын шундый хыялым бар: Кече Әтнәгә кайтып, шунда авылдашлар белән очрашып-күрешеп, мәчеткә кереп, мәрхүм булган авылдашларым истәлегенә, авылым нигезе исәнлегенә бер дога кылсам иде. Авылдашлар мине начарлыкка өйрәтмәделәр.

— Дамир, безнең бу сөйләшүгә бер карарганда бигүк бәйләнмәгән дә, әмма кайсыдыр ягы белән шактый ук бәйле булып та тоелган бер сорау бирим әле. Казан базарларында (хәзер алар шактый ешайды) ярминкәләр уза. Менә шуларда хәйрия ашлары — өлкәннәрне, инвалидларны бушка ашатулар оештырыла. Бушка ашаткан җирдә гадәттә урлашу да күп була...

— Нияз, беләсеңме, мин районның зоотехнигы булып эшләдем. Өстән, югарыдан килгән җитәкчеләрне «бушка ашату»ларны күп күрдем. Аларны дәүләт кесәсеннән, халык кесәсеннән ашаттылар. Чын эшмәкәр хәйрия ярдәме өчен акчаны бары тик үз кесәсеннән генә ала. Минем әнием сугыш чорында Кукмарада, Манзарас авылында эшләгән. Шушы авылга рәхмәт әйтәсем килә: ул әнинә сыендырган, эш биргән. Әнинең сөйгән егете сугышка алынган. 1945 елның апрелендә Берлинга барып кергәч үлеп калган. Гармунчы егет булган ул. Әни аның хатларын саклады. Әнинең ике абыйсы да сугышта үлеп калган.

Менә бәлки, инде аңларсың: мин — табигатьтән шулай — кешеләргә кешелеклелек гыйлем әнием миңа шул теләкне-доганы иңдерде.

— Ә синең, Дамир: татарда эчми торган, акыллы 300 миллионер туса, бөтен Русияне татар яулаячак, дигән сүзне ишеткәнең бармы?

— Бар. Аны шовинист Пуришкевич әйткән. Татарда шундый егетләр туса, сәнгатебез һәм әдәбиятыбыз да үсәчәк.

Әңгәмәне Нияз АКМАЛ
үткәрде

Телевидение һәм тамашачы

Бер җомгада ике бәйрәм

Без Татарстан телевидениесенең «Җомга кон кич белән» дигән тапшыруларын берсен дә калдырмый диярлек карап барабыз. Үз милләтен яраткан бөтен кешегә дә рухи азык бар анда. Моңа чаклы китапларын гына укып белгән язучылар белән дә очрашасың, галимнәр дә монда еш чыгыш ясый. Яраткан артистларыбызны да еледән-еле күреп торабыз. Кыскасы, «Җомга» тапшыруының күбесе милләт җанлы булган татар кешесе өчен бәйрәм ул.

Үткән җомгаларның берсендә исә безнең өчен икеләтә бәйрәм булды. Новокузнецк шәһәреннән кунакка кайткан туганнарыбыз белән шул тапшыруны карарга җыендык. Без дә бу тапшыруны алдан мактагач, торган җирләрендә татарча тапшыру күргәннәре дә булмагач, кунакларыбыз иртәдән үк әзерләнә башладылар. Иртә кычкырган көккүкнең башы авыртыр, дигәндәй, алдан мактап хур булмасак кына ярар иде инде, дип куркыбрак та торган идек. Шөкер, алай булмады. Киресенчә, нур өстенә нур булып, бу көнне без сезнең «Мәдәни җомга» газете белән дә таныштык. Хәер, аны «сезнең» дип кенә түгел, «безнең» дип тә әйтергә кирәктер инде.

Чөнки без, Казанда яшәсәк тә, моңа чаклы бу газет турында берни дә белмәгәнбез икән. Дөрес, шундый басма чыга башлавы турында ишеткән идек инде. Ничектер, бер тапкыр күзгә дә чагылып киткән иде. Ләкин эчен ачып карамагач, берәр төрле фәнни газеттер, дип уйлаган идек. Яки язучыларның әсәрләрен бастыру өчен генә кирәкле берәр басмадыр, дигән уй да булды. Чөнки хәзер андый газит-журналлар бик күбәйде бит. Болай дип язганым өчен үзләре үпкәләмәсеннәр кызганыч, аларның күбесендә татар-татар, дип, милләт-милләт дип авыз суын корыта торган мәкаләләр бик күп булса да, милләт язмышын тирәнтен ачып бирә торганнары бик аз шул.

Урамда кычкырып йөреп кенә, өчпочмак саен лаф орып кына, яисә митингларда гавылашланып кына әллә кая китеп булмый. Билгеле, үз урынында алары да кирәктер. Чамасын белгәндә. Ә инде халык хәзинәсенә әверелгән тарихи, мәдәни байлыгыбызны искә төшерү, бүгенге көндә язучыларыбызның, гади кешеләрнең нинди хыяллар белән яшәүләрен һәм ничек иҗат итүләрен белеп тору кирәк — әнә шулар күтәрә милләтне. Әнә шулар яңа тормыш диңгезендә батып калмыйча, башка милләтләр алдында ким-хур булмыйча яшәргә ярдәм итә.

Әлеге «Җомга» тапшыруын карагач, сезнең газит белән танышкач, нәкъ шуларны күреп шатландык. Безнең дә халкыбызга җан азыгы булырлык газитебез бар икән ләбаса!

Ярый әле, очрашуга төрле-төрле һөнәр ияләрен чакыргансыз. Әгәр гадәттәгечә сәнгать әһелләре генә булса, тапшыру бәлки бу кадәр мавыктыргыч та булмас иде.

Мәсәлән, теш врачы Исеме истә калмаган, фамилиясе Рәхмәтуллин. Башта, мәдәни газиткә бу иптәшнең ни катнашы бар икән инде, дип уйлап утырдым. Чынлыкта бар икән шул. Газиткә беренче булып язылган кеше икән. Ярый шуның өчен ул редакциягә кадерле кеше булсын ди. Соңыннан белдек, безгә дә бик кирәкле кеше икән. Озак сөйләнеп тормыйча, шундый матур итеп җырлап җибәрдә. Кайбер артистларың бер читтә торсын. Ул кыяфәт, ул тавыш, ул моң! Күз тимәсен үзенә.

Флорид Зарипов — рәссам. Әлбәттә, рәссамнарның газиткә азмы-күпме катнашы бар. Ләкин аның белән таныштыруыгыз да гадәттәгедән үзгәрәк булды. Әлеге барысы да аңлашылып бетмәсә дә, ул да үз рәсемнәрен фәлсәфи нигезгә корган икән. Рәсем сәнгате татарда болай да яңарак әле ул. Фәлсәфи тамырдан чыкканнары, ялгышмасам, бездә әлегә бөтенләй диярлек юк иде. Аның иҗаты турында «Җомга»да сөйләрязарбыз, дигәч, бу кеше белән без әле дигәч, бу кеше белән дә якыннанрак танышасыбыз бар икән әле, дип ризалаштык.

Харис хәзрәтне алыйк. Без Харис хәзрәтләрнең, Госман хәзрәтләрнең вәгазьләрен элек тә яратып тыңлый идек. Халкыбызның әхлагы турында кайгыртып, газиттә күтәрелә торган мәсьәләләрнең дә уртаклыгын табып сөйләгәч, тормышка дөньяга ышаныч уяна. Үз планнарыгыз, ничектер, дини мирасыбызга киләчәктә дә газиттә урын бирелсә әттырмассыз, дип уйлыйм.

Баш мөхәррир Зиннур Мансуров, Фоат Галимуллин, Лена Шагыйрьҗан, Мәсгудә Шәмсетдиновалар безгә телевизор аша электән дә таныш кешеләр. Тагын бер очрашу — якын танышың белән күрешү кебек. Рабит Батулла аш-су өстәле янына килеп баскач, башта аңламыйчарак калган идек. Әллә бу өчпочмак пешерергә өйрәтәмә, кирәкмәс идә, дип уйладык. Өчпочмак пешерә белмәгән татар бармыни ул! Без, мишәрләр әйтмешли, хитрый ход кына булган икән. Буза дигән эчемлекне ясаучы оста да булып чыкты бит әле бу. «Бик тәмле эчемлек икән, сез эчкәнне карап тордык» — дип көлештек. Вәгъдә иткәнегезчә, ничек ясарга икәнен газиттә дә бастырып чыгарсагыз, үзебез дә эшләп карарбыз, иншалла. Ул эчемлек кенә түгел, онытылган милли аш буларак та кадерле бит әле.

Яраткан җырчыбыз Хәмдүнә Тимергалиевага сез дә иң ахырдан сүз бирдегез. Мин дә иң ахырдан язам әле. Хәер, аның турында язып торуның кирәге бар микән? Аны тыңларга гына кирәктер. Минемчә, Халык җырларын дисеңме, композиторларыбыз әсәрләрен дисеңме — үзәкләреңне әзерләк итеп башкаручы җырчыларыбызның берсе бит ул. Галигә барам әле дип җырлый торгач, ул да насыйп ярын тапкан икән. Якты булсын уйларың, котлы булсын туйларың, Хәмдүнә! Ак бәхетләр юлдаш булсын. Без синең өчен бик шатландык, гаиләгә бәйләндем, дип, син безне дә онытма.

Ахыргы сүз итеп, тапшыруны алып барган Индус Сирматовка да зур рәхмәт. Әйткәнемчә, ул алып барган «Җомга»ларны элек тә яратып карый идек. Кунакларыбыз болар Мәскәү дикторларыннан бер дә ким түгел икән, дигәч, безгә дә рәхәт булып китте. «Сез бәхетле икән, — диделәр кунакларыбыз, — атна саен татарча тапшырулар карау безгә төшеми инде ул» — диделәр. Ичмасам, хәзер чит җирләрдә Татарстан газитләренә язылу да кыен икән.

Кыскасы, бер җомгада ике бәйрәм ясадыгыз. Киләчәктә дә газитегез кешеләргә шатлык китерсен, дигән теләктә калабыз.

P.S. Бу хатымны газиттә бастырсагыз, туры килеш бирсәгез иде. Рәхмәтебезне барысы да ишетсен иде.

Равил МӨХӘММӘТШИН.
Казан шәһәре

Анысы. адәм балаларын кешелек җәмгыяте ералганнан бирле хөкем итәләр инде Өтермәнгә дә утыртып куялар. башка зуррагын да эшлиләр Бактың исә. төрле бөҗәкләрне. хайван кошларны. хәтта инде табигатьнең үзен дә суд җаваплылыгына тарткан заманнар булган икән Аларны да чын-чынлап, бөтен шартларын китереп хөкем итеп яткан нар адәм балалары!

1545 ел. Франциянең Сан-Жанде-Мольен шәһәрендә чиркәү судында икә адвокат чыгыш ясый. Аларның берсе шәһәр халкын. икенчесе.. монда очып килеп, басу-кырларны эштән чыгарган саранчаларны яклап сөйли. Хөкем чыгара алмый калалар. саранча моннан очып китә. Тагын 42 елдан соң саранча яңадан килә. суд үзенең эшен дәвам итә һәм карар чыгара «Чиркәү бу бөҗәкләргә дә көтүлек кирәк икәнен гадел дип саный Аларны да Алла яраткан. Әмма алар ризыкны йөзем җимеше басуларында түгел. ә бүтән урыннан эзләргә тиешләр».

Ике ай вакыт үткәч, бөҗәкләр адвокаты епископка шикаять язып керә Баксаң-күрсәң, саранчаларга дип бүлеп бирелгән басуда ашарга яраклы берни дә булмаган икән. Бөҗәкләр яңадан монда очып килгәнче суд эшен туктатып торырга карар чыгаралар. Ә ул арада кыш та килеп җитә Бөҗәкләр эше тәки ахырына кадәр ачыкланмыйча кала.

• • •

Испаниянең Гимаран шәһәрендә 1540 елда кояя күбәләген, әйе, судья каршысына коя күбәләген китереп бастыралар. Аны бик төкыйммәтле келәмне бозуда гаеплиләр. Бик җентекләп тикшеренүләр һәм бәхәсләрдән соң коя күбәләге гаепле дип табыла һәм башын кисүгә хөкем ителә. Шул ук вакытта судья коя күбәләгенең барлык нәсел-нәсәбәсен корольлек җиреннән мәңгегә куып җибәрү турында карар чыгара Бу хөкемне суд эшенең ялгышы дип карарга кирәк. Чөнки келәм һәм бүтән шуның ише кыйммәтле әйберләрне коянең күбәләге түгел, ә корты ашый. Аннан килеп, суд белдерүе белән генә көяләр корольлек биләмәләреннән мәңгегә чыгып киттеләр микән әле? Бик икеле бит бу!

Табигатьне хөкемгә тартып буламы?..

Әкәмәт

• • •

1474 елда Швейцариянең Базель шәһәрендә гаҗәеп көлкеле суд утырышлары булып уза. Эш шунда ки, монда бер әтәч... күкәй салып куйган икән. Бу убырны шунда ук тотып алалар һәм хөкем каршына бастыралар. Хөкем дә бик дәһшәтле була. Әтәч мескенне күкәе-ние белән зур учакта яндыралар. Бүтәннәргә сабак булсын дип.

• • •

Гыйрак дәүләте җиреннән Диала елгасы агып үтә. Бу — дөньяда үлем җәзасына хөкем ителгән бердәнбер елга. Һәм бу хөкем җирена дә җиткерелгән.

Беләсезме, елганы кем мондый кырыс хөкемгә тарта? Шул замандагы фарсылар патшасы Кир башкара бу эшне. Диала елгасы аша кичкәндә падишаһның иң яраткан һәм барча яраннары изге дип атаган ак төстәге бик матур аты суга батып үлә Моңа җен ачулары чыккан Кир як-якка 360 канал казырга, шуларга елга суын бүлеп бетерергә боера. Һәм шулай эшлиләр дә.

Бу эш көлке булып кына бетми. Елга мең еллар буена үзенең шул урыннан ары таба агуыннан туктый. Тик гасырлар артыннан гасырлар үтеп теге каналларны ком каплап киткәч кенә елга үзенең элекке юлына төшеп ага башлый.

Мәгълүматларны язучы **Радик ФӘИЗОВ** туплады.

Үкчы йолдызлыгы астында туганнар

Котлыйбыз!

25 ноябрь

ӘБЕЛМӘМБӘТОВ Роберт Шәрифҗан улы — К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры директоры.

ЙОСЫПОВ Изил Галимҗан улы — «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең фәнни-тикшеренү проект нефть институты директорының фәнни эшләр буенча беренче урынбасары, техник фәннәр докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең өгъза-мөхбире, СССР Дәүләт бүләге иясе.

27 ноябрь

АКАМОВ Владимир Яковлевич — рәссам

ӘХМӘТОВ Наил Сибгат улы — КТУ каршындагы югары уку йортлары укытучыларының квалификациясен күтәрү факультеты деканы. химия фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйки әгъзасы.

ГАРИФУЛЛИНА Мөслимә Гарифулла кызы — Минзәлә драма театры артисты.

ХӘЙДӘР (ГӘЙНЕТДИНОВ Хәйдәр Гайфетдин улы) — язучы, Татарстан телевидениесенең өлкән мөхәррире.

28 ноябрь

ШАПИРО Давид Мотелевич — Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артисты, Татарстанның атказанган артисты.

29 ноябрь

ГӨЛШАҺИДӘ (МАКСУДОВА Шәйдә Абдрахман кызы) — язучы-тәрҗемәче.

30 ноябрь

СОЛТАНОВ Һидият Айниятулла улы — Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты, Татарстанның халык артисты.

Яңа гәзиткә язылу бара

— Картым, бәрәңге саткан акчаны бик ерак яшергәнсең. «Мәдәни җомга»га язылаcы бар бит...

Чайнворд «В»



Барлык сүзләр дә «В» хәрефенә башлана һәм бетә

1. Татар шагыйре, язучысы һәм китапханә директоры (яки «Мирас» һәм «Эт кояшы» повестьлары авторы). 2. Тула өлкәсендәге шәһәр. 3. Татар революционеры 4 Драматург, Әзәрбәйҗан театрына нигез салучыларның берсе 5 Казанда Октябрь кораллы восстаниесен җитәкләгән кешеләрнең берсе 6 Урыс совет язучысы, «Врач язмалары» повестеның авторы. 7. Татар язучысы, «Ташу», «Уяну» повестьларының авторы. 8. Күренекле урыс актеры һәм режиссеры 9 Эстониядәге күл. 10 Журналист, «Камышлы күл сагышы» исемле детектив очерклар китабының авторы. 11. Профессор, Казан терапевтлар мәктәбенә нигез салучы. 12. Киев өлкәсендәге шәһәр. 13. Этнограф. «Казан татарлары» китабының авторы. 14. Казакъ мәгърифәтчесе, тарихчысы һәм этнографы. 15. Польшадагы шәһәр. 16. Штангист, Олимпия Уеннары чемпионы. 17. Ладога күленә коючы елга. 18. Очучы-космонавт, ике тапкыр Советлар Союзы Герое. 19 Болгар язучысы, «Яңа җир» романының авторы 20. Татарстанда яшәгән урыс рәссамы.

Ренат ГАЛӘВИН төзеде. Казан.

Гәзитебезнең 16 нчы санында басылган, һәр сүзе «А» хәрефенә башланган һәм беткән чайнвордның җаваплары

1 Акмулла 2 «Аэлита» 3 «Алпамша». 4. Арча 5. Абдулла 6. Афзалова. 7. Анафора 8 Абага 9 Атна. 10 Альтернатива. 11. Акчура. 12. Алабуга. 13. Алма 14 «Ардабиола». 15 Арпа 16 Апа. 17. Алла. 18. Атилла. 19. Атама. 20 Алка 21 Атлама 22 «Андромана» 23 Аждаһа. 24 Алаша 25. Антитеза. 26 Алабута 27. «Алданма» 28 Апара 29 Арба 30 Алиева. 31. Аңлатма. 32. Алга 33 Ага

Мәдәни ЖОМГА

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат, Мәдәнният министрлыклары химаясендә чыгарыла

Баш мөхәррир Зиннур МАНСУРОВ

Баш мөхәррир урынбасарлары Газинур МОРАТ, Миншәех ЗӘБИРОВ

Җаваплы сәркатип Альберт САБИРОВ

Телефоннар:
32-41-79 — кабул итү бүлмәсе;
32-45-78, 32-06-76 — баш мөхәррир урынбасарлары;
32-57-36 — җаваплы сәркатип;
32-57-76 — җаваплы сәркатип урынбасарлары;
32-62-79 — публицистика, очерк. сәясәт бүлеге;
32-58-91, 32-68-22 — әдәбият бүлеге;
32-60-11 — сәнгать бүлеге;
32-12-08 — тәнкыйть, фән, тарих бүлеге;
32-62-79 — мәдәнният яңалыклары, мәгълүмат тәрҗемә бүлеге;
32-59-55 — халык тормышы, рухияте аклау;
32-69-54 — хатлар бүлеге;
32-66-28, 32-59-22 — рәссамнар;
32-69-26 — фотохәбәрче;
32-57-94 — бухгалтерия.

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

Газетада басылган язмаларны, фотографияләрне файдаланганда, шулай ук өземтәләр китергәндә, «Мәдәни җомга»дан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри

Реклама урнаштыру өчен заказлар кабул ителә

Реклама һәм белдерүләргә төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәләк ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты 609403 МФО 265566 в Бауманском отд. ПСБ

Газета Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 428 нче таныклык белән теркәлде

Индекс — 54129

Редакция адресы: 420503, Казан, Бауман урамы, 19

Нәшрият адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре уңаеннан 49-36-62 номерлы телефон буенча шалтыратырга

Газета редакциянең компьютер үзәгендә эшләнде

Газетаның сатудагы бәясе килешү буенча

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе

Тираж 8000
Заказ 4467